PRESSA.RU

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№12 (312) – ДЕКАБРЬ 2017

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан
нәшер ителә

Киләчәк бусагасында

Дингә юл – гыйлем аша

Каһарманнарга сусау: без аларны таныйбызмы?

ЗУР ЭШНЕҢ ӨЛЕШЕ БУЛУ КУАНДЫРА

4 612750 670011



16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Олеся Бондаревская,
Руфия Фазылова
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Ксения Сёмина, Катерина Котова,
Фаяз Хуҗин, Муса Юлдашев
Фотографлар: Александр Ефремов, Ната Смирнова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин,
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: җырчы Алинә Шәрипҗанова

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж: 3500 данә,
шул исәптән татар телендә – 1000.

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү
мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры
килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге
өчен редакция җавап бирми. «Промо» һәм «Медиа»
рубрикалары материаллары реклама-коммерция
нигезендә басыла.

Журнал «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № А-3149

Басарга кул куелды: 22.12.17

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com
Коммерция директоры урынбасары:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru
Коммерция бүлеге белгече:
Екатерина Благодарова,
eblagodarova@inbox.ru, тел. (843) 222-09-76
Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ҮЗ ӨЕҢДӘ – ҮЗ КӨЕҢ

Журналның декабрь саны чыкканчы булып узган тормыш хроникасына күз салсак, аны болайрак сурәтләргә мөмкин: «...Бу хәл Нурлатта булды – ятим балаларга өр-яңа фатир ачкычлары тапшырылды. Ә аннан шундый ук ачкычларны Яр Чаллыдагы 183 гаилә социаль ипотека буенча алды. Аңа кадәр Болгардагы балалар йортыннан чыгучыларны торак белән сөендерделәр. Уздымы икән бер атна, «Салават күпере» микрорайонындагы 425 фатирга педагоглар, табиблар, ветераннар кереп урнашты... Чистайдагы өр-яңа 104 фатирлы йортта авария хәлендәге торактан күчереп урнаштырылган яшь һәм күп балалы гаиләләр өй туен бәйрәм итте... Ә менә Түбән Камада, хәтерлибез, әйе, әйе, нәкъ шундый ук бәйрәмне социаль ипотека программасы буенча тапшырылган чираттагы йортның яңа хуҗалары билгеләп узды!..»

Озын сүзнең кыскасы, 2017 елның азагы күп кенә гаиләләргә бәхет алып килде, аларның күбесе үз йортына ия булды, ә «Татарстан» журналы, һәрвакыттагыча янәшәдә булып, яңа йортка күчүчеләрнең шатлыгын үз йөрәгә аша кичерде. Яңа елга шуннан да зуррак бүләк бармыни, йә хыялың тормышка ашсын әле! Ул барлык гаилә әгъзалары өчен уртак булган киң колачлы хыял да булса тагын! Татарстанлыларның бу хыялы чыннан да бәрәкәтле хәл ителде: хәзер алар үз өйләрендә Яңа ел чыршылары бизиләр, Кыш бабайның килүен көтәләр, теләкләр телиләр. Кемнеңдер теләге зуррак, кемнекедер – могҗизалырак. Хәер, эш чагыштырудамыни! Иң мөһим теләк бит инде тормышка ашты! Ә ул өйгә, беләсездер, шәт, гадәт буенча, беренче эш итеп песине кертәләр. Ул өйгә авыр эш көненнән соң кайтып керүнең рәхәтлеге! Ул өйдә балалар үстереп, кунаклар каршылап, бер-бер артлы Яңа еллар каршылауны уйлап киләчәккә күз ташлавы... анысы да үзенә бер бәхет!

«Без үз өебезне яратырга һәм кадерләргә сүз бирәбез!» – диде Нурлаттагы ачкыч ияләре, дәррәү кубып. Алар әле кичә генә чынбарлык булган коллектив тормыштан, шартлардан бөтенләй башка тормышка аяк атлауларына яңа гына ышана төште бугай. Үз өеңдә – үз көең бит!

Һәм нәкъ менә шушы Яңа ел алды могҗизасыннан башлана да бәйрәм саныбыз.

СЕЗНЕҢ ДЕКАБРЬ РЕДАКЦИЯГЕЗ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фарит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» АҖ
Нәшер итүче:
«Татмедиа» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе:
900 сум 00 тиен

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ®

Г. Дәүләтжанов. «Казан. Бауман урамы»

ДЕКАБРЬ

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

8. Киләчәк бусагасында. Яңа фатирларга ачкычларны кайдан алырга

14. «М-7» өчен яңа кием. «Тормыш юлын» ничек итеп «шатлык юлына» әйләндерергә

20. Дингә юл – гыйлем аша. Болгар академиясеннән репортаж

26. Алекно феномены. Казан клубын дөньяда иң яхшысы иткән тренер турында

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
www.protatarstan.ru

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

32. Корычтай дуслык. Тыюлыклы урманнарны кемнәр саклый

38. Гореф-гадәтләребез. Татар мунчасы турында

42. Сәнгать. XXI гасыр филармониясе: ретромы, авангардмы?

46. «Үзгәреш җиле». Фикерләр

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

52. Йөз ел элек декабрьдә. Казанда кайда Яңа ел чыршысын куя торган булганнар

58. Аш-су осталары. «Туган-авылым» рестораны шеф-повары Яңа ел табынына нәрсә әзерли

64. Казан ханлыгы. Тәхет өчен көрәш

72. Китап киштәсе. Каһарманнарга сусау

76. Жюри карары. «Татарстан» журналының «Әдәби премия»се финалистлары кайчан билгеле була

84. Татар авыллары. Татарстан «Кырымы»

88. Шук-шаян ханым. Ни өчен Бичураны котыртырга ярамый

Фото: ООО «Ренессанс»

ЛИКВИДАЦИЯ КОЛЛЕКЦИИ

на каминные часы, мебель, картины, иконы, скульптуры из бронзы, столовое серебро, форфор, ювелирные украшения, монеты и т.д.

Антикварный салон «Ренессанс»

Казань, ул. Баумана 44/8
(Внутри КРЦ «Родина» 1-ый этаж),
(843) 567-10-66, +79600412341,
www.antik-renessans.ru,
инстаграмм: antiksalon

* Акция до 15.01.2018. Подробности на antik-renessans.ru г. Реклама.

PRESSA.RU

Реклама

сеть ювелирных салонов

ЭКСКЛЮЗИВ

Любви и счастья
в наступающем году!

РОСКОШЬ ПО ДОСТУПНЫМ ЦЕНАМ

СКИДКИ ДО 50%* | ПОДАРОЧНЫЕ СЕРТИФИКАТЫ

• Действуют карты других ювелирных магазинов • Кредит**

• Прием старых украшений по выгодным для Вас ценам

ул. Восстания, 62, тел.: (843) 564-77-67; ул. Р. Зорге, 67, тел.: (843) 268-94-95;
ул. Бутлерова, 29, тел.: (843) 238-42-50; ул. Чистопольская, 16/15, тел.: (843) 223-00-08;
тел.: (843) 223-00-09 (консультация геммолога);
www.exclusive-jewelry.ru; Instagram: exclusive.kazan

* До 30.01.2018. Размер скидки узнавать по указанным адресам и телефонам. Фото: ООО «Эксклюзив».
** Кредит предоставляется банками ЗАО «Русский Стандарт» лицензия № 2289 от 19.11.2014 и ООО «Хоум Кредит энд Финанс Банк» лицензия № 316 от 15.03.2012.

PRESSA.RU

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

15.11

Микко Хаутала, Финляндиянең Россиядәге Гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе, – Казан Кремлендә Татарстан Президенты белән очрашу вакытында:

– Без илчелектә Россиянең зуррак потенциалга ия булган төбәкләре белән актив эшләү стратегиясен сайладык. Татарстан Республикасы әлеге төбәкләр исемлегенә керә. Икътисадый бәйләнешләргә килгәндә, иң мөһиме шунда: Татарстанның көчле индустриаль базасы һәм зур мөмкинлекләре бар. Шунысы да әһәмиятле: сезнең республикада инде киләчәк икътисады – ясалма интеллект, стартаплар һәм башкалар актив үсә. Бу юнәлештә эшләп карыйсы килә.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

24.11

Михаил Бабич, Россия Президентының Идел буе федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиле, – ТРның Теләче районында яңа «Теләче – Арена» боз сарае ачылышында:

– Татарстанда дистә еллар буе кешеләргә хезмәт итәчәк спорт сарайлары төзү буенча бик тә мөһим һәм киң колачлы программа тормышка ашырыла. Бу Россиянең күп төбәкләре өчен үрнәк алырдай мисал.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

12.12

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты, – Казан Кремлендә, ТР Президенты каршындагы Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр советы утырышында:

– Татарстан – күп халыклар өчен уртак йорт. Аларга милли тәңгәллекләрен, мәдәниятләрен саклар өчен шартлар тудыру, халыклар арасында тынычлык һәм аңлашуны саклау – иң мөһим бурыч. Татарстанның да, Россиянең дә көче һәм куәте әнә шунда. Моның өчен республикада күп эшләр башкарыла.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Торак мәйдан белән тәэмин итү **НИЧЕК** бара

«Тормыш юллары» **НИЧЕК** итеп «шатлык юлларына» әйләнә

Болгар академиясендә укулар **НИЧЕК** оештырылган

Владимир Алекно өчен **НИНДИ** биеклекләр әле алынмаган

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ – **«ТАТАРСТАН»НЫ** УКЫ!

Газета-журналларга язылу кампаниясе дәвам итә. Безнең элекке дусларыбыз, киләсе яртыеллыкка да язылып, «Татарстан» журналы белән дуслыгын дәвам итә. Әлегә безнең белән булмаганнарга тиз арада безнең «Татарстан» коллективына кушылырга тәкъдим итәбез!

ЛАЕШ РАЙОНЫ

ТАТАРСТАНДАГЫ ҺӘР ЯХШЫ НӘРСӘНЕ ПОПУЛЯРЛАШТЫРУ – МӨҺИМ БУРЫЧ

Михаил Афанасьев,
ТРның Лаеш районы башлыгы:
– «Татарстан» журналы безнең өчен абруйлы һәм ихтирамга ия басма, исеме генә дә ни тора бит. Бүгенге көндә безнең республика – Россиядә аеруча үсеш алган төбәкләрнең берсе, нәтиҗәле дәүләт идарәсе һәм бар халыкларның тату яшәү үрнәге. Татарстанның алдынгы тәҗрибәсе РФ җитәкчелеге тарафыннан югары бәяләнә, шуңа күрә дә республика тормышын яктырту, аның кешеләрен ачу, безнең талантларны, нәтиҗәле идарә итүчеләрне күрсәтү – мөһим бурыч, һәм «Татарстан» аны уңышлы башкара. Мин басма коллективына бәхет, имин тормыш, уңышлар телим!

ЧИРМЕШӘН РАЙОНЫ

ВАКЫТ БЕЛӘН БЕР САФТА АТЛАУЧЫ ЖУРНАЛ

Фердинат Дәүләтшин,
ТРның Чирмешән муниципаль районы башлыгы:
– «Татарстан» журналы вакыт белән бер сафта атлый. Без аннан Татарстан Республикасындагы хәлләр турында актуаль мәгълүматларны табабыз, туган ягыбыз тарихыннан кызыклы вакыйгаларны беләбез, республикада яшәүче халыкларның традицияләре, яңа проектлар белән танышабыз. Журналның һәр укучысы үзенә аеруча кызыклы булган рубрикаларны, материалларны таба ала.

Реклама 16+

ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

Реклама 16+

2018 елның I яртыеллыгына

«Татарстан» журналына язылу дәвам итә

П 2381 **татар телендә** 900 сум 00 тиен

П 2378 **рус телендә** 900 сум 00 тиен

PRESSA.RU

КИЛӘЧӘК БУСАГАСЫНДА

2016 елда республикада бер кешенең уртача торак мәйдан белән тәэмин ителүе күрсәткечләре үсте һәм 25,6 квадрат метрга җитте, шулай итеп без Россиядәге уртача күрсәткечләрне узып киттек. «Татарстан» журналистлары әлеге метрларның чын мәгънәсендә кешеләрне сөендерүенә шаһит була алдылар.

Автор:
Ксения Сёмина

Һава шарлары белән бизәлгән подъезд каршында ике колонка тора, алардан ABBA төркеменең тантаналы җыры яңгырый. Җырда игътибар үзәгендә булудан һәм моңаймаудан да рәхәтрәк берни булмавы хакында җырлана. Әйе, нәкъ шартына туры китереп сайланган ул: берничә минуттан бергә җыелган халыкка тормышларындагы беренче фатирның ачкычын тапшырачаклар.

БАРЫСЫ ДА БАШЛАНА ГЫНА

Нурлатның Красноармейская урамында урнашкан 24 фатирлы йорт ятим балаларны торак белән тәэмин итү буенча республика Президент программасы кысаларында төзелгән. 2014 елдан эшли башлаган программа нигезендә шушындый берәр йорт ел саен тапшырыла.

– Сезне программада күрсәтелгән термин белән атарга телем әйләнми минем, – ди Нурлат районы һәм Нурлат шәһәре башлыгы Равил Кузюров, ярымтүгәрәккә тезелешеп баскан яшьләргә. Алар арасында булачак әниләр дә, инде әни булганнар да бар. – Районыбызда һәм республикабызда программа буенча бүлеп бирелгән акчалар үз мантыйклы нәтиҗәсенә китерсен һәм гражданнарның яшәү шартларын яхшыртсын өчен барысы да эшләнә. Бүген нәкъ менә сезнең яшәү шартларыгыз турында бара сүз.

Көчле алкышлар яңгырый, ачкычлар тапшырыла. Һәрберсе – ал брелоклы, аларның балкышыннан төксе ноябрь һавасына үзенә күрә бер яктылык таралгандай була.

Микрофон алдына җавап рәвешендә әзерләнгән сүзен әйтер өчен бер кыз чыгып баса. Кәгазьгә карамый сөйләнгән сүзләр, һич көтелмәгәнчә, ихлас һәм тормышчан яңгыраш ала:

– Бүген безнең бик тә бәхетле көнебез! – ди ул. – Без сезнең ышанычны акларга, үз өебезне яратырга һәм сакларга сүз бирәбез!

Тантаналы рәвештә тасманы кисәләр, һәм подъезд эче җанлы, шатлыклы авазларга күмелә.

Бер фатирның бусагасыннан күзләрен төбәп бер яшьлек сабый карап тора.

– Эмилия исемле ул, – дип елмая аның әнисе Гүзәл. Карап торышка ул әле үзе дә бала гына. – Ирем Артур бик яшьли әти-әнисез калган, аны әбисе тәрбияләгән. Икебез дә Нурлатныкылар. Туйдан соң кеше фатирында тордык. Тиз арада бергә күченербез, дип өметләнәм. Менә монда ди-

Фото: Александр Ефремов

ван куячакбыз, монда – шкаф, ә монда – бала караваты… Бар да әзер булгач, Артурның әбисен кунакка чакырырга ниятлибез. Ул безнең өчен бик сөенә инде!

Подъездда янәшә яшәүче ике хатын башкарма комитет вәкиленә йорт янындагы территорияне тәртипкә китерү буенча сораулар яудыра:

– Анда җимерек сарайлар тора. Аларны алып ташларлармы?

– Әлбәттә, борчылмагыз, – дип тынычландыра аларны чиновник ханым. – Без бу сорауны күз уңында тотарбыз.

Алар янәшәсеннән узып барган Равил Кузюров катгый тәкъдимнәр бирә: йортта яшәүчеләр янына беренче шалтырату булуга килеп җитәргә, барлык җитешсезлекләрне кичекмәстән төзәтергә. Барган җирдән генә безнең сорауларга да җавап биреп өлгерә ул:

– Ятим балалар өчен йортларны без авария хәлендә булган йорт мәйданнарында төзибез, шул рәвешле берьюлы ике республика программасын тормышка ашырабыз. Ышанам, дәүләт ятимнәргә алга таба да үз тормышларын җайга салырга булышыр. Алар – безнең киләчәгебез, кеше капиталы. Республика җитәкчелегенә безгә мондый программаларда катнашырга мөмкинлек биргәннәре өчен бик рәхмәтлемен. Татарстан Президент каршындагы Дәүләт торак фонды киләсе елга булган планнарыбызны да раслар, дигән өметтә калабыз, ул очракта шушындый тагын бер йорт төзергә ният бар – якты да, уңайлы да итеп…

19нчы сан астындагы фатирда ике пар – өлкән һәм яшь буын вәкилләре – булачак шартлар турында сөйләшә.

– Бу минем апам белән абыем – Гөлнур һәм Юныс Хәнәфиевлар, хәер, минем өчен алар әнием белән әтием шикелле, – дип, туганнары белән таныштыра Лиана Максимова. – Ә монысы – ирем Дмитрий. Без Самарада таныштык, мин шунда авыл хуҗалыгы академиясендә укыдым. Хәзер менә бирегә күчендек, монда тормышыбызны җайга салып җибәрергә ниятлибез.

– Дмитрий – автомеханик, аңа инде эш таптылар, – ди Лиананың «әтисе». – Лиана да менә-менә урнашырга тиеш. Без аның белән бик горурланабыз! Безнең йөзгә кызыллык китермәде, укуын да кызыл

1. Торак алучылар исеменнән чыгыш ясаучы Рамилә Гомәрова яңа йортта бәхетле яшәргә вәгъдә бирә.

2. Равил Кузюров һәм яңа йортның иң нәни хуҗасы тантаналы рәвештә тасманы кисәләр.

3. Гөлнур һәм Юныс Хәнәфиевлар, аларның кызлары Лиана ире Дмитрий белән көтеп алынган фатирларында.

4. Бу көнне Гүзәл һәм Артур Нуретдиновларга бирелгән иң популяр сорау кайсы җиһазны кая урнаштыру турында булды.

1


2


3


4

PRESSA.RU




1

1. Табиблар Резидә һәм Рим Шәйхиевләр Түбән Камага узган елның көзендә килеп урнашканнар, ә быелның җәендә инде фатирлы да булганнар.

диплом белән тәмамлады, яхшы кешегә кияүгә чыкты. Янәшәбездә яшәячәкләренә дә куанып бетә алмыйбыз.

– Безнең карамактагы кешенең эшкә урнаштырылган булуы бик кирәк, бу очракта аның коммуналь хезмәтләр өчен түләү мөмкинлеге дә булачак, шулай ук мөстәкыйль яши алачак. Әмма ятимнәрнең эшкә урнашу белән кыенлыклары килеп туса, без һәрвакыт булышырга тырышабыз. Эшкә урнаштыру мәсьәләсе – принципиаль мәсьәлә, бигрәк тә яшьләр торакны исәпкә куелган җирдә сайламаса, әйтик, Алабуга, Казан, яки Арча районында яшәргә кирәк тапса. Агымдагы елда андый гариза белән мөрәҗәгать итүчеләр дүртәү булды, – дип сөйли опека бүлеге җитәкчесе Ирина Савинова.

Федераль программа буенча ятим балалар өчен фатирлар 2008 елда төзелә башлый, исәпкә кую белән фатирны алу арасындагы аерма шактый сизелерлек була. 2014 елда республика программасы барлыкка килә дә көтү вакыты акрынлап кими. Федераль закон нигезләре буенча, программада катнашучыга исәпкә басу моментында 18 яшь тулган булырга тиеш, әмма яшенең 23тән артмавы да шарт. Торакны алуның төгәл вакыты программада күрсәтелми. Катнашучы коммуналь хезмәтләр өчен генә түли, ә ун елдан соң, программа шартлары үтәлгән очракта, фатирның хуҗасы да була ала.

– Күпләр фатир алу вакыты килеп җиткәнче үк, гаилә төзеп өлгерә: безнең яңа гына фатирлы булучыларыбыз арасында инде әни, әти булучылар җитәрлек, бер яки икешәр балалары бар кайберләренең. Федераль һәм республика җитәкчелегенең зур игътибары нәтиҗәсендә программа бик тә актив рәвештә тормышка ашырыла. Татарстанда гына ел саен яңа фатирларга 300дән артык яшь кеше кереп урнаша. Дүрт ел элек, программа старт алган гына чакта, Нурлат районында торакка мохтаҗ 200 кеше исәптә тора иде. Хәзер аларның саны 70тән артмый, – дип ачыклык кертә Ирина Савинова.

Ул арада тантана сүрелә төшә. Әмма Красноармейская урамындагы йорт тәрәзәсеннән, әтисе белән әнисе кочагына сыенып, безгә кул болгап калган Эмилия өчен, киресенчә, барысы да башлана гына.

РӘХӘТЕН КҮРЕП ЯШӘГЕЗ!

Ачык чырайлы һәм ап-ак халатлы яшь белгеч үзе дә, Түбән Кама шәһәренең 2нче номерлы хастаханәсендәге заманча җиһазланган эш кабинеты да беренче карашка чит илдәге затлы, дәрәҗәле медицина үзәгенең реклама сүрәтеннән сикереп төшкәндәй тоелдылар. Шулай да чын булып чыктылар. Бары монда бу нәтиҗәгә ирешү өчен күп көч куйганнар, шул гына: медицина ярдәме кешеләргә барып ирешсен, уңайлы, һәм иң мөһиме – профессиональ булсын өчен.

Кан басымы күтәрелүдән интегәм, дип, күренергә килгән пациентны кабул итү тәгәлләнә. Тиешле дәва ысулларын билгеләгәч, врач-терапевт Рим Шәйхиев болай дип тә өсти:

– Суык тиюләр вакыты башлана, профилактика турында онытып җибәрә күрмәгез. Рационыгызда күбрәк яшелчәләр булсын, фатирыгызны ешрак җилләндерегез, һава алышынсын, үзегез дә саф һавада йөрегез...

Пациент, саубуллашып, ишеккә юнәлә. Ул бик канәгать күренә. Римның кабул итү сәгате тәгәлләнә. Шул вакытта ишектә бер ханым пәйда була:

– Талон ала алмадым, кабул итәрсезме икән?

Рим аны кирәргә өнди. Пациентны кире боруны ул әдәпсезлеккә саный.

Сменасындагы соңгы пациент киткәч кенә, хатыны Резидәне каршыларга юнәлә ул. Хатыны да биредә эшли – ул Перинаталь үзәге булган балалар шәһәр хастаханәсенең акушер-гинекологы. Резидә дә кабул ителергә тиешле, ә кайчак киңәш сорарга дип тә килгән күпсанлы булачак әниләрнең һәрберсен тыңлап-карап бетермичә сменасын тәмамламый.

Алар яңа йортта яшиләр. Фатирлары да Түбән Камага элеккеге елларда килгән яшь белгечләр урнаштырыла торган төссез, кысан бүлмәле күпкатлы тартмаларныкыннан аерылып тора.

– Резидә белән без Ижевскида Медицина академиясендә укыганда таныштык. Ул Зәй районыннан, Татарстаннан, мин – Киров өлкәсе Вятские Поляны бистәсеннән. Укуны тәмамлагач, эшкә урнашу мәсьәләсе алга килеп басты. Түбән Каманы, беренчедән, һөнәри яктан әйбәт перспективалар тәкъдим ителгәнгә, икенчедән, табиблар өчен республика грант программасы буенча торак бирелгәнгә сайладык, – дип сөйли Рим.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов 2013 елда гамәлгә керткән әлеге программа шартларына килсәк, белгеч-табиб, Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы бәйгесендә катнашып, торак шартларын яхшырту өчен 500 мең сумлык сертификат алырга хокуклы. Белгеч бу сертификатны социаль ипотекага беренче кертем буларак файдалана ала. Аннан, коммуналь хезмәтләр өчен генә түләп, үзе тәгаенләнгән медицина

Фото: Олеся Бондаревская

учреждениесендә биш ел эшләгәч, ул торакның хосусый милек иясе була ала.

– Сертификатларыбызны шушы фатирга керттек, туган шартларга бик сөенәбез. Шәһәргә узган ел көз килеп урнаштык, быелгы августка – фатир тапшырылганга кадәр, торак арендалап тордык. Эше күп калмады инде, җиһазларны да юнәтеп бетердек диярлек, – ди Рим. – Өебез уңайлы, җылы, күршеләр нәкъ безнең кебек үк табиблар. «Гаилә» ял паркына – бик якын, чаңгы трассасы да янәшә – кышын атнасына ике-өч тапкыр чаңгыда йөрергә чыгабыз. Бөтен инфраструктура каралган. Сине шулай каршы алалар икән, бу ышанычны аклап эшлисе килә. Булдырам шикелле: ике терапия участогы бүлеп бирделәр, укуы вакытында бүлек мөдирен алыштырып торам, менә.

Районда табибларны торак белән тәэмин итү юлы белән кызыксындыруга 2009 елда ук керешкәннәр. Соңгы биш ел эчендә Түбән Кама сәламәтлек саклау системасына 91 фатир тапшырылган. 2014 елда торакка грантларын 19 белгеч файдаланса, 2015 елда – 13, 2016 елда – 15, ә быел инде аларның саны 17не тәшкил иткән. Грант программасыннан тыш, медицина хезмәткәрләре өчен торакны арендага алу программасы да эшли, шуңа фатир өчен чиратта торучылар юк. 2016 елда эшкә керешкән 37 табибның 21е инде фатир белән тәэмин ителгән, тагын алтысы быел тәэмин ителеп өлгерәчәк.

Чагыштырмача кыска гына вакыт эчендә Түбән Кама сәламәтлек саклау учреждениеләрендәге ачык вакансияләрнең исәбе 180нән (2012 ел) 110 га (2015 ел) кадәр кыскарган. Узган ике елда районга тагын 63 белгечне кабул иткәннәр, якын арада биредә югары звенодагы медицина хезмәткәрләренә кытлык бетәчәк. Шәһәр белән район өчен бу бик тә әһәмиятле: Түбән Кама муниципаль районының үсеш стратегиясендәге пунктлар арасында сәламәтлек саклау системасын этаплап яңарту, бала туу санын арттыру һәм эшче халыкның башка төбәкләргә китүен туктату бар.

Табибларны торак белән тәэмин итү – ул мөстәкыйль процесс кына түгел, ә Түбән Кама шәһәре



белән районындагы торак төзү программасын тормышка ашыруның күп елларга сузылган киң колачлы юнәлеше дә. Әгәр 2016 елда 100 мең квадрат метр торак кулланылышка тапшырылса, 2017 елда инде бу сан 130 мең квадрат метрга (15 йорттан 1500 фатир) җиткән. Авыл җирендә исә шәхси торак төзелеше киң кулланыла – агымдагы елда гына 20 мең квадрат метрдан артык күләм тапшырылган. Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү программасын тормышка ашыруга зур игътибар бирелә. Әлеге юнәлеш гаять перспективалы: исегезгә төшерәбез, ноябрьдә РФ Президенты Владимир Путин яңа программа тәкъдим итте. Аның буенча якындагы биш ел эчендә икенче һәм өченче бала алып кайтырга җыенган гаиләләр дәүләт ярдәме каралган ипотека кредитына өметләнә ала. Дәүләт өч яки биш ел дәвамында аларның ипотека буенча процентларының бер өлешен түләп барачак. «Торакны беренчел базардан яисә элегрәк алган ипотека кредитларына рефинанс ясау ысулы белән юнәткән гаиләләр дәүләттән елына 6% ставка буенча субсидиягә өметләнә ала», – диде Владимир Путин.

– Түбән Камада җан башына исәпләгәндә, торак белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе республиканың уртача күрсәткечләренә якынлашып килә, – ди Түбән Кама Башкарма комитетының торак сәясәте бүлеге җитәкчесе Илнар Бәдретдинов. – Төзелеш эшләре республиканың төзелеш министрлыгы, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды химаясе астында бара. Темпларны көчәйтү исә җитештерүне киңәйтүгә һәм яңа предприятиеләр барлыкка килүгә бәйле. Бу елда, мисал өчен, эре социаль ипотека проекты төгәлләнде: 47нче «нефтьчеләр микрорайоны»ндагы 20 йортның 7 се тапшырылды. Алар 2014 елда төзелә башлаган иделәр.

Кондиционер
с установкой всего за 21000 руб.*
Доставка, консультация специалиста бесплатно
297-59-72
ООО «Бюро Погоды-Сервис» ОГРН 1041628206308 *до 31.12.17. Реклама.

PRESSA.RU

ТАТАРСТАНДА РЕСПУБЛИКА ҺӘМ ФЕДЕРАЛЬ ПРОГРАММАЛАР КЫСАЛАРЫНДА ТОРАК ТӨЗЕЛЕШЕ

«Салават күпере» микрорайоны

ТОРАК ТӨЗЕЛЕШЕ

	2010–2015 еллар	2016 ел	2017 ел (план)	2017 ел (18 декабрьгә)
Торак тапшыру, мең кв. м	14 033,6	2 406,5	2 402,0	2 193,8 (еллык планнан 91,3%)

СОЦИАЛЬ ИПОТЕКА

	2015 еллар	2016 ел	2017 ел (план)
Фатирлар саны	4 905	6 267	9 876
Мәйданы, мең кв. м	323,0	373,6	526,1

КҮПФАТИРЛЫ ИНВЕСТИЦИЯЛЕ ТОРАК

	2010–2015 еллар	2016 ел	2017 ел (план)
Йортларның саны	640	85	111
Мәйданы, мең кв. м	4 953,8	1043,1	881,9

Фото: Александр Ефремов

АЗКАТЛЫ ТОРАК ТӨЗЕЛЕШЕ

	2010–2015 еллар	2016 ел	2017 ел (план)
Йортларның саны	56 036	8 998	8 800
Мәйданы, мең кв. м	6 164,1	989,8	994,0

АРЕНДАГА ТОРАК

	2016 ел	2017 ел (план)
Йортларның саны	354	379
Мәйданы, мең кв. м	21,2	22,6

2015–2020 ЕЛЛАРГА «ТОРАК» ФМПНЫҢ «РФ СУБЪЕКТЛАРЫНЫҢ ТОРАК ТӨЗҮ ҮСЕШЕН КӨЧӘЙТҮ ПРОГРАММАЛАРЫ» ПОДПРОГРАММАСЫ

2016 ел	2017 ел
Бүлеп бирелгән **654,3 млн сум,** шул исәптән РФ бюджетыннан – **458,01 млн сум,** ТР бюджетыннан – **196,29 млн сум**	Бүлеп бирелгән **2 559,24 млн сум,** шул исәптән РФ бюджетыннан – **1 791,47 млн сум,** ТР бюджетыннан – **767,77 млн сум**

PRESSA.RU

Фото: Александр Ефремов

«ТОРМЫШ ЮЛЫН» НИЧЕК «ШАТЛЫК ҺӘМ БӘХЕТ ЮЛЫНА» ӘЙЛӘНДЕРЕРГӘ

Октябрь ахырында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Россия Президенты ярдәмчесе Игорь Левитин, Федераль юл агентлыгы (Росавтодор) җитәкчесе урынбасары Андрей Костюк, ТР Транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Ленар Сафин М-7 «Идел» федераль трассасының реконструкцияләнгән ике участогында берьюлы автомобиль хәрәкәтен ачты. Быел ике буйлыдан дүрт буйлыга әйләнгән юлның гомуми озынлыгы 30 километрны тәшкил итте.

- Заманча асфальт-бетоннан эшләнгән нык юл полотносы зур авырлыкларга һәм теләсә нинди һава шартларына чыдарлык күпкатлы «мендәр» өстенә ышанычлы итеп урнаштырылган.
- Су үткәрә торган торбалар конструкцияне – юылудан, ныгытылган сөзәк ян-яклары исә ишелүдән саклый.
- Җиһазландырылган сулга борылып төшү юллары һәм төрле югарылыктагы ике юл чишелеше маневр ясау өчен җитәрлек мөмкинлек бирә.
- Участоклар җир өсте җәяүлеләр кичүе һәм җәмәгать транспорты өчен павильоннар белән җиһазландырылган.
- Трасса чикләре 1600 дән артыграк сигнал баганасы белән билгеләнгән, озынлыгы 35 мең метрлы металл барьер куелган. 340 яктырту тереге һәм 600 юл билгесе дә имин хәрәкәтне оештыруга булыша.



PRESSA.RU

888нчедән 901нче километрга кадәр участокны ачу тантанасы.

Автор:
Алсу Троицкая

ИМИН ЮЛЛАР ИЛ ИКЪТИСАДЫН ҮСТЕРЕРГӘ МӨМКИНЛЕК БИРӘ

– Бу юлны элек «тормыш юлы» дип йөртәләр иде, – диде Игорь Левитин. – Киләсе елда без калган өч участокны да файдалануга тапшырырга планлаштырабыз, һәм М-7 машина йөртүчеләр өчен «шатлык һәм бәхет юлына» әйләнәчәк…

– Без тыгыз хәрәкәт барган М-7 трассасының үзебез өчен әһәмиятле ике участогын ачабыз, – дип басым ясады Рөстәм Миңнеханов. – Киләсе елда юлны тулысынча реконструкцияләп бетерәчәкбез… Бу – имин юллар. Бу – республика икътисадын, димәк, бөтен илебез икътисадын үстерергә мөмкинлек бирә торган юллар. Әлеге ике участокка гына да 10 миллиард сум инвестиция-ләнде, һәм кертелгән һәр сум юлның сыйфатын шактый яхшыртырга ярдәм итте.

Татарстан Президенты юл төзелешендә катнашучыларга – «НТПИ ТИ» ЯАҖ, «Каздорстрой» ААҖ, «Алексеевскдорстрой» АҖнә сыйфатлы һәм вакытында эшләнгән эшләре өчен рәхмәт белдерде. Аеруча тырышып эшләгәннәргә федераль дәрәҗәдәге һәм республика бүләкләре тапшырылды.

Трассаны беренче булып ретроавтомобильләр һәм төзелеш техникасы «сынап карады».

ИКЕ БУЙЛЫДАН – ДҮРТ БУЙЛЫГА

ТР Балык Бистәсе районының Яңа Арыш авылыннан ерак түгел үткән 888нчедән 901нче километрга кадәрге участокта эшләр 2015 елның февралендә үк башланган булган. Асылда тулы масштаблы яңа юл төзелеше турында бара сүз. Әгәр элегрәк II техник категориядәге юлның 13,5 километрлы әлеге өлеше 9 метр киңлектәге ике буйлы трасса булып, андагы хәрәкәт ешлыгы тәүлегенә 11 мең машинадан артмаса, хәзер бу дүрт буйлы (һәр юнәлештәге икешәр буйлы, араларында 6 метрлы аергыч буйлы) IБ категорияле заманча автострада сәгатенә 6 меңнән артыграк автомобильне үткәрә ала. Хәрәкәтнең перспективадагы ешлыгы тәүлегенә 25 мең автомобильгә җитә.

МАГИСТРАЛЬНЕ ТУРАЙТКАЧ, ТИЗЛЕКНЕ ЧИКЛӘҮ БЕТЕРЕЛӘ

941нче километрдан алып 957нче километрга кадәр булган икенче участокның бер өлешен юл төзүчеләргә өр-яңадан салырга туры килгән. 7,8 километр озынлыктагы юл төзелгән. Магистраль турайгач, күз күреме чикләнгән участок юкка чыккан һәм элек сәгатенә 50 километр белән генә барырга рөхсәт иткән чикләү алынган.

PRESSA.RU

УҢАЙЛЫЛЫК ҺӘМ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫКНЫҢ **НИГЕЗЕ**

«Волго-Вятскуправтодор» ФКУ Россиянең дүрт субъектында инде 15 елдан артык федераль автомобиль юлларын һәм алардагы ясалма корылмаларны төзү, төзекләндерү, ремонтлау буенча дәүләт заказларын үти. Ул Татарстан, Марий Эл, Удмуртия һәм Ульяновск өлкәсендәге 1773 км дан артык автомобиль юлына хезмәт күрсәтә. Юлларның төп өлеше (1038 километр тирәсе) безнең республика территориясендә урнашкан.

Федераль юл агентлыгының Идел-Нократ төбәге автомобиль юлларының федераль идарәсе башлыгы Илдар Минһаҗев «Татарстан»га федераль автомобиль юлларының торышы, яңа технологияләр, юлларны үзгәртеп төзү һәм юл хәрәкәтен оештыру планнары турында сөйләде.

– Илдар Галәветдинович, сезнең идарә карамагындагы юлларның техник торышын яхшырту өчен узып баручы елда ниләр эшләнде?

– Эшебезнең нәтиҗәсе, образлы итеп әйтсәк, аяк астында. Дөресрәге, көн саен федераль трассалар буйлап чабучы меңәрләгән автомобиль тәгәрмәчләре астында. Безнең идарә Мәскәү – Владимир – Түбән Новгород – Казан – Уфа «Идел» М-7 автомобиль юлында гаять зур эш башкара. Белгәнегезчә, бу – Россия башкаласын Идел буе федераль округы һәм Урал буе регионнары белән бәйли торган иң мөһим илкүләм автомагистральләрнең берсе. Татарстан Республикасында аның озынлыгы – 430 км дан артык. Тотрыклы финанслау ярдәмендә, узып баручы елда әлеге автомобиль юлының Казан – Чаллы өлешендә гомуми озынлыгы 30 км тирәсе булган ике участокны үзгәртеп төзүне тәгәлләдек. Бу юл өслеген генә җәю дигән сүз түгел. Моңа әле тагын юл читләрен асфальт-бетон белән ныгыту, цинкланган металл киртәләр, сигнал һәм электр баганалары, юл билгеләре урнаштыру, юл өсте һәм юл асты җәяүле кичүләре корылмалары төзү, куркынычсызлык утраулары, машина йөртүчеләр өчен ял итү мәйданчыклары һәм тукталыш павильоннары ясау да керә. Әлеге төзелеш объектларының гомуми бәясе 1 млрд сум тирәсе тәшкил итте. Бүген Татарстан Республикасында дүрт юл хәрәкәте полосасы булган 1 нче техник категорияле «Идел» М-7 трассасы участокларының озынлыгы – 255 км. Ә бу – аларда йөрү күпкә уңайлырак һәм куркынычсызрак дигән сүз.

Бүген «Идел» М-7 автомобиль юлының Казан – Чаллы өлешендәге гомуми озынлыгы 31,1 км булган тагын өч участокта үзгәртеп төзү эшләре дәвам итә. План буенча без аларны киләсе елның августына кадәр тәгәлләргә ниятлибез. Шул рәвешчә, 2018 елның җәендә юл төзүчеләр өчен генә түгел, бу трассадан файдаланучылар өчен дә зур шатлыклы вакыйгага булачак.

– Республикабызның көньяк-көнчыгыш юлларында йөрүче автомобильчеләр Яңа Чишмә районының Ленино авылы янындагы Чишмә елгасы аша салынган күпердән чыгу җайга салынды, светофорның яшел утын хәзер инде озак көтәргә туры килми, диләр.

– Әйе, капиталь ремонттан соң бу күпернең машина йөри торган өлеше 10 метрга кадәр киңәйтелде. Хәзер анда машиналар бер үк вакытта кара-каршы ике полоса буйлап хәрәкәт итә ала. Сүз уңаеннан, бу – Россиянең бөтен федераль юллар челтәрендә 100 елдан артык файдаланыла торган бердәнбер күпер! Ленино авылында яшәүчеләрнең күбесе юл буе сәүдәсе белән шөгыльләнә, шуңа күрә хәрәкәтне туктатмыйча гына күперне ремонтлый алуыбыз

Фото Александр Ефремовтан, «Волго-Вятскуправтодор» ФКУ архивыннан алынды.

Реклама

алар өчен уңайлы булды. Биредә без индивидуаль рәвештә проектланган, корыч-тимер-бетоннан ясалган, бөтен килеш китертелә торган өрлекләрдән күпер аралыклары төзү буенча инновацион технологияләр кулландык. Тагын шуның кадәр ел хезмәт итәчәк әле ул, дип уйлыйм…

Быел шулай ук Татарстан Республикасында «Идел» М-7 трассасындагы озынлыгы 1000 метрдан артып киткән иң зур күперне ремонтлау да тәгәлләнде. Биредә көйләү корылмалары, яр буе ныгытмалары ремонтланды, тирбәнеш авырлыкларына чыдам, ASFALIT гранит композициясен кулланып эшләнгән яңа түшәмә салынды. Аннан файдалану ремонт араларындагы срокларны озайту һәм күпер кичүеннән файдалану өчен киткән чыгымнарны киметү мөмкинлеге бирә. Үләмә, Солонка елгалары һәм Казан – Оренбург –Акбүләк – Казахстан Республикасы чиге Р-239 автомобиль юлының 261+706 километрындагы инеш аша салынган күперләр тәртипкә китерелде.

– Юллардагы автомобильләр саны даими арта бару белән, юл материалларына, технологияләргә дә таләпләр арта. Юл төзелешендә «Волго-Вятскуправтодор» ФКУ нинди инновацион технологияләр куллана?

– Дөрестән дә, җитештерү эшчәнлегенең уңай нәтиҗәләр бирүе күп очракта заманча алдынгы технологияләрдән файдалану белән бәйле, алар арасында юл өслекләренең салкын регенерациясен, вак ташлы асфальт-бетон катнашмасын һәм 3Д-системаларын куллану да бар. Мәсәлән, Яшел Үзән районында «Идел» М-7 трассасындагы юл төенен ремонтлаганда безнең белгечләр асфальт-бетон катнашмаларын проектлауның яңа ысулын кулландылар. Ул асфальт-бетонның катырак каркасын китереп чыгарырга һәм деформацияләнүне бетерергә ярдәм итә. Әлеге системаны куллану өслекнең һәм тулаем юлның хезмәт итү вакытын арттырырга мөмкинлек бирә.

Барлык регионнарда да чокырланып торуны бетерү өчен коелган асфальт-бетон һәм эмульсияле вак таш катнашмасы кертү технологиясе үзләштерелде. Чатнаган урыннарны төзәтү өчен мастика кулланыла, һәм бу юлларның сыйфатын яхшыртырга сизелерлек ярдәм итә.

Юл төзүчеләрнең эше, белгәнегезчә, ел әйләнәсендә, тәүлекнең теләсә кайсы вакытында, теләсә нинди һава торышы шартларында бара. Кыш тотрыксыз булган чорларда, күп кар яуган һәм бозлавык барлыкка килгән вакытларда аеруча кыен була. Һәм биредә шулай ук инновацион технологияләр ярдәмгә килә. Республикабызның федераль трассаларында урнаштырылган 40 юл метеостанциясе һәм видеокүзәтү комплексы явым-төшемле көннәргә вакытында игътибар итәргә мөмкинлек бирә. Алардан алынган мәгълүмат юл өслеге торышын һәм машиналарның реаль вакыт режимында йөрү шартларын бәяләргә генә түгел, алдагы 2–4 сәгать эчендә нинди һава шарты булачагын фаразларга да ярдәм итә.

Татарстан автомобильчеләре өчен тагын бер күңелле яңалык. Әйткәнемчә, киләсе елда без «Идел» М-7 автомобиль юлының Казан – Чаллы өлешендәге тагын өч участокта эшне дәвам итәчәкбез һәм анда йөрүчеләр өчен уңайлылык һәм куркынычсызлык тудыру өчен мөмкин булганның һәммәсен дә эшләячәкбез.

2017 елда Татарстан Республикасында федераль юл төзүчеләр тарафыннан 107,275 км юл төзекләндерелде, шул исәптән 14 км федераль юл капиталь ремонтланды.

Бу эшләрнең зур өлеше Казан-Оренбург-Акбүләк-Казахстан республикасы чиге Р-239 автомобиль трассасында башкарылды. Мәсәлән, трассаның Лаеш районы Сокуры авылы аша узучы 27 нче – 30 нчы километры участогында хәзерге заман технологияләре ярдәмендә машина юлы киңәйтелде һәм гамәлдәге юл өслегенең сыйфаты көчәйтелде. Автомобильчеләр һәм Сокуры халкы куркынычсызлыгына аеруча зур игътибар бирелде – гомуми белем бирү мәктәбе янында светофор куелды, бөтен авыл чикләрендә тротуарлар җәелде.

ДИНГӘ ЮЛ – ГЫЙЛЕМ АША

Ислам академиясе бинасыннан машинага чыгып утыргач, фотографыбыз: «Җәннәттә булып чыктык, әйдә, хәзер үзебезгә кайтыйк», – диде. Әллә миңа гына шулай тоелганмы дигән идем, юк икән – биредә күңелгә тынычлык иңә, җан белән тән тулы гармониягә килә. Югыйсә бит уку йорты гына... Хәер, уку һәм яшәү шартлары буенча бу кадәр уңайлы булган уку йорты Россиядә генә түгел, дөньяда да бүтән юк. Сүзем Болгар ислам академиясе турында.

Ислам академиясе булдыруга дәгъва кылучы төбәкләр һәм шәһәрләр берничә иде – Дагыстан, Чечен Республикасы, Мәскәү, Санкт-Петербург, Уфа. Татарстан Республикасы җитәкчелеге Россия Хөкүмәте белән сөйләшүләр алып барганнан соң Болгар шәһәре җиңеп чыкты. Мондый карарга килүнең төп сәбәбе тарихка бәйле – 922 елда бабаларыбыз Болгар җирендә ислам кабул иткән.

Бүгенге көндә Болгар ислам академиясендә 68 кеше белем ала. Аларның 16сы докторантурада, калган 52се магистратурада укый. Академиянең максаты – ислам кануннарын тирәнтен өйрәнергә теләгән мөселманнарга үзебездә белем бирү, ислам дөньясында абруйлы уку йортлары бирә торган гыйлемне Россиядә, ягъни Болгар ислам академиясендә укыту.



Автор:
Руфия Фазылова

«БИШЕНЧЕ ЮГАРЫ БЕЛЕМ АЛАМ»

Ислам академиясе тыштан хан сарайларын хәтерләтә: олпат, мәгърур, затлы. Эчкә узгач, XX йөз башына кайткандай буласың: башларына кәләпүш, өсләренә казаки кигән шәкертләр йөри, азан тавышы яңгырый. (Без килгәндә намаз вакыты иде). Ишектән узгач та, зур, стеналары бизәкле актлар залына эләгәсең. Барысы да заманча... Искиткеч! Гомумән, Болгар ислам академиясе төзелүнең тизлеге, масштабы үзе бер могҗизага тиң. 2016 елның 21 маенда нигез ташы салынган бина 2017 елның сентябрендә студентлар кабул итте. Академия белән танышып чыкканнан соң шаккатасың: ничек бер ел эчендә бу кадәр зур бинаны төзеп, аны күркәм, уңайлы да итәргә мөмкин?

Биредә шәкертләр укый да, яши дә. Дәресләрдән соң каядыр чыгып йөрергә кирәк түгел – лекция бетте, күрше бүлмәдәге спортзалга, йә булмаса китапханәгә барырга була. Намаз бүлмәсе, мунча, ашханә дә шунда гына. Икенче

Фото: Лилиана Вәлитова


Әмир Билалов

катта һәр студентка аерым бүлмә. Фикер алышу, китап укыр өчен дә махсус урыннары бар. Һәм болар барысы да – бушка!

– Мондый уку йорты буладыр дип күпләр уйлап та карамыйдыр, – дим безне академия буйлап йөрткән Әмир Билаловка.

– Әйе, мондый уку йортлары дөньяда да юк. Бишенче югары белемемне алам, тәгаен әйтә алам...

– Бишенче?! – дим, гаҗәпләнүемне яшерә алмыйча. – Барысы да ислам кануннары буенчамы?

– Беренче югары белемем буенча мин – юрист, калганнары барысы да – дини...

– Бу кадәр уку сезгә нигә кирәк? – дип сорарга теләгән идем, әле ярый эндәшмәгәнмен. Әмир, минем уйларымны укыгандай:

– Кеше белем алудан туктарга тиеш түгел. Күпме генә өйрәнсәң дә, бар нәрсәне белеп бетереп булмый, – дип җавап та биреп өлгерде.

Әмир Билалов Себер егете – Омск шәһәрендә туып-үскән. Туган ягында ике уку йорты, Казанда – Россия ислам институтын тәмамларга өлгергән. Аннан Фес шәһәрендә (Марокко) «әл-Карауиййин» университетында укыган. Әлеге уку йортын ислам дөньясында яхшы беләләр, ул иң дәрәҗәлеләрдән санала.

Әмир Фес шәһәрендә бары тик гарәп телендә генә укыган, аралашкан. Җирле халыкның яшәешен өйрәнгән.

– Мароккода халык бик гади һәм дини, – ди ул. – Мисал өчен, биш яшьлек балалар Коръәнне яттан өйрәнә, аның каравы укый-яза, куша-ала белми. Ул яктан мин аларны кызгандым да. Үсәргә, югары белем алырга гади халыкка бик авыр, мөмкин түгел, дисәң дә була.

Әмирне шулай ук Марокко халкының байлыкка табынмавы да гаҗәпләндергән. Бездәге кебек өсте-өстенә кием, җиһаз алу юк икән. Алмашка бер кием, ашарга өстәл, йокларга диван булса – җитте.

– «әл-Карауиййин» университетында гарәп телем яхшырды, анда барып укуыма бер генә дә үкенмим, – диде Әмир Билалов. – Докторлык эшемне гарәп телендә язачакмын. Хәер, Болгар ислам академиясендә укучы һәр шәкерт фәнни хезмәтен гарәп телендә эшләячәк. Бу төп шарт булып тора. Укулар да нигездә гарәпчә бит. Дөрес, аерым фәннәр рус телендә дә алып барыла.

«БЕЗ БАРЫБЫЗ ДА – СПОРТЧЫЛАР!»

Әмир хәзрәт безне спортзалга алып керде. Шунда ук мунчасы да бар. Ике шәкерт тренажерларда шөгыльләнә иде. Алар, бер дә

PRESSA.RU

кыенсынмыйча, камера алдында үзләренең көчләрен күрсәттеләр, безнең белән теләп аралаштылар.

– Без барыбыз да – спортчылар, – ди Дагыстаннан килгән Рамазан Исаев. – Кечкенәдән самбо белән шөгыльләндем. Хәзер дә спортның бу төреннән аерыла алмыйм. Спортзал, дәресләр беткәч буш тормый, мин үзем монда кермичә калмыйм диярлек. Намаз җанга кирәк булса, физик күнегүләр тән өчен бик мөһим.

Ислам академиясендә Дагыстаннан 7 шәкерт укый икән. Аларны бирегә җирле Диния нәзарәте җибәргән. Академия тәмамлаганнан соң шәкертләр, үзләренә кайтып, Дагыстан мөселманнарына югары белем бирергә тиеш булачаклар.

Спортзалдагы икенче шәкерт – Ильяс Әхмәтшин белән дә таныштык. Разянь өлкәсенең Касыйм шәһәреннән икән. Шәкертнең камил татарчасына игътибар иттем:

– Әти-әнием өйдә татарча гына сөйләште, – диде егет. – Безнең Касыйм шәһәрендә якынча дүрт мең татар яши, туган телебездә аралашырга тырышабыз.

Ильяска 28 яшь. Башта Разянь өлкәсендә юрист һөнәрен үзләштергән, югары белем ал-

Рамазан Исаев

ган. Аннан, Казанга килеп, Россия ислам институтын тәмамлаган. Һәм зур сынаулар аша Ислам академиясенә эләккән.

– Монда белем алу – зур дәрәҗә, – ди Ильяс. – Яшерен-батырын түгел, күпләр сынауларны уза алмады. Академиягә укырга керер өчен компьютерда гарәп телендә тест тапшырдык. Аннан үз кызыксынуыбыз турында гарәпчә инша яздык.

– Укулар ничек, җиңел биреләме? Авырмы? – дим.

– Җиңел димәс идем, минем чит илләрдә алган тәҗрибәм юк. Шулай да сер бирмим, тырышам. Кайбер әйберләрне тәҗрибәле шәкертләрдән дә сорыйм. Бирегә бер-береңә ярдәм итү дигән әйбер бик көчле. Беренче көннән үк шулай куелды. Дәрестә аңлап бетермәдең икән, курсташыңнан сорыйсың.

«АЛАР МИНЕМ УЛЛАРЫМ...»

Академиядә укучы шәкертләр арасында, Дагыстаннан кала, Уфадан, Әстерхан, Пенза өлкәләреннән килүчеләр бар. Киләчәктә, һичшиксез, география киңәячәк. Ә быелгы «беренче карлыгачларның» күбесе – Россия ислам институтын тәмамлаган шәкертләр, аларның иң яхшылары дип әйтергә кирәктер.

Академия укытучылары арасында өч чит ил мөгаллиме дә бар. Шуларның берсе – доктор әс-Сәгъди – ислам дөньясындагы бик абруйлы шәех. Икенче мөгаллим – Исмаил Бульбуль, 11 ел Палестина мөфтие булып торган, атаклы ислам академияләрендә укыткан кеше ул. Өченчесе, Хәмделла Сафти, чагыштырмача яшь булуына карамастан, Мисырда – Каһирәдә укыткан белемле доктор. Киләчәктә тагын югары




Исмаил Буль-Буль

халыкара дәрәҗәгә ия 10–15 чит ил укытучысын җәлеп итәргә җыеналар.

Без исә Исмаил Буль-Буль әфәнденең дәресенә кердек. Атаклы профессор рус телен белми икән. Ләкин укыту гарәп телендә алып барылганлыктан, бу ике арада бернинди каршылык та тудырмый. Шәкертләр дә гарәпчә яхшы укый-яза, сөйләшә бит. Исмаил әфәнде бик күңелле кеше, көлә-көлә сөйләште. (Аралашырга Әмир Билалов ярдәм итте.)

– Студентларның белем дәрәҗәсе ничек? Сезнең тәҗрибә зур бит. Чагыштырып әйтә аласызмы? – дим.

– Төрлечә. Алар бит төрле югары уку йортларында белем алганнар. Тик мин борчылмыйм: тырышлыклары күзгә күренеп тора. Алла боерса, югары дәрәҗәләргә ирешәчәкбез.

Исмаил әфәнде тормыш иптәшен дә бирегә алып килгән, алар Болгар шәһәрендә яшиләр. Җирле халык турында:

– Ачык кешеләр, гадиләр, – диде ул. – Студентларымны улларым урынына күреп яратам. Һәркайсына ярдәм итәсем килә.

Палестинадан килгән атаклы мөгаллим татарча, русча да берничә сүз өйрәнгән.

– Җитәкчелек кирәк дип тапса, мин моннан китәргә уйламыйм әле, – ди. – Шулай булгач, киләсе очрашуда сезнең белән татарча сөйләшербез, насыйп булса. Татар теле миңа якынрак, сүзләре таныш...

Болгар ислам академиясеннән алган тәэсирләрне язманың башында ук әйткән идем. Кабатлап тормыйм. Бары бер теләк – изге ният тормышка ашсын. Биредә белем алган ир-егетләр киләчәктә Россия ислам дөньясына файдалы, дөрес юнәлеш бирүче фән кандидатлары, фән докторлары булып танылсыннар иде.

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов:

– Академия ачу – Татарстан, тулаем Россия өчен, шулай ук бөтен мөселман дөньясы өчен дә тарихи вакыйга. Монда, Болгар җирендә, 922 елда ата-бабаларыбыз ислам кабул иткән. Күп гасырлар дәвамында халкыбыз Аллаһка иманлы булып һәм гореф-гадәтләргә тугры калып, данлыклы һәм катлаулы юл узган. Болгар мәшһүр дин галимнәре яшәгән урын булган. Аның үзәгендә Ислам академиясе ачып, без элеккеге шанлы тарихыбызны яңартабыз...

Россия мөселманнарының Үзәк диния нәзарәте рәисе Тәлгать Таҗетдин:

– Әле кайчан гына Болгардагы мәчет ташландык хәлдә иде. Санаулы еллар эчендә Ак мәчет салынды, академия бинасы төзелде. Бу урын бабаларыбыздан калган традицион ислам үзәгенә әйләнергә тиеш. Эш дипломда гына түгел. Экстремистларда да, террорчыларда да диплом бар. Безнең әби-бабаларыбызның дипломы булмаган, әмма алар дини белемле, дөрес карашлы һәм кыйблалы булган...

Болгар ислам академиясе президенты, ТР Президенты ярдәмчесе Камил Исхаков:

– Болгар ислам академиясенең максатлары зурдан. Без кыска гына вакыт эчендә белгечләрне әзерләү буенча дөньякүләм дәрәҗәгә күтәрелергә тиеш. Магистрларны гына түгел, докторларны һәм дөньякүләм ислам белгечләре элитасына керәчәк кешеләрне әзерләргә тиешбез. Монда укуын дәвам итәргә лаек табылган кешеләр өчен биредә уку, киләчәккә яхшы юллама булачак. Академияне тәмамлаган кеше үзенә эш таба алачак. Бу юнәлештә актив эшләячәкбез.

Болгар ислам академиясе ректоры Рафыйк Мөхәммәтшин:

– Академияне тәмамлаучыларга ике төрле диплом биреләчәк, беренчесе – теология буенча дәүләт дипломы, икенчесе – ислам фәннәре кандидаты яки докторы дипломы.

Әлбәттә, бүген эшлисе эшләр бик күп. Яхшы, ислам дөньясында исемле укытучылар коллективы тупларга кирәк, дәреслекләр белән тәэмин итүне эшләп бетерәсе бар.

Татар телен укытуга килгәндә, җавап бик гади һәм анык: Болгар ислам академиясе – федераль дәрәҗәдәге уку йорты. Шуңа күрә уку гарәп һәм рус телләрендә алып барыла. Дөрес, студентларга фәнни эшләр язганда, татар телле чыганакларга да таянырга әйтәбез.

PRESSA.RU

ДӘҮЛӘТ ӘҺӘМИЯТЕНДӘГЕ **ТӘҖРИБӘ**

Татарстанның РФ Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы конкурсына тәкъдим иткән дәүләт хезмәте өлкәсендәге технологияләре башка төбәкләрдә зур кызыксыну уятты: күптән түгел Казандагы стажировкага РФнең 32 субъектыннан дәүләт органнары кадрлар бүлекчәләренең җитәкчеләре һәм белгечләре килеп китте.

Автор:
Ксения Сёмина

ТР Президенты Аппараты бинасының конференц-залы тыңлаучылар белән шыгрым тулы. Экранда – республиканың Бердәм мәгълүмати кадрлар системасы презентациясе. Республикада проектка старт 2014 елда бирелгән иде.

– Бүген система республиканың һәр дәүләт хезмәткәре турында мәгълүматлар тупланган электрон белешмәләр базасын тәшкил итә: анда – шәхси белешмәләр, белем, хезмәт эшчәнлеге, бүләкләр һ.б. кертелгән. Республиканың барлык дәүләт органнары җитәкчеләре системага онлайн керә ала, димәк, алар үзләренә кирәкле мәгълүматны оператив алу, кадрлар составын анализлау, белгечләргә ихтыяҗны алдан фаразлау мөмкинлегенә ия, – дип сөйли алып баручы.

Тыңлаучылар, аерым билгеләр һәм тезислар янына эре сорау билгеләре куйгалап, конспект язып бара. Презентация тәмамлана, һәм фикер алышу башлана.

– Системаны эшләү өчен шактый күп вакыт таләп ителгәне һәм кертемнәр салынганы күренеп тора, – ди тыңлаучыларның берсе.

– Кертемнәр бер генә тапкыр салынды, ә кандидатлар эзләү, резервны яңартып тору процессы, һәм шулай ук дәүләт кадрлары системасы эчендәге хәрәкәт – өзлексез бара. Мондый эшнең нәтиҗәлелеген шул да дәлилләп тора: хәзер бердәм кадрлар системасы федераль дәрәҗәдә дә тормышка ашырыла башлады, – дип җавап кайтара алып баручы.

«HR-практикум» әнә шулай башланып китте. Сентябрь, октябрь һәм ноябрь айларында өч төркем ТР Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты һәм Казан федераль университетының Югары дәүләт һәм муниципаль идарә мәктәбе тарафыннан эшләнгән чаралар программасында катнашкан иде. Дүртенче төркем Казан Башкарма комитеты Аппаратының Кадрлар сәясәте идарәсе белгечләре әзерләгән программа буенча стажировка үтте.

Казан Кремлендә стажировка ачылуына Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының Дәүләт һәм муниципаль хезмәт, коррупциягә каршы тору өлкәсендә дәүләт сәясәте департаменты директоры Дмитрий Баснак килде. Үзенең сәламләү сүзендә ул болай дип ассызыклады: «Татарстан – дәүләт органнарында кадрлар технологияләренең югары дәрәҗәсе буенча әйдәп баручы булып тора, һәм конкрет субъектка яраклаштырылган бу тәҗрибәдән файдалану алгарышлы уңай нәтиҗәгә китерәчәк».

ПРОЕКТЛАР КҮП, МАКСАТ БЕР

– Хәзер илдә кадрлар системасы эшен оештыруның нинди дә булса бердәм механизмы, персоналны бәяләүнең, аның мотивациясенең бердәм ысулы юк. Законнардагы үзгәрешләр дәүләт хезмәткәренең өч елга бер тапкыр белемен күтәрү бурычын юкка чыгарды. Хәзер бу процесс даими дәвам итә, дип исәпләнелә. Әмма төбәкләрдә укыту шартлары да, аның нәтиҗәлелеге дә шактый нык аерыла. Һәм барысы да шушы юлга – бердәм концепция булдыру юлына бассын өчен конкурс оештырылды, аның белән бергә җинүче-субъект мәйданында стажировка үтү проекты да, – дип сөйли Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментының дәүләт хезмәтен һәм кадрларны үстерү бүлеге баш киңәшчесе Ләйсән Низамова. – Стажировкада катнашучыларны без монда, Татарстанда, таныштыра торган бар нәрсә – дәүләти гражданлык хезмәткәрләре белән тест үткәрү булсынмы ул, электрон мактау тактасын оештырумы яки «Иң яхшы дәүләт хезмәткәре» конкурсын үткәрүме – барысы да гамәли характерда. Кирәк дип санаганда, төбәк тиешле программаны алырга һәм аны үзендә кертергә мөмкин. Шуңа ярашлы норматив база («Дәүләт граждан хезмәте турында» 79нчы ФЗга тулысынча туры китерелгән) безнең тарафтан инде булдырылган.

Стажировканың максаты РФ Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәтендә кадрлар белән эшләүнең иң яхшы тәҗрибәсе» конкурсында җиңеп чыккан республика технологияләре һәм методикалары белән Татарстан министрлыклары һәм ведомстволары мисалында таныштыру иде. (Алар биредә нәтиҗәле рәвештә тормышка ашырылды.) Проектта катнашучылар ТР Хисап палатасында, КФУның Югары дәүләт һәм муниципаль идарә мәктәбендә, ТР Юстиция министрлыгында, ТР Инвестицион үсеш агентлыгында, һәм шулай ук КФУда һәм Казан Кремле буенча экскурсиядә булдылар. Һәрбер чара дәүләт органын презентация-

Реклама

ләүдән башланып китте, аннары кунакларны эш тәҗрибәсе белән таныштырдылар, соңыннан күргәннәр турында фикер алышу булды.

– Республика җитәкчелегенең дәүләт хезмәте институты үсеше өлкәсендәге барлык уңышлы проектларны һәм технологияләрне яклавы нәтиҗәсендә, Татарстанның чыннан да күрсәтер эшләре бар. Без презентацияләребез кунакларда зур кызыксыну уятыр дип көткән идек. Әмма безне программада катнашучыларның активлыгы да бик сөендерде: белемнәрне уртаклашу бик интенсив рәвештә барды. Һәрбер фикер алышуда үзара элемтәгә ирештек – безгә сораулар биреп кенә калмадылар, конструктив рәвештә тәкъдимнәрен дә җиткерделәр, – ди Ләйсән Низамова.

Республиканың Юстиция министрлыгында хезмәткәрләрне KPI технологиясе буенча бәяләү системасы презентациясе зур дискуссия кузгатты. Бу системаны республика дәүләт органнарында сынау тәртибендә кертү вакытыннан башлап, министрлык бик яхшы нәтиҗәләр күрсәтә, һәм аның вәкилләре бу проект турында шактый тулы итеп сөйли алдылар.

Персоналны сайлау һәм бәяләү үзгендә андагы белгечләр кунакларга персонал эзләүдә кулланыла торган перспективалы ысуллар, шул исәптән махсус программ продуктлардан файдалану турында сөйләделәр. Татарстан экспертларын, үз чиратында, Саратов өлкәсе белгечләренең психодиагностика өлкәсендәге тәҗрибәсе кызыксындырды.

Хисап палатасында стажировкада катнашучыларга корпоратив мәдәниятне үстерү эшчәнлеге нәтиҗәләрен күрсәттеләр. Аерым алганда, палата командасы ведомствоара спорт ярышларында катнаша һәм спортның берничә төрендә алдынгы урыннарны яулый. Мотивация ысуллары, мәсәлән, «Иң яхшы дәүләт хезмәткәре» конкурсы аеруча кызыксыну уятты. Ул конкурста катнашу турында Татарстан Инвестицион үсеш агентлыгында бик уңай планда сөйләделәр. Әлеге зур булмаган, яшь, әмма бик актив структуралы коллектив барлык ведомствоара ярышларда катнаша һәм призлы урыннарны яулый. Ә мондый тәҗрибә, һичшиксез, илһамландыра.

НӘТИҖӘЛЕ ҺӘМ КРЕАТИВ!

«Оештыручыларга зур рәхмәт. Вакыт сизелмичә дә үтте, бик сөйкемле кешеләр, яңа очрашуга өметләнәм!» – дип язылган бер катнашучының анкетасында. Программа тәмамланганның икенче көнендә төбәкләр тәҗрибәләр буенча өстәмә мәгълүматлар сорый башлады. ТР Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментында программа турындагы барлык фикерләр һәм тәкъдимнәр игътибарга алына һәм өйрәнелә: киләсе елда «HR-практикум» кабат Казанда уздырылган очракта, бу тәҗрибә файдалы булачак.

– Стажировка миңа беренче чиратта ТР Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты белән КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбенең үзара эшчәнлеген өйрәнү ягыннан кызыклы булды. Югары дәүләт һәм муниципаль идарә мәктәбе менә 6 ел инде КФУ базасында эшли һәм, күргәннәребезгә карап фикер йөрткәндә, бик югары дәрәҗәгә ирешкән. Башка төбәкләр тәҗрибәсе белән танышу да кызыклы булды: бу – бүгенге көндә безнең республика шөгыльләнә торган проблемалар һәм бурычларга башка күзлектән карау мөмкинлеге дә иде, – ди стажировкада катнашучыларның берсе, Башкортостан Республикасы Башлыгы каршындагы Башкорт дәүләт хезмәте һәм идарәсе академиясе ректоры Илгиз Кызыргулов.

– Креативлык, максатчанлык, план белән эшләү, нәтиҗәлелек – стажировка өчен оештырылган программаның төп нигезе әнә шуларга корылган иде. Чараларның докладлар белән генә чикләнмәве, ә бәлки тәҗрибәне тормышка ашыручы орган базасында үткәрелүе, һәм аннан соң фикерләр һәм тәҗрибә уртаклашу мөмкинлеге – барысы да яхшы уйланылган иде. Шул ук вакытта прграмма РФ Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы үткәрә торган үсеш сәясәтенә тулысынча ярашты. Татарстан җитәкчелегенә дә, стажировканы оештыручыларга да барлык чараларның югары дәрәҗәдә үткәрелүе өчен зур рәхмәт белдерәсе килә, – диде Тамбов өлкәсе администрациясе башлыгы аппаратының Дәүләт, муниципаль хезмәт һәм коррупциягә каршы тору департаменты директоры Сергей Чупрунов. – Үзебез өчен без файдалы элементлар алдык. Бездә хәзер дәүләт идарәсе системасын реформалау буенча киң күләмле эш алып барыла. Губернатор тарафыннан бер максат куелган: аз санлы булып та, бурычларның зуррак күләмен башкара ала торган нәтиҗәле, компетентлы аппарат булдыру. Тиешле нәтиҗәлелеккә ирешүгә юнәлеш тоту һәм аны стимуллаштыру мәсьәләсе – кадрлар департаментлары җитәкчеләре өчен даими бер нигез ташы булып тора, һәм монда, әйтик, электрон мактау тактасы кебек матур табышлар ниндидер зур системаның бер өлеше була ала. Дәүләт хезмәтендә кадрлар белән эшләүнең Татарстанда булдырыла һәм гамәлгә кертелә торган технологияләренең нәтиҗәлелеген федераль экспертлар тагын бер кат раслады. Россия Федерациясенең Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы ТР Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан тәкъдим ителгән кадрлар белән эшләү тәҗрибәләрен чираттагы «Дәүләт һәм муниципаль идарә системасында кадрлар белән эшләүнең иң яхшы тәҗрибәсе» Бөтенроссия конкурсында диплом һәм рәхмәт сүзе белән билгеләп үтте. Аның нәтиҗәләре Мәскәүдә 14 декабрьдә чыгарылды.

Александр Белов, ТР Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты җитәкчесе:

– Департамент әле беренче тапкыр гына оештырган «HR-практикум» бик тә нәтиҗәле үтте, дип әйтә алам. Кунакларыбызның анкеталарында – стажировка программасы турында да, проектлар турында да һәм, гомумән,чараларның оештырылуы турында да уңай фикерләр бихисап. Шуны да билгеләп үтим: стажировка процессы ике яклы булды: без тәҗрибә уртаклашып кына калмадык, башка төбәкләрдән дә өйрәндек, мәсәлән, дәүләт хезмәткәрләрен бәяләүнең яңа технологияләренә һәм корпоратив мәдәниятне камилләштерүгә. Катнашу турында гаризалар стажировка шартлары билгеләгәннән күпкә артыграк алынды, шуңа күрә без «HR-практикум» бездә тагын бер кат оештырылыр дип фаразлыйбыз. Хәзер без хезмәт культурасына багышланган яңа һәм бик тә актуаль проектка методик материаллар эшлибез, һәм аны киләсе елга программаны стажировкалау кысаларында презентацияләргә җыенабыз.

Игорь Привалов, Казан (Идел буе) федераль университетының Югары дәүләт һәм муниципаль идарә мәктәбе директоры:

– Стажировкада катнашучылар белән фикерләр һәм тәҗрибә уртаклашу безгә тәҗрибәләрне эшләүдәге бүгенге хезмәтебездә дөрес юнәлеш сайлавыбызда ышаныч тудырды. Әмма, нинди генә уңай нәтиҗәләргә ирешсәк тә, камиллеккә омтылуның чиге юк. Тик бу омтылышны үз эченә йомылган килеш тормышка ашырып булмый. Шуңа күрә дә стажировкаларны республика министрлыклары һәм ведомстволары мәйданчыкларында үткәрү бик мөһим. Программа вакытында безгә күп сораулар бирделәр, аларны түбәндәгечә гомумиләштерергә мөмкин: «Татарстан боларның барысын да ничек булдыра ала?» Җавап бик гади: боларны көчле җитәкчелек белән бергә бердәм команда тормышка ашыра. Җирле дәүләт структураларының да, һәм федераль, һәм республика структураларының да көйләнгән уртак эше бер максатны күздә тота: татарстанлылар үз төбәгендә яхшы һәм уңайлы яшәргә тиеш.

PRESSA.RU

УЕН МОГҖИЗАСЫ

Башка төр спорт дисциплинасы терминын кулланып сөйләшсәк, Владимир Алекно турында спринтер карарларын кабул итү осталыгын камил үзләштергән стайер дип әйтер идек. Үз стиле турында ул болай ди: «Мин үземне барысын да бер вакытта һәм тулысынча булдырырга теләгән тренер дип саныйм, һәм бу яктан минем белән эшләү җиңел түгел. Шул ук вакытта мин ниндидер бер элементны үзләштерүдә камиллеккә ирешү өчен бик тырыш, җентекле хезмәт кирәк икәнлеген аңлыйм. Кайчак моңа берничә ел таләп ителә».



Автор:
Ксения Сёмина

Мондый капма-каршылыкның бердәмлеге һәм көрәшенең нәтиҗәлелегенә ачык мисалларның берсе –10 елга якын Алекно җитәкчелек иткән «Зенит – Казан» волейбол клубының тарихы. 2014 елдан клуб – Чемпионнар лигасында, Россия Суперлигасында, Россия Кубогы матчларында да җиңелүләрнең ни икәнен белми. Җиңелү дигәндә икенче урын алу күздә тотыла. Клубның матбугат хезмәтендә әйтүләренә караганда, нәкъ менә шушы көннәрдә «Зенит – Казан» үзенең «дөнья тажы өчен сәяхәтен», ягъни планетаның иң көчле клубы исемен алу көрәшен тәмамлый. Команда, бер уенда да оттырмыйча, финалга барып җитте. Экспертлар, клубның иң көчле исемен алуга шансы беркайчан да булмаганча зур, дип исәплиләр. Ә аннан соң нәрсә? Владимир Алекноны бары тик яуланмаган биеклекләр генә уңышка дәртләндерә кебек тоела бит.

ФАҖИГА, ӘММА ҖИҢЕЛҮ ТҮГЕЛ

Алекно-уенчы язмышына туры килгән иң йолдызлы шансларның берсе – Сеулга, 1988 елгы Олимпиадага бару мөмкинлеге була. 22 яшендә ул инде легендар ЦСКА дублендә өч сезон уйный һәм илнең икенче җыелма командасының капитаны итеп билгеләнә. Олимпиада якынлаша, һәм тренер Геннадий Паршин уенчыны сборларга чакырырга карар кыла. Алекно җыелма командага 12нче булып эләгә. Ләкин Олимпия уеннары башланырга бер атна кала, бәйләүче буын уенчысы аягын каймыктыра. Кыен хәлгә калудан саклану максатында Паршин командага башка бәйләүче уенчы – булачак волейбол легендасы Вячеслав Зайцевны чакыра, шулай итеп Алекно Олимпиадага бара алмый кала. «Әлеге чор турында әллә ни ис китәрлек хатирәләр сакланмаган күңелдә, әмма менә Сеулга бармау – минем өчен фаҗига булганы истә калды, – дип сөйли Владимир Романович. – Ләкин мин яшь, җиңүгә омтылыш, теләк көчле иде. Бүген мин шундый авыр мизгелләрдә югалып калган, төшенкелек чигенә җиткән яисә, берәр нәрсә килеп чыкмаса, күңелләре тиз сүрелә торган яшь уенчыларны очратам. Мондыйлар спортта әллә ни югарылыкларга күтәрелә алмаячаклар, билгеле».

ФРАНЦУЗ СЕРПАНТИНЫ

Владимир Алеконың спорттагы карьерасы СССР таркалган елдан башлана: аны тиздән Болгариягә, үз иленең чемпионы булачак «Левски-Спартак» клубына чакыралар. Ике елдан соң спортчы инде итальян клублары составында уйный. Италиядә әлеге уен шаукымы күтәрелгән чор, спортчыга төшкән йөкләнеш гаять зур була. Шуңа күрә ике ел дәвамында итальян волейболы Алекноның ныклыгын сыный. Аннан

Фото: Роман Кручинин

соң француз җыелма командасы тренеры Филипп Блэн аны Франциягә чакыра. Шул рәвешле язмышының француз чоры башлана. Алекно башта – «Канны» командасында, аннан соң «Тур»да уйный, соңгысында, тренерның үз сүзләренә караганда, ул «бүгенге дәрәҗәгә ирешерлек мөмкинлекләр» ала. Чөнки нәкъ менә «Тур» менеджеры 1999 елда тез авыртулары һәм артык авырлык белән көрәшкән уенчыга сезонны уйный торган тренер буларак тәмамларга, ә аннан соң баш тренер вазыйфасын башкарырга тәкъдим итә.

АЛАРДАН БАШКА АЛЕКНО БУЛМАС ИДЕ

Алекноның үзенә яхшы баш тренерлар туры килә – совет ирләр волейболының берничә дистә еллык үсешен тәэмин иткән Вячеслав Платонов һәм Юрий Чесноков кебек кешеләр. Чесноков белән беренче очрашуын Алекно болай дип искә ала: «Мине армиядән ЦСКАда уйнарга чакырып алдылар. «Динамо» командасы белән иптәшләрчә очрашу бара иде. Мин запастагы уенчылар эскәмиясендә утырам һәм уенны күзәтәм. Яныма Чесноков килде һәм нәрсәдер әйтте. Кырдагы уен белән мавыгып китеп, мин аңа карамый гына баш кактым, ул китеп барды. Шунда икенче бер уенчы килеп миңа болай диде: «Кешеләр баскан килеш аның каршында калтырап торалар, ә син утырып торасың…» Шуннан бирле тиеш булса да, булмаса да, мин Чесноков каршында шәм кебек басып тордым. Мин аны кырыс, хәтта ки авторитар, әмма, һичшиксез, бөек тренер дип саныйм». Владимир Алекно Чесноков үткәргән тренировкалар, аның тактикасын теркәп-язып бармавына үкенә: «Мин бүген дә, никадәр тәҗрибәгә ия булсам да, 18 уенчы өчен бер үк вакытта һәм бертөрле интенсивлыкта ике мәйданчыкта тренировка үткәрә алмыйм, ә ул үткәрә иде». Шулай да тренер үзенең төп укытучысы дип Вячеслав Платоновны атый, аның фикерләре һәм көнегүләре теркәлгән язмалар Алекнога инде «Тур» тренеры булып эшләгәндә нык ярдәм итә. «Әлеге тактика мине җыелма команда составында уйнаганда ук кызыксындыра иде. Ул, мәсәлән, алдагы көндә шәп уен күрсәткән уенчыны икенче көнне уйнарга чыгармаска мөмкин иде. Ике көн рәттән спортчы бер үк нәтиҗә күрсәтә алмаячак, дип саный иде».

ЛОНДОН – МӘҢГЕГӘ

Күп кенә уеннарда Алекноның нәкъ менә тактик карарларының нәтиҗәләре ничектер гайре табигый күренә. Лондонда чыннан да могҗизага тиң булган җиңү алтын хәрефләр белән мәңгелеккә Россия волейболы тарихына язылган. Алекно тарафыннан яхшы итеп әзерләнгән команда финалга чыга, әмма уен алдыннан шактый киеренке атмосфера хөкем сөрә: көндәш – төркем уеннарында россиялеләр җиңелгән бердәнбер команда – Бразилия җыелма командасы. Моннан тыш, барлык уенчыларыбыз да диярлек күптән түгел алынган травмаларыннан тернәкләнеп киләләр генә. «Аларны үтерә яздылар. Шулай да алар исән калды» – илебез спорт порталларының берсендәге башисемдә шулай дип язылган иде. Баштан ук хәлиткеч матч россиялеләр файдасына бармый. Отылган ике сеттан соң, җанатарлар инде җиңүгә өметләнми дә. Кинәт Александр Волков бразилиялеләрнең чираттагы атакаларын кире кагарлык блок куя. Сетка аша туп бирергә Сергей Тетюхин чыга һәм матч барышын үзгәртеп куя, ә аннан соң Владимир Алекно, бөтен кеше, шул исәптән уенчыларны шаккатырып, диагональ уенчы Максим Михайловны көндәшләрне тар-мар итүне җитәкләячәк Дмитрий Мусэрскийга алыштыра: спортчыларыбыз ике матчболда өстенлеккә ирешәләр, исәпне тигезлиләр һәм 3:2 исәбе белән Бразилия җыелма командасыннан җиңүне тартып алалар.

«Ул уенда бар нәрсә Аллаһы Тәгалә ихтыяры белән барды, – ди бүген Владимир Алекно. – Аңа һәм тагын бердәм уйнаган командага таянып җиңдек. Чын команда җиңде. Ә мин нәрсә эшләдем, бу турыда әйтеп торырга кирәкми… Миндә интуиция бар, һәм мин аңа колак салырга тырышам. Килеп чыгамы-юкмы – анысы икенче мәсьәлә». Һәм Лондон турында сөйләгәндә ул болай ди: Олимпиададан соң исемнәре бөтен илгә яңгыраган уенчылардан тыш, күләгәдә калган Александр Бутько һәм Сергей Гранкин кебек уенчылар, һәм һәрвакыт команда белән бергә булган физик әзерлек буенча тренер, табиб, массажистлар, менеджер, ярдәмче Серджо Бузато да җиңүгә зур өлеш керттеләр.

НАПОЛЕОН ТҮГЕЛ

Владимир Романовичның дүртенче мәртәбә илнең җыелма командасына тренер булып кайтуы ихтимал, дигән фаразларга ул болай дип җавап бирә: «Җыелма команда миннән башка да булдыра. Аны башка тренер җитәкли, алар Европа чемпионатында җиңделәр. Әлегә мин анда кирәк түгел». Җыелма команда тренеры постын Алекно соңгы тапкыр Риода үткән Олимпиададан соң, команда анда дүртенче урын яулагач калдырып китә. Ул вакытта аңа карата тәнкыйть ташкыны ябырыла. Ул шуны да искә төшерә: 2012 елгы Олимпия уеннарына җыелма команданы әзерләү өчен 2010 елда тренер буларак кайтудан аны үзе хөрмәт иткән күп кенә кеше кисәтә. «Ләкин мин Наполеон түгел. Катнашу мөмкинлеге була торып, көрәш кырын читтән генә күзәтә алмыйм», – ди атаклы тренер.

ҖИДЕНЧЕ УЕНЧЫ

Аның чит илләрдәге тормышы турында иң якты истәлекләреннән берсе «Тур»да уйнау белән бәйле. Әлеге кечкенә шәһәрчек трибуналарына, волейбол уеннарын карарга дип, өч меңнән дә ким кеше җыелмый. Ә инде «Тур», Франция Кубогында җиңеп, Чемпионнар лигасында уйный башлагач, уеннарга бөтенләй әләгеп булмый башлый. Һәм менә, егерме ел узганнан соң да, «Зенит» яулаган эре җиңүләрнең иң яңасы (2017 елгы Россия Суперкубогы) турында сөйләгәндә тренер өчен иң мөһиме – ул трибуналар. «Иң зур уңышыбыз шул: без матч алдыннан залны тутыра алдык. Искиткеч атмосфера урнашты. Мондый зал мәйданчыкта җиденче уенчы дигән сүз. Әлеге уенда без өч очко да эшләдек, алтынчы мәртәбә Россия Суперкубогын да яуладык. Барысы да искиткеч булды».

P.S. Журналыбызны басмага әзерләгәндә, волейбол дөньясында елның иң төп вакыйгасы турында билгеле булды: «Зенит-Казан» клубы планетада иң яхшысы дип табылды. Барысы да уң килеп торды: уенчыларның югары осталыгы да, һәр матчка Алекнога хас җентекле аналитик һәм тактик әзерлек тә һәм, ниһаять, җиңү рухы булдырырга һәм, шуңа таянып, искиткеч триумфка һәм тагын да алга таба атларга уенчыларның әзерлеге һәм тренерларының талантлы да. Алда – Чемпионнар лигасында «Берлин» көтә бит. ◼

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән ТР дәүләтчелеген үстерүдә, гражданнарның хокукларын һәм азатлыгын тәэмин итүдә, икътисад, мәдәният, фән, мәгариф, сәламәтлек саклау, сәнгать һәм спортны үстерүдәге зур казанышлар, шулай ук җәмгать тәртибен саклауда күрсәткән кыюлык һәм батырлык өчен бүләкләнәләр. Әлеге билге 925нче пробалы көмештән эшләнгән.

Ф press.ru

КИЛӘЧӘККӘ – ЭНЕРГОКҮПЕР

Узып баручы елда Татарстанның энергетика комплексы өчен истәлекле вакыйга булды: «Челтәр компаниясе» ААҖ Казанны Алабуга районындагы подстанция белән тоташтырып һәм республикабыз башкаласын киләчәкнең зур проектлары өчен өстәмә куәтләр белән тәэмин итеп, «Щелоков – Үзәк» 220 кВ югары вольтлы линияне файдалануга тапшырды.

Илшат Фәрдиев, «Челтәр компаниясе» ААҖ генераль директоры

– Бу вакыйгага кадәр республика энергетика комплексларының төп объектларын камилләштерү һәм төзү белән бәйле күп кенә проектлар тормышка ашырылды, – дип сөйли «Челтәр компаниясе» ААҖ генераль директоры Илшат Фәрдиев. – Иң әһәмиятле этапларның берсе Универсиада-2013 кә хәзерлек алдыннан башкарылган «Киндери» 500 кВ, «Котлы Бүкәш» 220 кВ һәм «Үзәк» 220 кВ подстанцияләрен үзгәртеп төзү булды. «Үзәк» подстанциясе проекты яңа электр үткәрү линиясе өчен булган ячейкаларны күздә тотты.

«Алабуга» махсус икътисадый зонасы үсеше, «ТАНЕКО» һәм «Аммоний» комплекслары төзелеше белән яңа энергообъектларның республиканың үзәк районнарына гына түгел, Кама аръягы зонасына да керәклеге ачыкланды. ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын киләчәктә өстенлекле үсеш ноктасы буларак билгеләде.

2013 елда «Щелоков» 500 кВ (Алабуга-500) подстанциясе төзелде. Ул кабат төзелгән «Бигеш» 220 кВ подстанциясе аша Түбән Кама энергорайонының резервлы электр белән тәэмин ителешен булдырды һәм Казан энергорайонын яңа бәйсез туену чыганагы белән баетты.

– 2014 елда «Челтәр компаниясе» ААҖндә «Щелоков» 500 кВ подстанциясеннән «Үзәк» 220 кВ подстанциясенә кадәр (соңгысын югары вольтлы сүндергеч ячейкалары белән җиһазлап бетереп) электр җибәрү линияләре төзелешенең проект документлары расланды, – ди Илшат Фәрдиев. – 230 км га сузылган энергокүперне проект буенча республиканың Алабуга, Мамадыш, Балык Бистәсе, Питрәч районнары аша салырга кирәк иде. Проектны тормышка ашыру «Челтәр компаниясе» ААҖ филиалы – «Түбән Кама электрорайонының төзелүче объектлары дирекциясе» директоры Владимир Уржумцевка тапшырылды. «КЭР-Холдинг» ИК» ҖЧҖ генераль подрядчик буларак катнашты – һава линиясе буенча проектны Вячеслав Глазков җитәкләде. Татарстанның төзелеш һәм энергетика өлкәсендә хезмәт куючы дистәдән артык әйдәүче предприятиесе субподрядчылар буларак катнашты.

СУ ӨСТЕННӘН УЗДЫК

Иң яхшы традицияләргә тугры калып, «Челтәр компаниясе» объектны вакытыннан алда тапшырды, өстәвенә, объектта күп кенә катлаулы инженерлык һәм технологик мәсьәләләр бар иде. Иң катлаулы участокларның берсе Нократ аша өр-яңа, хәтта Россия энергетика тармагы өчен дә уникаль булган технологияләр кулланып төзелгән өч километрлы кичү булды.

Реклама

> **– Шулай итеп, Мундиаль-2018не каршылаганда без, Казанны 800 МВт ка кадәр өстәмә куәт белән тәэмин итеп, республика энергокомплексын көчәйтәчәкбез.**

– Беренче этапта 150 тонналы терәкләрне урнаштырырга һәм җыярга тиеш идек. Ике анкерлы (ярларда, 92 метр биеклектә) һәм өч ике арадагы (107 метр биеклектә) терәкләр зур авырлыкларны чыдата алды, бораулап кертелгән субайларда югары ныклыктагы нигез салынды, – дип сөйли Илшат Фәрдиев. – Кичүдә һава юлы салу өчен Бельгиянең «LAMIFIL» фирмасы технологиясе буенча җитештерелгән югары технологияле яңа үткәргеч файдаланылды. Тышкы кендегенең Z рәвешендәге формасы ярдәмендә үткәргеч югары үткәрү сәләтенә ия, шундый ук диаметрлы гадәти үткәргеч белән чагыштырганда аның механик көчәнеше азрак, ул температура сикерүенә һәм көчле җилләр тәэсиренә каршы тора ала. Әмма аны монтажлау билгеле бер көч таләп итте. Үрелү үзенчәлекләре булу сәбәпле, аның җиргә тиеп торуына һәм катлауларга аерылуына юл куймаска кирәк иде. Шуңа күрә тизлекне һәм үткәргечнең тартылуын күзәтү һәр терәк янында урнаштырылган. Барлык монтажлау процессында 40 белгеч катнашуы кирәк булды.

Авиация куркынычсызлыгы өчен (ерак түгел «Бигеш» аэропорты урнашкан) махсус кичүнең яшен тросына аклы-кызыллы пластик шарлар урнаштырылды. Ике арадагы терәкләр дә шундый ук төскә буялган.

ИННОВАЦИЯЛӘР ТЕРӘГЕ

«Челтәр компаниясе» ААҖнең тагын бер горурлыгы – Казанга керер алдыннан биш километр озынлыгындагы участок. «Щелоков – Үзәк» линиясенең «Үзәк» подстанциясенә керүе кабельле булачак дип планлаштырылды. Әмма инде төзелеш башлангач ук яңа нәрсәләр ачыкланды: планлаштырылган трасса янындагы торак корылмалар артык тыгыз, ә кабель салу өчен буш коридорлар юк, – дип искә ала Илшат Фәрдиев. – Линияне гамәлдәге «Киндери – Үзәк» кВ һава линиясе күчәре буйлап салырга карар кылдык. Иске линияне сүтәргә, ә аннары дүрт чылбырлы терәкләрдәге иске һәм яңа линияләрнең уртак асылмалары участогын төзергә кирәк иде.

Бу республика өчен генә түгел, Россия электр челтәре комплексы өчен дә эшкә инновацион якын килү булып чыкты: проектлау башлангач тиешле төзелеш һәм файдалану нормативлары юк, ә проектта күздә тотылганнан шактый түбән «дүрт чылбырлылар» бары тик Сочи, Мәскәү яны, Себер һәм Уралда гына урнаштырылган иде. Әмма мондый технология чит илләрдә киң һәм уңышлы кулланыла, һәм «Челтәр компаниясе» ААҖ белгечләре бу алдынгы тәҗрибәне нәтиҗәле файдалана алдылар, өстәвенә, дүрт чылбырлы терәкләрне җыю һәм монтажлау технологиясен аларга өр-яңадан өйрәнергә һәм үзләштерергә туры килде.

Беренче этапта бораулап кертелгән субайлардан торган нигез урнаштырылды, мәйданчык әзерләнде, нигез салу детальләре урнаштырылды, каркас бетонланды (һәр конструкция астына – 260 кубометр бетон). Аннары терәкләрне монтажлау башланды: һәр «колонна»ның (биеклекләре – 43 метр, авырлыклары – 108 тоннага якын) дүрт секциясе сиксән тонналы автокраннар ярдәмендә этаплап урнаштырылды.

Җыю процессы чын мәгънәсендә ювелирларча осталык таләп итте: деталь кисәкләренең урнашу тәртибен «тотып алырга» һәм 128 технологик тишеккә урнаштырырга кирәк иде. Һәр терәкне монтажлау 4–5 көн дәвам итте. Барлыгы 5 анкерлы һәм 17 аралык терәге урнаштырылды, аннары аларга югары технологияле Z рәвешендәге үткәргеч монтажланды.

ЧЕМПИОННАР ӨЧЕН ЭНЕРГИЯ

– «Щелоков – Үзәк» линиясе Казанны электр белән тәэмин итүнең иң эре үзәген («Киндери» 50 кВ подстанциясен) өлешчә бушата һәм икенче электр белән тәэмин итү үзәге – «Үзәк» 220 кВ подстанциясе белән өстәмә элемтә бирә, – ди Илшат Фәрдиев. – Шулай итеп, Мундиаль-2018не каршылаганда без, Казанны 800 МВт ка кадәр өстәмә куәт белән тәэмин итеп, республика энергокомплексын көчәйтәчәкбез.

Моның белән бергә, яңа линия төзелеше – ул энергетика боҗрасы төзелешенә чираттагы адым («Щелоков» ПС 500 кВ – «Үзәк» ПС 220 кВ, «Котлы Бүкәш» ПС 220 кВ – «Бигеш» ПС 220 кВ – «Щелоков» ПС 500 кВ). Дөнья һәм ил тәҗрибәсе «боҗра» схемасы сәнәгать потенциалын туплаучы Татарстан өчен кулланучыларны электр белән тәэмин итүнең ышанычлы һәм сыйфатлы булу мәсьәләләрен дөрес чишәргә ярдәм итәчәген күрсәтә.

PRESSA.RU

Реклама 16+

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Бертуган Горшковлар **НИЧЕК** итеп Россиянең биологик төрлелеген саклыйлар

Татар мунчалары **КАЙЧАН** барлыкка килгән

Филармония **НИНДИ** тормыш белән яши

«Үзгәреш җиле»: **КАЯ** юл тотабыз

Әлеге материалда бертуганнар – кан буенча гына түгел, рух ягыннан, уртак эшләре белән бер булган, республикабызны алга җибәрү өчен кулга-кул тотынышып хезмәт куючы кешеләр турындагы язмаларыбызны дәвам итәбез.

БЕРТУГАН ГОРШКОВЛАР. NATURA* ШУНДЫЙ!

– Көрткә чумасымы? Кар бабай ясыйсымы? Кар бәреп уйныйсымы? – дип көләләр фотосессиябез геройлары. Без исә алар тормышында болай да экстрим җитәрлек дип саныйбыз.

Быел безнең редакция беренче карны Идел-Кама тыюлыгында танылган экологлар – бертуган Юрий һәм Михаил Горшковлар белән бергә каршы алды.

Фото: Ната Смирнова

* Табигать – инглиз теленнән тәрҗемә.

PRESSA.RU

Автор:
Ольга Туманская

ТАБИГАТЬ ӨЧЕН КӨРӘШ

Идел-Кама тыюлыгы директоры Юрий Горшковның кабинеты үзенең зурлыгы белән дә, җиһазлары белән дә әллә ни тәэсирләндерми. Тәрәзә пәрдәләре юк (теләгән кеше карый ала!), бүлмә почмакларында – китаплар һәм карталар. Менә киштәдәге грамоталар һәм бүләкләргә күзем төшә, ә алар арасында – иң кызыклыларына. Халыкара Эндрю Сейбин премиясе һәм Россиянең Экологик сәясәт үзәге дипломы «акыллы» техника яисә затлы җиһазларга караганда ныграк тәэсирләндерергә сәләтледер. «Россиянең биологик төрлелеген саклауга керткән зур өлеш һәм кыргый хайваннарны саклауда күрсәткән шәхси батырлык өчен».

Ә вакыйга ерак 1995 елда була. Юрий Александровичның ул чакта директор кәнәфиенә ияләшеп кенә килә торган чагы. Хәер, кәнәфи бик еш буш тора, чөнки Горшков – кабинет саклый торган җитәкче түгел. Һәм менә ул көздә дә директор коллегалары белән бергә Түбән Кама сусаклагычына экспедициягә китә.

– Кама-Ык тугае – җанварлар өчен чын эльдорадо иде! – дип искә ала ул көннәрне Михаил Александрович. – Яшьтән үк таныш урын – анда Фәннәр академиясенең биология полигоны урнашкан иде. Без ул вакытта Юра белән тыюлыкта эшли генә башладык. Өстәвенә, ул әле тагын диссертациясе өчен материал да җыя иде.

Беренче ату тавышлары яңгыраганда, команда инде йокларга җыенып йөри торган була. Браконьерларның поши ауларга чыгуларын шундук аңлап алалар. Җинаятьчеләрнең эзенә тиз төшәләр. Алар пошиларны трактордан атып торалар – берсе, капотка утырып, куакларны прожектор уты белән яктырта.

– Без аларның юлларына аркылы төшәргә омтылдык, – дип сөйли Горшковларның кечесе. – Юра шунда ук тракторга ташланды, капотта утырганын сөйрәп төшерергә тырышты.

Әлеге бәрелештә алар җиңә. Браконьерларны тоткарлыйлар. Әмма



нәрсә бәрабәренә! Юрий Горшковка бер мизгел җитми кала – трактор йөртүче газга басып өлгерә һәм тыюлык директоры трактор астында кала. Алынган җәрәхәтләр бик җитди була – сынган, тайган, имгәнгән урыннар бихисап. Иң якын хастаханәгә, Минзәләгә иптәшләре аны көймәдә, су буйлап алып баралар. Алда гаять авыр операция, тернәкләнү узулар...

УРМАНДА ДА, СУДА ДА – ЭШ КЫРЫНДА

Алар табигатькә мәхәббәт безнең геннардан килә, дип раслыйлар. Әтиләре биофак тәмамлаган, ә әниләре – фән кандидаты, Татарстан авыл хуҗалыгы ФТИ хезмәткәре – үсемлекчелек эшенә җаны-тәне белән бирелгән белгеч. Юра белән Миша хәтта ки бөтен җәйге каникулларын кырда үткәрергә мәҗбүр булалар. Нина Наумовна арышның яңа сортларын чыгару өстендә эшли, ә малайлар беренче класстан башлап, арыш басуларын чүп үләннәреннән арындыралар.

– Алны-ялны белми эшләргә туры килә иде. Кызуда, тузанда! – дип искә ала ул көннәрне Михаил Александрович. – Әти-әниләребез безне хезмәткә өйрәтте, дөрес, бакчачылыкка, җиргә тартылуны без мәңгелеккә җуйдык. Аның каравы, миндә суга мәхәббәт уянды! Юра тыюлык эше белән мавыгып китте – бу эш белән озак еллар бергә шөгыльләндек. Ә аннан соң ихтиология барыбер өстенлек алды, һәм мин тулысынча үземнең һөнәри кәсебемә бирелдем.

Әмма шулай да «кыр» төшенчәсе алар тормышыннан беркайчан да китми, чөнки аның мәгънәсе җир дигәннән күпкә киңрәк. Хәер, әйтеп тә торасы юк, бертуганнар бүген еш кына «кыр»да югалалар! Ягъни экспедициядә – хәтта ки ул суда оештырылса да. Беренче булып экспедицияләргә Юрий йөри башлый – өлкәнрәк. Мөмкинлек булганда кечкенәдән үк үзе белән ияртеп йөргән энесен дә ала. Шундый сәяхәтләрнең берсе – 1978 елгысы – хәтергә бигрәк уелып кала.

Ул бүген генә Татарстанда беркемне дә ысылдавык аккош күрдем дип шаккатырып булмый. Ә ул чакта Алексеевск районында сирәк кошлар парын күргәннәр дигән хәбәр биологлар арасында ыгы-зыгы уята. Гаҗәп бит: соңгы тапкыр

PRESSA.RU

ысылдавыклар бу якларда 19 гасырда күренгән булганнар.

Горшковлар бу турыда таныш аучыдан ишетәләр. Барырга кирәк, дип карар кылалар. Моторлы көймәдә чыгарга туры килә. Урынга килеп җитәләр: кечкенә генә уентык, күрәләр: аккошлар оя гына кормаганнар, балалар чыгарырга да өлгергәннәр. Максат – фотога төшерү. Юрий ул чакта диссертациясе өстендә эшли – фән өчен ул фотосурәтләр бик кирәк була. Бер тәүлектә әйләнеп кайтырбыз, дип уйлыйлар, кая анда! Бер көн урынына дүрт тәүлек тоткарланырга туры килә. Ашамлык запасы күптән бетә, икесенә бер чабак балыгы (вобла) кала, ә алар һаман да әрәмәлектә, ишкәк һәм дә фотомылтык белән.

– Ул вакыйга минем хәтеремә нык уелып калды. Ләкин авыр булганга түгел, бәлки үзебезнең ачыш ясауда катнашуыбызны тойгангадыр. Бу фотолар Татарстанда күренгән ысылдавык аккошларның беренче сурәтләре иде! – дип искә төшерә Михаил Горшков.

Бертуганнар тормышында андый хәлләр шактый була, чөнки алар кабинетларда, лабораторияләрдә генә утыручы галимнәр түгел.

– Без – станок артындагылар, – ди үзе Михаил Александрович. – Безнең цех – әйләнә-тирә дөнья. Һәм менә нәрсә кызык: яшь баруына да карамастан, ару-талуның әсәре дә юк! Бер экспедициядән кайтып кына керәсең, бер-ике көн ял итеп алгач, тагын каядыр ашкынасың: «Боз әле катмаган кебек – бәлки, тагын берәр тапкыр барып килергә өлгерербез?» «Кырга» тарта!

МАХСУС САК АСТЫНДА

Юрий Александровичның директор кәнәфие янәшәсендә значоклар коллекциясе урын алган. Аерым тематикалы. Алар барысы да төрле тыюлыкларны һәм милли паркларны чагылдыра. Бертөрлеләр юк. Барысы да тормыштагыча, дип раслый Юрий Горшков: ил күләмендә 103 тыюлык исәпләнә һәм һәркайсы үзенчә уникаль. Идел-Кама тыюлыгы да – үзенчәлекле.

– Аның составына Көнчыгыш Европаның беркайчан киселмәгән иң борынгы урманнарының берсе керә, – дип сөйли Юрий Горшков. – Кайчандыр бирегә чирмешләрнең изге агачлыклары урнашкан була. Ә аннан соң өч йөз елга якын әлеге урыннар Раифа монастыре монахлары сагы астында була. Татарстанда мондый урманнарны башка табып булмый.

Юрий Александрович директорлык иткән чорда Идел-Кама тыюлыгына ЮНЕСКОның биосфералы территориясе статусы бирелә, бу аны аерым саклана торган халыкара әһәмияттәге табигать объекты итә. Ә Горшков үзе исә – Россиядә берданбер! – ЮНЕСКОның Мишель Батисс исемендәге «Биосфералы территория белән нәтиҗәле идарә иткән өчен» дип аталган гаять абруйлы премиясенә лаек була.

– Бүген тыюлык җитәкчесенә егерме ел элек белән чагыштырганда кыенракмы? – дип сорыйм аңардан.

– Чагыштыргысыз! Иртәдән кичкә кадәр – циркулярлар, исәп-хисаплар, төрледән-төрле формалар тутыру... Без кәгазь боткасына баттык. Бу безгә төп эшебез белән шөгыльләнергә комачаулый.

Нәкъ менә төп эш өчен көенә дә директор. Шәһәр көннән-көн тыюлыкка якыная. Экосистемага актив булмаган антропоген йогынтыны киметү өчен төзелгән буфер зонасы бүген девелоперлар өчен гаять кызыктыргыч калҗа булып тора.

– Тыюлыкта эшләү – аның мәнфәгатьләрен һәрдаим кайгыртып тору, – ди Юрий Горшков. –Алай итмәгәндә вакытлар үтү белән әлеге уникаль урынның язмышы Мәскәү янындагы «Лосиный остров» милли паркын хәтерләтәчәк – аны периметры буенча тулысынча төзелеш уратып алган. Ә бу кыргый табигать өчен зарарлы нәтиҗәләргә китерәчәк. Шуңа әле климатның җылына баруын, ландшафтның коруын, үсемлек һәм җәнлекләрнең тайга төрләре югалуын һ.б.ларны өстәгез.

Бәхеткә, бүген Идел-Кама тыюлыгы тагын әле җәнлек һәм кошларның тыгыз урнашуы белән аерылып тора. Сак хезмәтенең эше нәтиҗәсендә аның чикләре бикле. Намуссызлар табыла, ләкин аларны чикләп торалар. 250ләп беркетмә – еллык хокук бозулар статистикасы шундый.

– Җирле халык арасында чыршы кисүчеләрне тотарга туры киләме? – дип, «яңа ел» соравы бирәм Горшковка.

– Юк! Алар өчен дендрарийда махсус плантация бар.

БОРЫНГЫ ДӘРТ

– Кар яуды – «түбә» китте, – дип көлә Горшковлар. Кар – ауга чыгарга сигнал ул, дип аңлаталар алар, ә ау – аларны берләштергән тагын бер мавыгу.

– Әле бер гасыр элек язучы Ефим Пермитин «ау – кешеләрне тарту көче ягыннан бары тик мәхәббәт белән генә чагыштырып була торган гаять көчле борынгы дәрт ул» дигән, – дип сөйли миңа тыюлыкка бару юлында Михаил Горшков. Ярты сәгать үттеме-юкмы, шул ук сүзләрне миңа аның абыйсы да кабатлый.

Беренче булып ау белән Юрий мавыгып китә – КДУның табигатьне саклау кафедрасында укыган вакытында. Энесе бераз соңрак кушыла, яше җиткәнче, мылтыктан башка гына йөри ул ауга.

– Бер яктан караганда, биологэкологлар, икенче яктан – аучылар. Шулай да була аламыни? – дип сорыйм Горшковлардан.

– Ау – табыш кына түгел – ул күзәтү, тормышның үзе! – дип җавап бирә Юрий Александрович. – Бары тик чын аучы гына әйләнә-тирәдәге табигать халәтен тирәнтен аңлый. Урманда ничек ориентлашырга, елга аша ничек дөрес чыгарга, төнлә дулкын вакытында көймәне ничек алып барырга, машинада сазлыкны ничек кичәргә... Хәтта сынган куак яисә кош тавышы аучыга күп нәрсә турында сөйли. Бу натуралистка хас тулы бер күнекмә һәм карашлар җыелмасы, болар барысы да табигатьне саклау эшендә ярдәм итә.

Үз вакытында аларның бригадалары да булган – җәнлек мехы җитештерү буенча республика буенча беренче урыннарны биләгәннәр. Шул ук вакытта Юрий җәнлек кенә ауламый, диссертациясе өчен материал да туплый. Һәм тиздән ул кыргый булмаган шартларда ондатра үрчетү методын эшли.

Проект инде гамәлгә кертү стадиясендә була: җәнлекләрнең баш саны меңгә җитә һәм иң мөһиме – алар инде нәсел бирә башлый! Ләкин эш шуннан да алга китә алмый кала. Советлар Союзы җимерелгәннән соң, җәнлекчелек тармагы да таркала. Бүген җәнлек мехына ихтыяҗ алай югары түгел, дип саный бертуганнар. Кышлар җылы килә, машиналы кешеләр күп, ә мехларны әкренләп пуховиклар алыштыра.

БАЛЫКЛЫ ЭШ БИТ!

Бер минутка гына күз алдына китерегез. Кара көз. Фәнни-тикшеренү судносы палубасын кар баскан. Ачы җил. Һәм беркая да качып булмый, салкын белән өретелгән дулкыннан да котылу юк! Түбән өлеше Жигули диңгезе дип йөртелгән Куйбышев сусаклагычы плотинасы

янындагы киң урында аның биеклеге өч метрга кадәр җитә!

– Кайчак иртән уянып китәсең – судно бозда, – дип сөйли Михаил Горшков. – Җил атналар буе исә, дулкынны куалый. Кайберәүләрдә диңгез авыруы башлана, ләкин бу эшне туктату өчен сәбәп була алмый. Суның температурасы – дүрт градус. Сине дулкын каплап ала – бер мәртәбә, ике… Көн дәвамында мондый «һөҗүмнән» берниди гидрокостюм да саклый алмый. Дөресен әйткәндә, моңа һәр кеше дә чыдый алмый. Ләкин без – команда! Яшьләребез дә искиткеч кыюлар. Кызлар магистратураны тәмамлап кына килә, ә күнекмәләре оста морякларныкына тиң.

Чебешләрне көзен саныйлар диләр. «Балыкны да!», – дип көлә Михаил Горшков. Республикада балыкчылык перспективасына бәя бирү өчен, рейска сентябрьдән дә иртә чыгарга ярамый, кайчак, гомумән, ноябрьләрдә генә. Дәүләт күл һәм елга балыгы хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институтының Татарстан бүлеге хезмәткәрләренең бурычы – балык запасларының торышын, аларны рациональ куллану перспективаларын һәм балыклар өчен азык ресурсларын бәяләү. Ел саен мондый экспедицияләрне оештыру – аларның катгый бурычы. Алай итмәгәндә, трендлар югала, күзәтүләр динамикасы өзелә. Михаил Горшков үзенең коллегалары белән чираттагы рейстан кайтып кына кергән иде: Кама буенча Удмуртиядәге Каракулино авылына кадәр менгәннәр, кире кайтканда Идел киң җирендә тикшеренүләр үткәргәннәр. Ул арада инде салкыннар килеп өлгергән…

– Сез табигатегез белән балыкчымы? – дип сорыйм саубуллашканда.

– Сез дөрес сүз сайладыгыз, чөнки әле балык тотучылар да бар, – дип елмая ул. – Әйе, мин балыкчы! Башка балыкчы-профессионаллар да бар, әйтик, студент елларыннан ук бергә булган якын дусларым. Укытучыларым – Казан университеты профессорлары миндә әлеге эшкә кызыксыну уяттылар – промысел белгечләре белән эшләргә һәм тыгыз аралашырга этәргеч бирделәр. Мин үзем дә алардан кайбер нәрсәләргә өйрәндем…

Михаил Горшков – республиканың атказанган экологы, Юрий – Россиянеке. Икесенә бер эшме? Юк – тугызына! Династияләренә шуның кадәр фикердәш тупланган. Хатыннары – шулай ук алар арасында. Яшь буын арасында да дәвамчылары бар: Юрий Александровичның олы улы Дмитрийга атаклы Сихотэ-Алинск тыюлыгын җитәкләү кебек зур җаваплылык тапшырылган.

PRESSA.RU



ҖИҢЕЛ ПАР БЕЛӘН!

«Ирония судьбы, или С легким паром!»ны карамаган кеше юктыр. Төп геройның маҗаралары мунчага барып кайтудан башлана. Россиядә яшәүче миллионлаган кеше Яңа ел кичендә нәкъ менә шушы киноны карый. Чөнки фильмы да шәп, мунчасын да ярата безнең халык. Күпләр мунча юыну культурасының нәкъ менә татарларда, дөресрәге болгар бабаларыбызда барлыкка килгәнен белмидер дә әле. Яңа ел алдыннан мунча тарихын өйрәнергә, бүгенгесе белән чагыштырырга булдык.

Автор:
Руфия Фазылова

ТАТАРЛАРДАН БАШЛАНГАН...

Татар мунчасының тарихы Болгар дәүләтенә барып тоташа. Багдад хәлифәсе әл-Моктадир илчелеге сәркатибе, гарәп сәяхәтчесе Әхмәт ибн-Фадлан 922 елда Болгарга килгәч, ирләр белән хатыннарның бергә юынуын күреп гаҗәпләнә. Бу турыда ул истәлекләрендә язып калдыра. Соңрак, X гасырның ахырларында, землянкалар казып, ирләр белән хатыннарның аерым юынганлыгы билгеле. Күрәсең, ислам дине кабул ителгәч, бабаларыбызның гореф-гадәтләренә, йолаларына үзгәрешләр керә.

Болгар музей-тыюлыгындагы мунча калдыкларыннан күренгәнчә, Болгар шәһәрендә – XIV гасыр урталарында ук җәмәгать мунчалары булган. Өч яклы, таштан эшләнгән бинаның калынлыгы 80–90 сантиметрга кадәр җиткән. Димәк, икеләнмичә, бабаларыбыз мунчада юынуның бөтен ләззәтен белгән дияргә була. Болгарларда су бар нәрсәнең башында тора, дигән ышану яшәгән. Ул яшәү чыганагы, пакълек билгесе саналган. Казан ханлыгы чорында Кремль мәйданында булган мунчалар турында бик күп тарихи китапларда язылган. Алар бик зур һәм затлы итеп сурәтләнә: мәрмәр бассейннар, фонтаннар белән. Ә мунчага су турыдын-туры күлдән килгән. Аның исеме дә – «Мунча күле». Көмеш сулы, дәвалау үзлегенә ия булган әлеге сулык турында халыкта төрле имеш-мимешләр, риваятьләр йөргән.

Гади халыкның мунчалары, әлбәттә, гадирәк була.

– Хәтта авыл мунчасы белән шәһәрнеке дә аерылып торган, – дип сөйләде филология, тарих фәннәре кандидаты, этнограф, КФУ мөгаллиме Руслан Бушков. – Шәһәрдә җәмәгать мунчалары булса, авылда күбесенчә кара мунчалар салганнар.

Руслан Бушков «Эх, Казан мунчасы» исемле китап язган. Архивларда утырып, тарихи фактларны «сөзгән». Каюм Насыйри һәм башка татар язучылары һәм зыялыларының хезмәтләрен өйрәнгән. Тәҗрибәле этнограф үзе өчен бик күп кызык ачышлар ясаган:

– Татар мунчасы тарихы турында сакланып калган документлар XII–XIII гасырларга карый, – дип сөйләде Руслан Бушков. – Юыну культурасы күпчелек халыкларга татар-

Фото: Рушан Хәялиев, Руслан Бушков китабыннан алынды

лардан күчкән дип әйтергә тулы җирлек бар. Мин, нигездә, шәһәр мунчасы культурасын өйрәндем. Шунысын төгәен әйтә алам: Казан ханлыгы чорында мунчада юынуның тәмен дә, шифасын да яхшы белгәннәр. Морзалар, хәлле кешеләрнең аерым мунчачылары булган. Алар себерке җыеп, мунчаны ягып, пар чыгарып торганнар. Бүген дә мунчаларда андый кешеләр бар.

Руслан Бушков Кремль мәйданындагы мунчалар тарихын дә өйрәнгән:

– Иван Грозный 1552 елда Казан ханлыгын басып алганнан соң әлеге мунчалар юкка чыгарыла. Соңрак атаклы саф сулы күлләр дә пычранып кибә. Ләкин нәрсә генә булса да, татарларда мунчада юыну культурасы юкка чыкмый. XVI–XVII гасырларда Казанда җәмәгать мунчалары популярлаша. Татарлардан күреп, руслар, башка милләт вәкилләре дә юынырга йөри. Бу шәһәр казнасына яхшы гына акча китерә. XVIII гасыр уртасында Казан Думасы җәмәгать мунчаларын эре сәүдәгәрләргә тапшыра. Нәтиҗәдә шәһәрдә тиз арада күпләп яңа мунчалар төзелә, шуның белән бергә аларга бәя дә арта. Мисал өчен, бер кеше өчен ике тиен торган мунчалар илле тиеннән берничә сумга кадәр күтәрелә. Билгеле инде, уңайлыкларына карап. Шулай булса да, юынырга теләүчеләр барыбер кимеми, ә арта гына.

Руслан Бушков тагын бер кызык фикер әйтте:

– Татарларның тормышы мунча белән башлана, мунча белән тәгәлләнә...

– Ягъни? – дим.

– Кендек әбисе балаларны мунчада таптырган бит. Аннан сабыйны шунда юындырганнар. Мунча беренче зөфаф төне уздыру урыны да, ир белән хатынның җәен йоклый торган җире дә булган. Йорттан мәет чыккач та керне монда юганнар. Кыскасы, татарлар тормышында мунча алыштыргысыз урын булып тора.

Байлар мунчасы гади халыкныкыннан аерылган, дип әйттек. Беренчеләре өчен ул юыну урыны гына түгел, ял итү, күңел ачу мәйданы да булган. Анда бүлмәләр киенү-чишенү, чәй эчү, ял итү, тәмәке тарту, парлану, юыну өчен махсус ясалган. Гадәттә мондый мунчаларда хезмәтче – мунчачы да тотканнар. Ул үз эшенең чын остасы саналган. Гади кешеләр исә мунчаларын бер яки ике яклы итеп эшләгән.

Руслан Бушков үзен «мунча җене кагылган» кеше дип саный. Шуңа да ул бу турыда китап язарга алынган. Айга бер-ике тапкыр озаклап парланып мунча керү – аның өчен гадәти.

– Мунчага барырга берничә көн алдан әзерләнергә кирәк, – дип аңлата Руслан Бушков. – Ашык-пошык юынып чыгу һич кенә дә мунча керү булмый. Тән белән җан ял итсен өчен, кимендә, өч сәгать парланып, чабынып юынырга кирәк. Мин үзем каен себеркесенә өстенлек бирәм. Озак итеп чабынып, парланып утырам. Мунчада бөтен җир кызарып-пешеп чыкканчы, йөрәкләр җилкенгәнче торырга кирәк! Ә күңел халәте яңадан туган кебеккә әйләнсен, бөтен арыганнар юкка чыксын, тән яңа туган сабыйныкы кук йомшак, керсез булсын...

КАРА МУНЧА «ПӘРИЕ»

Алда әйтелгәнчә, гади халык нигездә кара мунчада юынган. XX гасыр башында авылларда да ак мунчалар күренә башлый. Шулай да әле мин үскәндә безнең Апас якларында кара мунчалы кешеләр бар иде. Тәрәзәдән күреп: «Әни, кара, Сәлим абыйларның мунчасы яна», – дип кычкырганны хәтерлим. Бактың исә, ул яну түгел, ә ягу икән.

Кайбыч районының керәшеннәр яшәгән Мәлки, Иске Тәрбит авылларында бүген дә кара мунчалар бар. Бу якта гомумән ак мунчада юынмаган кешеләрне дә очратырга була. Мисал өчен, Иске Тәрбит авылында яшәүче Валерьян дәдәй Морозов.

– 80 яшемә җитеп, гомерем буе кара мунчада юындым, – диде ул горур кыяфәт белән.

Валерьян дәдәй үзенчәлекле, кызык кеше, эчендәгесе тышында аның. Кара мунчаның ягу серләре белән кызыксына башлагач, әллә шаяртып, әллә чын итеп:

– Ягып та күрсәтәм, кирәк булса, юындырып та чыгарам, – диде. – Аның берние юк. Мичкә утын тутырасың да, ишекләрне ачып куеп, ут төртәсең... Кыш көне мунчаны җылытырга ике зур кочак утын кирәк.

Ак мунчадан караны аеру өчен зур белгеч булу кирәкми – ерактан ук күренә ул. Беренчесе – морҗалы, икенчесе – морҗасыз. Әгәр инде кара мунчаны якканнар икән, әллә каян беленә – тирә-юньгә әчкелт-төчкелт төтен исе тарала.

– Хатын-кызлар мондый мунчаны якканда борыннарын томалый, – ди Валерьян дәдәй. – Мин алай эшләп тормыйм. Ис тими миңа. Ә менә керер алдыннан әйбәтләп ишекләрен ачып, төтеннәрен чыгарабыз. Ис тиюе бар.

PRESSA.RU

– Кара мунча ак мунчадан нәрсәсе белән аерыла? – дим.

– Ышту син, кара мунчаның һавасы әйбәт, коры була! Ничә кеше юынса да, идәннәр коры кала. Шуңа да мондый мунча 20, 30, 40 ел да тора, череми…

Әллә күреп үсмәгәнгә, кара мунча сәер тоелды миңа. Корым оясында юынган кебек. Ә Валерьян дәдәй, киресенчә, төтен бактерияләрне үтерә, мондый юыну бүлмәсе сулыш юллары өчен яхшы, дип саный.

Кара мунча ягу үзенчәлеге агыннан әллә ни аерылмый. Тегесендә дә, монысында да мич бар. Кара мунчага яккач, төтен морҗадан түгел, ә мич авызыннан, башка тишек-тошыклардан чыга. Биредә морҗа урынына бүрәнәгә тишек ясалган. Кара төтен шуннан тарала. Тишеккә сыймаган төтен исә мунчаның эченә тарала.

– Су монда җылына, – дип, Валерьян дәдәй мунча мичենә беркетелгән тимер савытка төртеп күрсәтте. – Мичкә су сипкәч, кап-кайнар пар күтәрелә, аның хуш исе!

Бабай сөйләгәндә күз алдыма кызык бер сурәт килеп басты: мунчадан чыкканда ялгыш кына стенага сөяләсең… Беттең! Корымнан арыну өчен, тагын бер сәгать юынырга кирәк. Тик Валерьян дәдәй белән андый очракларның булганы юк икән.

– Соң стенага сөялмә! Мунчага аек килеш керәсең бит! – диде.

Иске Тәрбиттә кара мунчалы кешеләрнең берсе – Зина түти. Ул аны буяп, яңартып куйган. Тыштан караганда, кара мунча димәссең дә! Эче дә матур гына.

– Ни генә дисәләр дә, ак мунча карага тормый инде! – диде ул. – Рәхәтләнеп юынабыз. Махсус сүтермәдем…

ӨЛКӘННӘР ТӘМЕН БЕЛӘ!

Бүген нинди генә мунчалар юк: япон, фин, рус, төрек мунчасы… Һәркайсы халыкны үзенчә кызыксындырырга, җәлеп итәргә тырыша. Берсендә файдалы үләннәр тутырылган су мичкәсенә кереп утырасың, икенчесендә тәнгә төрле майлар сылап, шәп массаж тәкъдим итәләр. Җаның ни тели, кесә калынлыгы нәрсәгә җитә, шунысына бара аласың.

Әмма ләкин парадокс: башкалабызда татарлар өчен генә мунча юк. Әлбәттә, сүз монда татарча сөйләшү турында бармый. Милли йөзебезне саклый торган, кәеф-сафа корып утырмый торган мунчаларны күздә тотуым.

– Самовар белән чәй кайнап утырган, коймак пешкән мунчага барасы килә! – диде Җиләкле бистәсендә яшәүче Сания апа. – Кая карама, ир-атлар сыра эчеп, кычкырышып утыра. Югыйсә, без аларны карарга бармыйбыз. Киров, Мәскәү районында юк безнеңчә, татарча ипле мунчалар.

Сания апаның хыялындагыча милли мунчабыз төзелсә, бик күркәм булыр иде. Тик, ашаган белми, тураган белә, дигәндәй, монда аерым сәбәпләр бар икән.

– Шәһәр халкы мунчага юыныр өчен килми, – дип шаккатырды Казан шәһәренең Киров районына караган бер мунча директоры. – Кайвакыт, ышанасызмы-юкмы, башлары күбекле килеш кайтып китәләр. Бүген юынырга элеккеге кебек чират торулар бетте. Мунчага килүчеләрнең күбесе бер максат белән килә – кәефләнеп алып, күңел ачу, ял итү. Шуңа күрә юынудан кала халыкка ял итәргә бөтен мөмкинлекне тудырабыз…

Һәр мунча пенсионерлар өчен аерым көннәр булдырган, гадәттә ул атна башы яки уртасы. Мисал өчен, гомуми залда юыну гадәти көннәрдә 180 сум торса, ташламалы көннәрдә пенсионерлар 150 сум түләп керә икән. Мин барган мунчада өлкәннәр йөри торган көннәр – чәршәмбе һәм пәнҗешәмбе иде. Ә иң кызыгы шунда: беренче көнне руслар, икенче көнне күбрәк татарлар килә икән.

– Һәр җомга алдыннан юынырга тырышабыз, – диде мунчага килгән Хәлимә апа. – Күрше йорттан иптәш хатын белән йөрим. Тагын берничә мөселман апасы килә. Гел бер сәгатьтә йөрергә тырышабыз. Парланып, сөйләшеп утырабыз.

– Ә нишләп ваннада гына юынмыйсыз? – дим Хәлимә апага.

– Беренчедән, минем аякларым авырта, ваннага менү авыррак. Икенчедән, монда юыну белән ваннаны чагыштырып булмый инде. Без бит мунча ярата торган буын.

Чынлап та, әле егерме-утыз ел элек кенә шәһәр халкы мунчага гаиләләре белән йөргән. Атна азагында җәмәгать мунчасына барып, гомуми залда юыну – бу гадәти хәл иде. Күпләр тулай торак, коммуналкаларда, иске баракларда яшәде. Ә анда кайнар су юк. Хәер, ваннасы булганнар да мунчага өстенлек биргән. Бүген дә өлкәннәр мунчаның тәмен белеп керә икән. Биредә эшләүче билет сатучы апа бер кызык хәл сөйләп үтте:

– Узган атнада бер әби көне буе ятты. Түләнгән вакыты узса да, куып чыгармыйбыз кешеләрне. Йөрәге тотып алганчы чабынган әби. «Ашыгыч ярдәм» машинасы чакырттык, укол кададылар. Әби ничек кайтып җитәр икән дип, кайгырышкан идек, ул яңадан чабынырга кереп китте. Директор әйтә: «Зинһар, әбине карап торыгыз, алай-болай була күрмәсен», – ди. Ә әби тагын ике сәгатькә якын юынып чыкты. Гомуми залларга нигездә шул өлкәннәр йөри инде. Ә яшьләр аерым яки люкс залларга килә.

Минем алдан бер төркем яшьләр тугыз сәгатькә акча түләп люкс залга кереп киткән иде. Анда ял бүлмәсе, бильярд, бассейн бар, ди.

– Юынырга вакытлары калырмы, белмим, – диде билет сатучы апа.

Декабрьнең унбишеннән соң мунчада буш заллар бик булмый икән.

– Яңа ел алдыннан ел да шулай, урыннарны алдан алып куеп, төркемләп киләләр, – диде мунча директоры.

31 декабрьдә гомуми зал ирләр өчен генә кичке алтыга кадәр эшли. Хатын-кызлар ул көнне мунчага бик килми икән. Ирләр, киресенчә, Яңа елга аяк басканчы, мунчада юынып калырга ашыгалар. Люкс бүлмәләр исә төне буена хезмәт күрсәтә. Яңа елны мунчада каршы алырга теләүчеләр дә бар икән.

...Заман белән бергә мунчага йөрү культурасы да үзгәрә. Күргәнебезчә, шәһәр мунчалары бүген яшь буын өчен күбрәк күңел ачу урынына әйләнеп бара. Тик акча артыннан куып, заман таләбе дип кенә мунчада юынуның чын асылын югалтмыйсы иде.

КИҢӘШ

Табиблар мунчаның файдасы бик зур, ди. Ул организмдагы шлакларны чыгара, үзәк нерв системасын җайга сала. Гел бер урында утырып эшләгән кешеләргә, авыр физик хезмәттә булганнар өчен файдалы. Тик бер яшькә кадәрге сабыйларга, өлкәннәргә, авырлы хатын-кызларга, шикәр диабеты, югары кан басымыннан интегүчеләргә кайнар мунча киңәш ителми. Хәер, мунча кергәндә һәр кешегә чама хисен югалтмау зарур. Мисал өчен, ләүкәдә 15–20 минуттан да озаграк утырырга ярамый. Хәл китә башласа, гомумән, чабынмаска кирәк, тиз генә юынып чыгу әйбәтрәк.

Мунча аяк кан тамырлары авыруларын кисәтү өчен менә дигән урын. Организмны чыныктыруның сыналган чарасы. Кеше мунчада булганда, төрле температура йогынтысын кичерә, менә шул организмның чыныгуына ярдәм итә дә.

«Эх, Казан мунчасы» китап авторы Руслан Бушков мунчадан соң.

PRESSA.RU

XXI ГАСЫР ФИЛАРМОНИЯСЕ: РЕТРОМЫ, АВАНГАРДМЫ?

«Филармония» төшенчәсе миңа балачакта зур бер сер кебек тоела иде. Әлфия Авзалова, Илһам Шакиров, Флера Сөләймановалар өебездәге тәлинкәдә һәр көн әйләнә, әбием исә аларны һәр куйган саен «филармония җырчылары» дип атый. Шулчакта тавышында горурлык та, ихтирам чаткылары да чагылып китә. Әнә шул балачак ихтирамын һәм горурлыгын ияртеп барам мин хәзер дә Татар дәүләт филармониясендә узган һәр концертка. Һәм ул тойгылар кимеми, ныгый гына төшә. Монысы – икеләтә сөенеч.

Автор:
Луиза Янсуар

РЕТРОДАН – ЗАМАНЧАЛЫККА

Татарстанда филармония 1937 елның июлендә эшли башлый, озак та үтми, Татар дәүләт опера һәм балет театры (1939 ел) һәм Казан дәүләт консерваториясе (1945 ел) ачыла. Нәкъ менә шушы өч оешма, тыгыз бәйләнештә торып, татар музыка сәнгатен үстерүгә һәм пропагандалауга зур өлеш кертә, Казандагы музыкаль климатны билгели. Филармониянең беренче җитәкчесе Л.А.Галиев, музыкага кагылышы булмаган партия кешесе исәпләнсә дә, яхшы музыкантларны туплый һәм филармониянең, коллективларның эшчәнлеген әйбәт итеп оештыра. Биредә 35 кешедән торган симфоник оркестр туплана һәм эшен башлап җибәрә. Беренче айларда ук эстрада-концерт бүлеге оештырыла. Россиядәге башка филармонияләрдән аермалы буларак, Татар дәүләт филармониясендә татар фольклоры кабинеты ачыла һәм Татар халык уен кораллары оркестры оеша. Бу аның баштан ук милли сәнгатьне үстерүне үзәккә куеп эшләве һәм халыкны агарту юнәлешен приоритет итеп алуы хакында сөйли. Әлеге кыйбласына ул хәзер дә тугры булып кала бирә.

Бүген ул үзенең янә бер яңарышын – мәдәни ренессансын кичерә дисәк, ялгышмабыз, дип уйлыйм. Исемендә грек аһәңнәре яңгырап торган, үзе, беренче карашка, ретро категориясенә карарга тиеш булган бу оешма, киресенчә, заманның иң алдынгы сафларында булуга дәгъва белдерә. «Филармония экраны» дигән төшенчә бар, мәсәлән, Казанда. Нинди дә булса чара оештырганда, ул сәхнәгә өстенлек бирәләр – чөнки, бу экран тамашаны уникаль фон белән тәэмин итәргә сәләтле. Ярый, монысы техник мөмкинлекләр. Хәер, яңарыш чалымнары филармониянең программа-репертуарында да, концерт-лекторийларының сыйфатында да, дөнья мәдәни контекстына интеграциясендә дә, хәтта ки тышкы вә эчке килеш-килбәтендә дә чагыла. Озын сүзнең кыскасы: Казанның мәдәни тормышында Татар дәүләт филармониясе үзенең мәртәбәле урынын алып тора бүгенге көндә.

Фотолар: Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе архивыннан

Үз тамашачысы белән шулай ук заманча, ягъни ачык һәм демократик шартларда аралаша. Ул, заман таләпләре кушканча, социаль челтәрләрдә актив, билетларны алу һәм бронь мәсьәләсендә, реклама юнәлешендә мобиль һәм уңайлы. Болар бүгенге динамикага корылган заманда бик мөһим. Дөрес, тамашаларга килгән чакта парковка мәсьәләсе тынгы бирми (уены-чыны бергә!), әмма монысы киләчәктә хәл ителә торган мәсьәләдер, дип ышанам. Болар белән мин ни әйтергә телим? Ә менә нәрсә: бүгенге көннең талымлы һәм таләпчән тамашачысы буларак (чөнки безгә бүген бик күп төрле мәйданнар тәкъдим ителә, һәрберсенең – үз үзенчәлеге, үз йөзе), мин XXI гасыр филармониясен сайлыйм һәм анда уздырган вакытымны заяга киткән дип исәпләмим. Ышаныгыз: ике-өч сәгать дәвамында күмелеп-онытылып Шутиков оркестрын, Айдар Фәйзрахманов коллективын, джаз-оркестрны җаныңа сендереп утыру эчке кодларны бөтенләй башка юнәлешкә көйли.

Сәнгати чикләр юылган, татар эстрадасының затлы укасы коелган бер заманда филармониянең анык урыны һәм позициясе булу – сөенечле күренеш. Филармонияләр, мәдәни институт буларак, хәзерге көндә Европа, Америка һәм Россиянең иң эре шәһәрләрендә эшләп килә. Театрлар, музейлар шикелле үк, шәһәрнең мәдәни статусын һәм йөзен дә билгеләүчеләр булып торалар. Әйтик, Вена филармониясенең алтын залында узган концертлар турында ишетеп беләбез без, экспериментларга һәрчак ачык булган Нью-Йорк филармониясе симфоник оркестрының масштаблы чыгышларын...

Филармония дигәч, күз алдына артистларның һәм һәртөрле коллективларның иҗатын пропагандалау, концертлар оештыру белән шөгыльләнүче бер институт килеп баса. Әмма аның бурычы күпкә киңрәк: ул музыка сәнгатен киң массаларга тарату, дәресләр, лекторийлар уздыру белән дә шөгыльләнә. Бүгенге көндә ул яшь тамашачылар – балалар, мәктәпләр белән актив элемтәдә тора.

Белүебезчә, беренче филармонияләр XIX гасырда Европа һәм Америка шәһәрләрендә барлыкка килә – Петербургта, Мәскәүдә, Бакуда, Берлинда, Лондонда, Нью-Йоркта. Алар нигездә симфоник музыканы пропагандалый. XX гасырда инде филармонияләр Европаның социалистик илләрендә дәүләт оешмалары булып әверелә. Бу аңлашыла да: сәнгатьнең башка төрләре шикелле үк, музыка да идеологик корал буларак зур роль уйнаган еллар бу. 1976 елда СССРда гына да 136 филармония исәпләнгән. Бүгенге көндә Россиядә аларның саны 50гә дә тулмый. Үзгәртеп кору, капиталистик рельсларга басу һәм сәнгатьнең дә язмышы билгесез кулларга күчү чорында күпчелек филармонияләр үзләрен саклап кала, яңа шартларга яраклаша алмыйлар.

«ТӨП КРИТЕРИЙ – ПРОФЕССИОНАЛЬЛЕК»

– Без дә шактый зур югалтулар белән кичтек ул елларны, – дип сөйли Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе директоры Кадим Нуруллин. – Бинабыз бик таушалган, коллективларның хәле киеренкеләнгән иде, артистларга түләргә, аларны кайгыртырга кирәк. Филармониядә теркәлгән һәр артист – ул безнең коллективның гына түгел, ә милли сәнгатебезнең дә асыл берәмлеге, ул кадерсез булып йөрергә тиеш түгел. Әнә шундый миссиясе дә бар филармониянең. Без нигездә килешү буенча эшлибез хәзерге көндә, бу дөньякүләм кулланыла торган система. Ә теге чакларда шактый читенгә туры килде артистларга да, җитәкчелеккә дә... Безнең бинаны арендага биреп торып акча юнәтергә тырышкан чакларыбыз да булды. Аренда концертларының планда 70%ка кадәр җиткән чаклары булды. Шөкер, республика җитәкчелеге, ул чактагы Президентыбыз Минтимер Шәймиев безне үз канаты астына алды. Рөстәм Миңнеханов та филармониянең хәле белән һәрчак кызыксынып тора, зур кайгыртучанлык күрсәтә. Болар безгә үсәргә бик нык ярдәм итте. Филармония мескен хәлдә яшәргә тиеш түгел, чөнки ул – дөньякүләм масштабтагы оешма. Чит илләргә чыкканда безнең артистлар, коллективлар республиканы күрсәтә һәм данлый, шул ук вакытта, гастрольләр, турлар вакытында алар югары һөнәри осталыкка да ирешә, дәрәҗәсен күтәрә. Тирә-юньдә ни барын белмичә, бары тик үз мирасыңа гына күмелеп ятып булмый, бүген без борынгы, сыналган мирасны заманча форматта тәкъдим итүгә йөз тотарга тиешбез. Әмма мин үзем дә, безнең коллектив та – гаҗәеп консерваторлар, без иң беренче чиратта милли

1

2

3

1. Музыка-фольклор кабинетында. 1938 ел.

2. Фронт бригадасы. 1942 ел.

3. Бер төркем артистлар С.Садыйкова белән. Мәскәү, 1969 ел.

мирасны саклауны, аның дәрәҗәсен төшермәүне үзәккә куеп эш итәбез.

Бүген безнең олысына да, кечесенә дә тәкъдим итәрдәй искиткеч бай репертуарыбыз бар. Үзебезнең җырчыларны халыкка күрсәтәбез, шулай ук дөньякүләм танылган сәнгать әһелләре һәм коллективлары белән бик теләп хезмәттәшлек итәбез. Һәркем, монда килеп, җан азыгы алып кайтып китә ала, минемчә.

– Ә әлеге дә баягы аренда мәсьәләсе белән эшләр ничегрәк тора? Нинди критерийлар буенча сайлыйсыз бүген кемнең аяк баса алуын филармония сәхнәсенә? – дип төпченәм.

Кадим Назыйрович тыенкы гына елмаеп куя:

– Сәнгатьтә критерий бер генә була ала, минемчә: профессиональлек. Менә шуңа зур игътибар бирәбез. Рәшит Ваһапов, Җәваһирә Сәлахова, Вафирә Гыйззәтуллина, Илһам Шакиров, Лундстрем, Деринг җитәкчелегендәге оркестрлары белән дан тоткан филармония икәнлеген онытып җибәрмәскә кирәк бер генә мизгелгә дә. Без шуларны тыңлап, ишетеп, алар рухында тәрбияләнеп үстек. Безгә кадәр – әти-әниләр, әби-бабайлар. Менә шушы чылбырны өзмәү зарур: сәнгать ул югары кимәлдә булырга тиеш. Хәзерге көндә цензура юк, һәркем үзе теләгәнчә һәм булдыра алганча «сәхнә тота». Мин монысы ак, монысы кара, дип мөһер сугып утырырга җыенмыйм, әмма филармония сәхнәсе – ул затлы сәхнә. Монда килгән тамашачы, фойега аяк басуга, затлылык, тантаналылык атмосферасына күмелергә тиеш, шулай булган очракта, ул инде сәхнәгә артистлар чыккан мизгелдә чын-чынлап сәнгатькә күмелергә әзер булачак. Бу гап-гади тәрбия. Элегрәк дворяннар бит балаларын кечкенәдән сәнгатькә мәхәббәт уятып тәрбияләгәннәр – музыкага, иң беренче чиратта. Аксөякләр арасында музыканы яхшы белмәү оят саналган. Бездә, мөселманнарда, музыкага мөнәсәбәт икенчерәк, билгеле. Әмма гасыр башында хәят үзгәргән, хәзер ул тагын да ирекләрәк. Бүген безнең сәхнәдә дөньяның иң күренекле музыкантлары, артистлары чыгыш ясый, аларны, килеп, тере килеш тыңларга, ишетергә, карарга мөмкин. Бәяләр дә ул кадәр тешләшә димәс идем.

Дүрт фасыл тулы – музыка. Һәм ул гына да түгел – биюләр, эбру сәнгате, ком анимациясе, спектакльләр һәм тагын әллә никадәр сый-нигъмәт. Бары тик вакытың гына җитсен! Хәер, алдан билгеләп, планлаштырып куйганда җиткерергә мөмкин вакытны – сыналган ысул. Ә инде бәяләр, дигәннән. Филармония ел саен абонементларын сата торган махсус көннәр билгели. Мондый көннәрдә аларны чынлап та шактый демократик суммага алырга мөмкин. Балалар абонементлары да – аерым бер тема биредә.

«ТУЛЫ КАНЛЫ ТОРМЫШ БЕЛӘН ЯШИБЕЗ»

– Без шулкадәр тулы канлы тормыш белән яшибез, – ди ТР Фольклор музыкасы ансамбле коллективы җитәкчесе Айдар Фәйзрахманов. – Гастрольләр, дисеңме, фестивальләрме, үзебезнең тамашачы өчен әзерләнгән концертлармы. Фольклорга игътибар хәзер бөтен дөнья күләмендә күзгә күренеп көчәйде, бу глобальләшү шартларында кешеләрнең тамырларын барлау белән дә бәйледер, бәлки. Безнең ансамбльне кайда гына барып чыксак та зур кызыксыну белән каршылыйлар, алкышларга күмәләр. Шуңа да үзебезнең профессиональлеккә зур игътибар бирәбез. Республиканы дөнья күләмендә тәкъдим итү искиткеч зур җаваплылык ул, син үз милләтеңнең йөзенә кызыллык китерә алмыйсың. Ә Татарстан һәм Казан тамашачысы алдында чыгыш ясаганда, аларның бәясен дә тоеп торасың. Монысы – үзе бер имтихан. Мин филармониянең бүген бик матур, ямьле чоры дип уйлыйм, без заман белән бергә атлыйбыз, шул ук вакытта очсызланмыйбыз, үз дәрәҗәбезне саклыйбыз. Яңа буынны тәрбияләүгә зур игътибар бирелә – менә бу шәп нәрсә. Районнарга чыкканда, балалар алдында чыгыш ясаганда, зур канәгатьлек алам. Кайчандыр без авыллардагы йолалар, бишек җырлары, кечке уеннар эчендә алып үстек милли тәрбияне, хәзер чылбыр өзелде, шуңа да аны махсус башкарырга кирәк, бу бик мөһим.

Фольклор музыкасы ансамбле 1999 елда ТР Мәдәният министрлыгы инициативасы белән оеша. Бүгенге көндә аның коллекциясендә 15 сюжетлы программа концерты бар, гастрольләр географиясе җир шары буйлап таралган. Фольклор ансамбле филармониянең икенче бер данлыклы коллективы – Анатолий Шутиков җитәкчелегендәге ТР Халык уен кораллары оркестры белән дә чыгыш ясый. Әлеге оркестрның туган елы – 1993 ел. Бу коллектив Татарстанның гына түгел, ә Россиянең һәм дөньяның әйдәп баручы җырчылары белән бергә эшләгән концерт программалары белән билгеле. Болар – Илһам Шакиров, Зилә Сөнгатуллина, Венера Ганиева, Юрий Борисенко, Галина Ластовка, Георгий Ибушев, Рөстәм Маликов, Ренат Ибраһимов, Зураб Соткилава, Артур Эйзен, Елена Образцова, Ки Юнг Янг, Каеко Амано, Даниил Штода һ.б.

– Музыка ярдәмендә төрле милләтләрне һәм халыкларны тоташтыручылар дип атар идем мин безнең коллективны, – ди Анатолий Иванович. – Чын сәнгать шуның өчен яратылган да – чикләрне киңәйтер, хәтта юкка чыгарыр өчен. Реаль

Татар дәүләт филармониясенә Габдулла Тукай исеме бирелүгә 70 ел тулу уңаеннан оештырылган концертта. 26.02.2016.

Бүгенге филармония – белем бирү, сәнгатьне киң массаларга җиткерү мәйданы да. Моның белән филармониянең Музыкаль-әдәби лекторие коллективы шөгыльләнә. Ул 1945 елда оеша, 1994 елда реорганизация кичерә, «Опера һәм камера музыкасы бүлеге» булып кала. 2012 елда лекторий кабат торгызыла һәм 11 артисттан оеша: ТР халык артисты Георгий Ибушев, ТР атказанган артисты Ригина Вәлиева, халыкара конкурслар лауреатлары Любовь Добрынина, Гөлнара Байназарова, Оксана Шәйдуллина, Айтуган Вәлмөхәммәтов, Әлфия Мансурова, Ильяс Камалов, концертмейстер, ТР атказанган артисты Роман Чуйнов һәм лектор-музыковед Алсу Мөлекова. Музыкаль-әдәби лекторийның җитәкчесе – ТР атказанган артисты Владимир Васильев.

чикләр турында түгел, беренче чиратта, безнең аңыбыздагы чикләр турында әйтүем. Халык уен кораллары белән бөтен төр жанрларны да, стильләрне дә уйнап була, бернинди проблема юк. Без моны үз мисалыбызда сынап карадык һәм исбатлап күрсәттек инде.

Сүз уңаеннан, оркестр һәр ел саен балаларны үзенчәлекле Яңа ел тамашалары белән сөендерә. Шулай ук 20 елдан артык нәни тамашачыларга абонемент концертлар циклы да уздыра.

ТР филармониясе джаз-оркестрын Россиянең иң алдынгы джаз-коллективлары рәтенә генә кертеп калмыйлар, ә Олег Лундстремның турыдан-туры дәвамчысы буларак та югары бәялиләр. Казан биг-бэнды дөньякүләм джаз традицияләрен саклаучы һәм яңа заманга китереп җиткерүче буларак та абруен югалтмый, сүз, иң беренче чиратта, Каунт Бейси, Глен Миллер оркестрлары турында бара, билгеле. Шуңа да оркестрның сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижеры Анатолий Василевскийның сүзне Лундстремнан башлавы бер дә гаҗәп тоелмады:

– Язмышымның Казан һәм Казан филармониясе белән бәйле булуына төп сәбәпче, әлбәттә, Лундстрем һәм джаз. Гашыйк идем мин аның оркестрына! Алар 1958 елда Архангельскига килделәр, әле теге легендар Шанхай составы белән. Без, музыка училищесы студентлары, өнсез калдык, башыбыз-аягыбыз белән джазга чумдык. Миңа Ленинград консерваториясенә рекомендация бирделәр, әмма мин дә, туганым Владимир да Казанны сайладык. Казанга мин Лундстремга киләм дип килдем. Аның белән очрашу тормышымдагы олы бер вакыйга булды. Ул инде үзе Казанда булмаса да, Олег Леонидович безгә берничә тапкыр репетицияләргә килде, киңәшләрен бирде. Казанда джаз традицияләренең дәвам итүе аны куандыра иде. Репертуар белән дә ярдәм итте ул безгә. Глен Миллерның фирменный ноталарын күчереп язып алырга биреп торды, аларга орынганда, кулларымның ничек калтыраганын хәзер дә хәтерлим. Чын хәзинә бит алар! Хәзер менә интернеттан теләгән нәрсәңне табарга була... Ә ул чакта ноталарны төннәрен күчереп яза идек.

Миңа калса, Татарстанда джазның киләчәге яхшы булачак. Ул хәзер тармаклана – аның төрле агымнары, юнәлешләре барлыкка килеп тора. Безнең коллективка килгәндә, состав саллы, шул ук вакытта яшьләргә йөз тотабыз. Безнең үз тамашачыбыз бар, ул инде безгә күп еллар буе тугрылыклы, яшь буын да даими өстәлеп тора. Шулай булгач, безгә әле эшлисе дә эшлисе. Мин «джаз татарга хас музыка түгел», «джаз бетәчәк» дигән сүзләрне ишеткәндә, безнең оркестрның кичәгесе һәм бүгенгесе турында уйлыйм һәм киләчәгенә тагын да ныграк ышанам.

«АКЧА КИТӘ ДӘ БЕТӘ, ӘММА – НӘРСӘГӘ?»

Эльза Нәгыймова, укытучы, 2 бала әнисе:
– Филармониянең балалар абонементы – зур хәзинә. Икенче ел йөрибез, олы улым бик яратып кабул итә барлык тамашаларны, кечкенәсенә әле иртәрәк бераз. Ни өчен йөртәсең баланы концертларга, ул бит аларны барыбер аңламый, дигән танышларым да булды. Әмма бу минем максатым иде: кечкенәдән классик сәнгатьне белеп үссеннәр. Без бит авылда берни күрмичә үстек, кая инде ул оркестрларны тыңларга йөрү! Балаларымның сәнгатьне тоя, белә торган затлы шәхесләр булып үсүен телим. Акча китә дә бетә ул, әмма нәрсәгә китә бит – шунысы мөһим.

Айнур, КФУ студенты:
Миңа дусларым «филармоник» дип төрттерәләр. Беренчедән, ул безнең өйгә якын, икенчедән, әнием – музыкаль «маньяк» минем. (Көлә.) Әни белән берничә тапкыр барган идем, болай, кызык өчен генә. Джазга, Даниил Крамерга, Шутиков оркестрына. Аннары лекторий кызыксындырды. Шуннан китте инде. Үзем дә сизми калдым. Кеше үзенә рәхәт булган урынга кат-кат кайта бит, минем очракта да – шулай.

PRESSA.RU

«ҮЗГӘРЕШ ҖИЛЕ»: «УЛ ИҖАТ ЛАБОРАТОРИЯСЕ БУЛЫРГА ТИЕШ»

Әзерләде:
Луиза Янсуар

Фотолар «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгыннан һәм шәхси архивлардан алынды. Автор: Салават Камалетдинов.

«Үзгәреш җиле» соңгы ике ел эчендә республикада иң каршылыклы фикерләр тудыручы, иң күп тәнкыйть ителүче, шулай ук күкләргә чөеп макталучы да проектларның берсе булды дисәк, мөгаен, ялгышмабыз. Икенче чирканчыктан соң инде чагыштырып карарга да, күпмедер күләмдә нәтиҗәләр ясарга да мөмкин, шуңа быелгы концерттан соң, аны оештырган коллективның, музыка сәнгатенә кагылышы булган шәхесләрнең бәясен, фикерләрен ишетү аеруча кызыклы тоелды.

PRESSA.RU

Венера Ганиева, «Үзгәреш җиле» проектында вокалистлар белән эшләү өчен җаваплы педагог:
– Быелгы «Үзгәреш җиле», иң беренче чиратта, масштабы һәм географиясе белән аерылып торды: үзебезнекеләр белән беррәттән, Африка музыкантлары да катнашты проектта, Италия һәм Россия башкаручылары да. Алар да татар халык җырларын татар телендә яңгыратты. Бу безнең милли сәнгатебезнең халыкара күләмдә таныла баруы дигән сүз. Узган елгы концерттан соң тәнкыйть сүзләрен күп ишетергә туры килде, әмма быел инде аранжировка ясаучылар үзләре дә татар музыкасына хас үзенчәлекләргә ияләште, алар аның милли нюансларын тоеп эш итте. Аутентик яңгырашны заманча форматта тәкъдим итү – бөтен дөнья әлеге практикага күчте бит инде, без дә калышырга тиеш түгелбез.

Эльмир Низамов, композитор:
– «Үзгәреш җиле», һичшиксез, кирәкле фестиваль. Беренчедән, ул безнең тамашачыны тәрбияләр, аның зәвыгын үстерер өчен кирәк. Фестивальдә әйбәт тавышлы сәләтле җырчылар һәм музыкантлар катнаша. Быелгы «Үзгәреш җиле» минем өчен тагын да үзенчелеклерәк булды, чөнки минем җырым да яңгырады. Бу минем өчен зур горурлык һәм намус эше.

Миләүшә Тәминдарова, ТР Камера хоры җитәкчесе һәм дирижеры:
– «Үзгәреш җиле», башка күп кенә проектлар шикелле үк, ТР җитәкчелеге инициативасы белән уздырылуы ук гаять зур әһәмияткә ия. Мондый проектлар бик кирәк. Мин аны хуплыйм һәм ул бар яклап үсәргә тиешле дип саныйм. Ул киләчәктә татар эстрадасын реформацияләү буенча үзенә күрә бер лабораториягә әверелсен иде. Ә моңа җырчылар, музыкантлар, аранжировка ясаучылар, педагоглар, коучлар һәр елны алышынып торган очракта, төрле командалар эшләгән хәлдә генә ирешергә мөмкин. «Алло! Без талантлар эзлибез!» һәм аларга үзләрен сынап карарга мәйдан бирәбез – төп принцип. Бездә талантлы яшьләр бик күп, аларны чынлап та зәвыклы музыка тудыручылар итеп тәрбияләргә кирәк. Тәнкыйтьләп утырырга мөмкин, әмма ул тәнкыйтьләгән кеше яхшырак итеп эшләп карасын, бирегез аңа мөмкинлек! Менә шунда үзгәреш булачак. Минем «Алтын граммофон» проекты һич кенә дә «Үзгәреш җиле»нә альтернатива, капма-каршы нәрсә түгел, ә шушы юнәлештә тагын бер төрле итеп эксперимент ясап карау ысулы. Мин бирегә «Үзгәреш җиле» командасын чакырам, һәм аларның фикерләре миңа бик тә кызыклы булачак. Без, тәнкыйтьләшеп ятмыйча, барыбыз бергә эш итсәк кенә, нәрсәгә дә булса ирешә алачакбыз.







Раяз Фасыйхов, җырчы:

– Бик матур проект, ике ел рәттән катнашам, чакырсалар, тагын да катнашырга риза. Профессиональ җырчы буларак үсәргә, дөньякүләм танылган музыкантлар белән эшләргә мөмкинлек бирә ул. Максаты – татар җырларын дөньякүләм стильләргә сыештырып, башка халыкларга да җиткерү. Җырның мелодиясе шул килеш кала, әмма аңа туры килгән заманча аранжировка ясала һәм башкару рәвеше үзгәрә. Ләкин шуны аңларга кирәк: бу әле татар эстрадасы шулай яңгырарга, шундый булырга тиеш, дигән сүз түгел.

Алинә Шәрипҗанова, җырчы:

– Профессиональ җырчы буларак, 15 ел дәвамында татар эстрадасы сәхнәсендә чыгышлар ясыйм, «Алтын барс» та алганым булды, «Болгар радиосы премиясе»н дә. Болары да мөһим, билгеле, әмма безнең татар эстрадасында профессиональлекне арттыру өчен эшләнгән масштаблы, олы проект көтелә иде. Мәскәүдән килгән музыкантлар, аранжировка осталары милли көйләребезне хөрмәт итеп, яратып, аларга яңа сулыш өрде – бу зур хезмәт. Моны оештыручы командага һәм республика хакимиятенә, җыр сәнгатенең бер вәкиле буларак, чын күңелдән рәхмәт әйтәсем килә: татар җыр сәнгатен затлы, интеллигент тамашачы кабул итәрдәй дәрәҗәгә чыгарырга мөмкинлек тудырулары өчен. Бездә әле мондый проект юк иде. Фестивальләр, әлбәттә, күп, тик тере тавышлы, тере оркестрга башкарылган, бөтен дөньядан җыелган «беренче классы» музыкантлар уйнавын күздә тоткан, башкаручыларның да менә дигәннәрен сайлап оештырылганы… – бу уникаль күренеш. Образларны төрләндерү, ел саен яңа җырлар үзләштерү безгә, артистларга, процесс буларак та кызыклы, профессиональ яктан үсәргә дә – зур этәргеч. Мин бу проектта катнашуыма чын-чынлап шатмын: татар җыр сәнгатен яңа баскычка күтәрү юнәлешендә барган үзгәрешләр җиленең эчендә кайныйбыз, икенче ел инде бу өлкәдәге экспериментларда катнашабыз. Зур эшнең өлеше булу куандыра.



Зарина Вильданова, җырчы:

– Минем өчен «Үзгәреш җиле»нең 2016 елда узган беренче концерты үк зур вакыйга һәм бәйрәм булды. Ике зур окрестр, искиткеч музыкантлар, гаҗәеп артистлар… Танылу дәрәҗәсе турында сүз йөртмим, юк, ә көйне, телне тоюлары һәм вокал техникасы ягыннан үз эшенең осталары булуларын әйтәм. Без яңа вектор белән барабыз. Төп максат: онытылган җырларыбызны яңа дәрәҗәгә күтәрәбез. Минемчә, бу бик мөһим, ә артистлар өчен, үз чиратында, шактый катлаулы, олы миссия дә. Нәрсә генә әйтсәләр, ничек кенә тәнкыйть итсәләр дә, җил исте, һәм мин моны төрле концертларда, фестивальләрдә күрәм. Без дөрес юлга бастык, дип ышанам.

PRESSA.RU

Фото: Александр Ефремов.

РЕСТОРАН «БРАССЕРИЯ» ПРИГЛАШАЕТ:

НА ДЕЛОВЫЕ ОБЕДЫ

УЖИНЫ

КОНФЕРЕНЦИИ

КОФЕ-БРЕЙКИ

ПРЕЗЕНТАЦИИ

3 зала вместимостью от 15 от 150 человек

+7 (843) 222-5555

г. Казань, переулок Дуслык (Большие Клыки), дом 8

БРАССЕРIЯ

РЕСТОРАН

* Брассерия Ле Грилл с 2014.

Реклама

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Элек Казанда **КАЙДА** Яңа ел чыршысын куя торган булганнар

«Туган-авылым» рестораны шеф-повары Яңа елга **НӘРСӘ** әзерли

Казан ханлыгында **КЕМНӘР** хан була

Татарстан «Кырымы» **КАЙДА** урнашкан

Бичураны **НИ ӨЧЕН** котыртырга ярамый

PRESS.RU

Кирилл Пономарёв коллекциясендәге иң карт Кыш бабай.

КЫШКЫ ҺӘМ... ШУНДЫЙ **ҖЫЛЫ!**

Ул яшеренми дә кебек, тик һич сиздермичә килеп җитә. Аны көтәсең дә шикелле, тик ул һәрвакыт кинәт ишек шакый. Ел саен 31 декабрьдә, зур кар өеме кебек шаккаттырып, киләчәккә ниндидер яхшылыклар вәгъдә итеп килә дә төшә ул. Спас манарасындагы сәгатьләр, текелдәүләрен акрынайтып,

Автор:
Муса Юлдашев

Иң яраткан бәйрәмебезнең төп билгесе – Яңа ел чыршысының тарихы христиан дине белән бәйле. Ләкин вакытлар узу белә Вифлеем йолдызын биш очлы совет йолдызы алыштыра, ә хәзер исә чыршы очына йә көмеш боз сөңгесе куялар, йә аны бөтенләй «шәрә» калдыралар. Дини-сәяси йогынты инде гомумән сизелми. Ләкин матур, игелекле персонажлары булган кышкы әкият һич югалмый...

Казанның күренекле коллекционеры Кирилл Пономарёвның вакыт елгасына чумган артефактлар белән шыгрым тулы антиквар кибетендәге бронза сәгатьләр һәм берсеннән-берсе төз «антик» вазалар артыннан инде бераз таушала башлаган Кыш бабайлар кыенсынып кына дөньяга карап тора. Аларның иң яше дә инде җитмешне узып барадыр.

ХӘЗЕР АЛАР ЛАЕКЛЫ ЯЛДА

Уйлап карасаң, бу Кыш бабайлар үз гомерләрендә Казан балаларына никадәр шатлык-куаныч китергән дә, аларга ышанган, табынган чакларда бер Яңа ел төнендә генә дә мөхтәрәм аксакалларга ничаклы караш юнәлгән булгандыр. Могҗиза иясе бу бабай, шәһәр утлары астында алтын нурлар чәчеп торган карны шыгырдата-шыгырдата атлап, подъезд ишеген ачып керә, кыңгырауны чылтыратып, бихисап кешене бераз гына булса да бәхетлерәк итә – бу хәл өндә була, ләкин ешрак төштә генә шул. Капчыгы зур түгел бит, һәркемгә җитеп бетми! Шуңа күрә дә, бала кеше, үсә төшкәч, мамык сакал таккан бабакайга карап, төрлечә төрттерә башлый.

Инкыйлабка кадәр Яңа елны ничек бәйрәм итүләрен без китаплардан укып белә алабыз. Анда барысы да җентекләп теркәп куелган! Антон Павлович Чеховның «Ёлка» дип исемләнгән чәнечкеле хикәясе бар. Анда бүләк өләшү вакыйгасы фәлсәфи мәгънә ала.

«Биек, мәңге яшел тәкъдир чыршысына тормыш форсатлары элеп чыкканнар... Монда агачның төбеннән очына кадәр шәп карьералар, бәхетле очраклар, уңышлы кияү-кәләшләр, отышлар, югалтулар, борынга чиртүләр һәм башкалар эленеп тора. Чыршы янында яше балалыктан күптән узган балалар таптана. Язмыш аларга бүләк өләшә...

– Балалар, кайсыгыз бай сәүдәгәр хатынын алырга тели? – дип сорый ул, баштанаяк энҗе-мәрҗәнгә,

чәркәләрнең мөлдерәп тулганын сабыр гына көтә. Ниһаять, галәмәт зур алтын кайчылар эшкә керешә дә, иске елны архивка җибәреп, вакыт тасмасын кисеп ташлый. Шампан бөкесе люстрага оча, ә аның җитез күбекләре канга тарала... Бүлмә почмагыннан – урман, табыннан мандарин исе агыла, ә каерып ачып куелган тәрәзәдән башлыгына яңа саннар язылган үҗәт бер малай үрмәли.

PRESSA.RU

бриллиантларга төренгән кызыл йөзле сәүдәгәр хатынны ботактан алганда… – Плющихада ике өе бар, тимердән ясалган өч кибет, бер сыраханә һәм ике йөз мең акчасы белән! Кайсыгыз тели?

– Миңа! Миңа! – Сәүдәгәр хатынга йөзләгән кул үрелә. – Сәүдәгәр хатынны миңа бирегез!

– Өелешмәгез, балалар, дулкынланмагыз… Барыгыз да канәгать калырсыз…» Һәм хикәя шул рәвешле дәвам итә.

– Хәзерге Кыш бабайлар чит илнең Санта Клаусына охшаган, – дип зарланып куя Кирилл Николаевич, – ләкин безнең үзебезнеке, бераз онытылган булса да, күңелебезгә бик якыны бар бит. Антиквар кибеттә сакланып калганнарның иң өлкән яшьтәгесе – папье-машедан инкыйлабка кадәр эшләнгән Кыш бабай. Аның тышкы кыяфәте буенча Николай Чудотворец иконасыннан күчереп алынганлыгы бик ачык күренә, рәссам моңсу йөзне мөлаем елмаюга гына алыштырган. Карагыз әле, бабай нинди тере килеп чыккан! Мондый кыяфәттә ул – православ изгесе түгел, ә ак сарык толыбы кигән үзебезнең тапкыр рус ир-аты. Яңаклары салкыннан янып тора, сакалын исә, әйтерсең, бәс сарган да ул ак төлке якасыннан салынып тора. Күзләре хәйләкәр. Чыршы ботаклары белән капланган кечкенә йортында ул кичләрен уенчыклар ясаган һәм менә балаларны Раштуа белән котларга чыккан. Һәр детале бик нечкә итеп, җиренә җиткереп ясалган. Әйтерсең, Кыш бабайны икона язучы тиен койрыгыннан эшләнгән нәфис пумала белән буяган. Кулдан ясалган бу хезмәткә бик озак карап торырга, бик озак сокланырга була. Билгесез останың кул җылысын сеңдергән сын башта уйланганнан күпкә олпатрак, тәэсирлерәк килеп чыккан. Бу инде гади әкияти герой гына түгел, халык зирәклеген һәм аның гореф-гадәтләрен саклаучы образ да.

Кыш бабайны караганда тагын нәрсәгә гаҗәпләнергә мөмкин? Россиянең чит илдән кергән бөтен нәрсәне никадәр тиз адаптацияләвенә, үзебезчә әйтсәк, җайлаштыруына һәм читне үзеңнекенә әйләндерү сәләтенә. Палестина пальмасы яфраклары бездә кабарып торган ботаклы чыршыга әйләнә. Төркиянең Дәмрә каласыннан булган Николай Чудотворец Кыш бабайга үзгәреп куя. Болганчык Иордан

елгасын бәкедәге үтә күренмәле купель алыштыра, купшы яңгырашлы Тәүрат исемнәре бөтенләй танымаслык булып гадиләшә: Иоаан – Иванга, Иеремия Еремага әйләнә… Гүя искиткеч останың күренмәс кулы чит илдән кергән катлаулы нәрсәне Россия өчен гадиләштереп юнган-шомарткан.

ЧЫРШЫДА – ТАНКЛАР ҺӘМ ИЯРЧЕННӘР

Кирилл Николаевич тартмадан совет заманындагы көмеш йөгертеп ясалган чыршы уенчыкларын чыгара. Сагыну хисләре уянып куя! Аларны чыршы ботакларында йомшак кар ролен уйнаган мамыкка төреп саклыйлар иде. Чыршы бизәү бик сөенечле вакыйгага әйләнә, гап-гади бүлмәдә дә серле җемелдәгән утлар пәйда була. Өлкәннәр бу бүлмәгә кергәч, сокланып күз йөртә. Күңел кыллары ничектер йомшарып китә иде.

Уенчыкларның темасы үз чорына туры килгән. Казанның Дворян собраниесе бинасында Беренче бөтендөнья сугышы алдыннан куелган гаҗәеп зур чыршы, халыкның патриотик хисләренә туры китереп, тулысынча солдат сыннары, туплар һәм крейсерлар белән бизәлгән. Сүз уңаеннан, Казан губерниясенең төп чыршысына һәр гимназия һәм училищенең кулдан ясалган зур уенчык җибәрү гадәте яшәп килгән.

Чыршы уенчыгының илдәге вакыйганы чагылдыруы – мәҗбүри шарт. Россия күкләрендә аэропланнар пәйда булып, очучылар халык героена әйләнгәч, чыршы ботакларын шунда ук ошбу темага уенчыклар бизәгән. Совет чорлары да бу кагыйдәдән чыгарма түгел. Чыршы бизәүне бер тыйганнар, бер рөхсәт иткәннәр, ләкин соңыннан, дини сәбәпне читкә куеп, чыршыны хакимият кулындагы «мамыктай йомшак» пропаганда чарасына әйләндергәннәр дә үсеп килүче буынны тәрбияләүдә куллана башлаганнар. Балалар чыршыга буденовка кигән кызылармеецлар, тачанка-ростовчанкалар элгән һәм, тизрәк үсеп җитеп, Эшче-крестьян Кызыл армиясе сафларына басарга хыялланган. Бөек Ватан сугышы елларында чыршыларны автоматчылар, танклар, истребительләр һәм хәтта «Катюша»лар белән бизәгәннәр. Чирәм җирләрне үзләштергәндә, тракторлар модага керә; галәмгә очу башлангач, ясалма иярченнәр,

PRESSA.RU

ракеталар, скафандрлы космонавтлар рәвешендәге уенчыклар өстәлә. Ылыслы гүзәлне бүген исә төрле төстәге шарлар, кар бөртекләре, кечкенә фонарьлар бизи. Бернинди сәясәт тә юк! Шулай да балалар аны бик күптән – 1903 елда шагыйрә Рәисә Кудашева язган иске җырны җырлап бәйрәм итә. Россиядә Яңа ел гимны ул:

В лесу родилась ёлочка,
В лесу она росла,
Зимой и летом стройная,
Зелёная была.

«СЕЗНЕ КОТЛАРГА АШЫГАБЫЗ...»

Открытка килгәч, аны өйдәгеләргә кычкырып укыганнар, аннары буфеттагы пыяла артына тыгып куйганнар яки стена календаре тирәсенә җилпәзә кебек кадап чыкканнар. Бәйрәмнән соң открыткалар калын гаилә альбомына озатылган. Кайчак татар әбиләре шулар белән диварларны да бизәгән әле, хәтта иске шәмаил читләренә дә ябыштырып чыкканнар. Матур бит!

Кирилл Пономарёв коллекциясендә Яңа ел һәм Раштуа открыткалары да бар. Аларның күбесе язулы. Өч тиенлек маркаларына штамп сугылган. Димәк, бу тәбрикнамәләр адресатка ирешеп, аны куандырырга да өлгергән. Әйтик, менә яңа телефон аппараты (ул чорда исең китәрлек техник яңалык) янындагы җилбәзәк, шаян кыз берьюлы ике трубкага ябышкан, күрәсең, бер үк вакытта ике егетен дә котлый. Менә шундый юмор!

Аны Казанга Түбән Новгородтан 1914 елның 22 декабрендә җибәргәннәр, ә инде ике көннән Гостинодворская (хәзерге Чернышевский) урамындагы Гутман кибетенә Иван Спиридоновка китереп тә җиткергәннәр.

«Исәнмесез, кадерле дустыбыз Иван Спиридонович һәм Евдокия Лаврентьевна һәм балаларыгыз Вера Поля. Сезне Раштуа бәйрәме белән котларга ашыгабыз. Аны шатлыкта, сәламәтлектә һәм чын муллыкта каршы алуыгызны телибез. Сезне йорт сатып алуыгыз белән дә котлыйбыз. Сезнең (бу урында укылмый) Фёдр».

Язган кешенең белем ягы икелелек кенә булган, ләкин шуннан соң да әле кешеләр дөрес язу мәсьәләсендә әллә ни алга китмәде, телефондагы смсларга яки Ютуб һәм Инстаграм ишеләрдәге хәбәрләргә күз салу да җитә. Техника барлыкка килү тормышны гадиләштерә. Хәтта шул ук телефон аппаратлары да бәйрәм хатлары, открыткалар санын кимәтә. Китап кибетенә барып открытка сайлау, аңа үзенчәлекле теләкләр уйлап утыру, орфографик сүзлек актару, хәрефләрне матурлап, сырлап-бөтереп язу ихтыяҗы бетә, номерны җыясың да котлау сүзләреңне яңгыратасы гына кала. Эпистоляр жанр инде әнә шул чорда ук үлемгә хөкем ителә, ә кесә телефоннары һәм интернет хат белән открыткаларны тәмам кабергә озатты.

1. 50нче елларга караган уенчыклар.

2. Кирилл Пономарёв коллекциясендәге Кыш бабайлар.

– Инкыйлабка кадәрге открыткаларның күбесендә алтын белән басып төшерелгән «Съ Рождествомъ Христовымъ» язуы бар. Дини сәбәпне күздә тотмыйча гына котлаган «Съ Новымъ годомъ» дигәннәре сирәгрәк, – дип сөйли говорит Кирилл Николаевич, Яңа ел коллекциясен уен карталары кебек таратып. – Шулай да ел алышынуны әллә ни зурлап билгеләп үтмәгәннәр. 31 декабрьдән 1 гыйнварга каршы төндә казанлылар, мамык мендәрләрен кабартып, тәмле йокыга талу ягын караган. Православ динендәгеләр 6 гыйнвардан 7 сенә каршы төндә Раштуаны гына шау-гөр килеп бәйрәм иткән. Чиркәүләрдә чыршы чатырлар корып, аның эчендә кардан вертеплар (Раштуаны сурәтләгән курчаклы мәгарә) ясаганнар. Кайчак елга бозыннан зур тәре кисеп алганнар. Раштуа атнасы хәйрия кичәләре белән тәмамланган, аларда лотереяләр уйнатылып, мохтаҗларга шактый зур ярдәм күрсәтелгән.

Халык чыршысын Черек күлгә куя торган булганнар. Ул вакытта Россия империясенең башка губерния башкалаларындагы шәһәр чыршысыннан биегрәк, шәбрәк булсын дип тырышмаганнар да. Төп максат – ярлы-ябагай өчен төрле уен-көлкеле, кызык-мызыклы бәйрәм оештыру. Анда шуар өчен таучыклар, таганнар, яулап алынырга тиешле боз кирмәннәре, шамакайлар, Петрушка һәм Городовойлы балаганнар, самавырлы чәй өстәлләре һәм бер тиенлек кайнар сумсалар булган – рәхәтләнеп бәйрәм ит! Чыршы төбендә гармун моңнары яңгыраган, һәм һәркем күңелле ял иткән. Сүз уңаеннан, халык күңел ачкан җирләрдә хәмер сату тыелган. Бары үлән һәм кипкән җиләк чәйләре генә. Бәйрәм үзе исерткән!

Совет чорында гражданнарга хәмер эчү культурасын бик кертергә тырыштылар. Һәр бәйрәм, Яңа ел кебек гаилә бәйрәме дә иҗтимагый чара дип саналган. Һәм аны сәяси яктан дөрес тостлар белән кафеда, аек парторг күзәтүе астында, бергәләп каршы алырга киңәш ителгән. Ләкин бу гадәт урнашып кала алмаган. Һәркемне үз өендәге бер ләгән винегрет һәм «Советское шампанское» шешәсе күбрәк кызыксындырган, ә ул шампан шәрабе исә акрынлап боздай салкын «Московская» белән алышынган. Ә инде телевизорда тәүге «Зәңгәр утлар» кабынып, Мөслим Магомаев, Лариса Мондрус, Аида Ведищева, Валерий Ободзинский, Майя Кристаллинская һәм Эдуард Хильләрне карау бәхете тәтегәч, кешеләр бер-берсен карда аунатып ял итеп керү өчен генә урамга чыккалаган, ә аннары тизрәк кире өстәл янына йөгергәннәр.

Халык өчен Яңа ел кызыл төскә манылмаган бердәнбер бәйрәм булган. Кышкы, тик шундый җылы бәйрәм!

3. Яңа ел пакеты. Якынча 1965 елгы.

4. 50нче елларга караган уенчыклар.

PRESSA.RU

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ӨЧЕН МАХСУС

ШЕФ-ПОВАР ГЕОРГИЙ ТАМРАЗОВТАН ШАШЛЫК ҺӘМ КАЛҖА

Автор:
Татьяна Вафина

«Татарстан» журналының «Редакция кухнясы» һәвәскәр-поварлары сафына тәүге тапкыр чын профессионал – «Туган авылым» рестораны шеф-повары Георгий Тамразов кушыла. Ул сарык итеннән классик кавказ шашлыгы һәм классик татар калҗасы әзерли. Бер-берсенә бөтенләй охшамаган ике халыкның бер-берсенә бөтенләй охшамаган ике ризыгы. Чөнки, оста фикеренчә, Яңа ел табынында шундый тәмле дуслык – халыклар дуслыгы, һичшиксез, булырга тиеш.

Фото: Ната Смирнова

– Дөньяда 500 дән артыграк шашлык рецепты бар. Әмма иң беренче һәм берданбер классик ысул – сарык итеннән әзерләнгән шашлык. Калганнары – сыер, тавык, дуңгыз ите һ.б. – соңрак кулланыла башлаган, бу шашлыкның вариацияләре һәм төрләре генә. Классика исә – сарыкның бөер өлеше, бөерләрен дә кушып әзерләү! – дип мактый Георгий Михайлович.

ИТ ЧАБУ БУЕНЧА МАСТЕР-КЛАСС

Хәзер иң мөһиме – бәрәнне дөрес итеп бүлү. Һәм шеф-повар, унбиш кило чамасындагы бәрән түшкәсен өстәлгә ташлап, «Татарстан» фотокамераларыннан бер дә тартынып тормыйча, безгә бушлай мастер-класс күрсәтә – һөнәрмәндләр телендә бу процесс «ит чабу» (обвалка) дип йөртелә.

– Билгеле, сезнең беренче тапкырдан ук болай килеп чыкмас, – ди Георгий Михайлович, балтаны «Татарстанның» түземсез кулларына бирергә ашыкмыйча. – Тәҗрибә кирәк. Мин моның белән уналты яшемнән шөгыльләнә башладым. Үзем ит чабучы булып эшләгән колбаса ясау цехына иртәнге сәгать дүрттән килә идем. Тимер көбә перчаткадан куллар ярылып бетте. Кулым авырта, бәлки, больничныйга чыгаргадыр, дип мастер янына килгән идем, ул миңа үсемлек мае бирде һәм кулыма сөртергә кушты. «Йә, басылдымы авыртуы? – ди. – Бар, эшлә хәзер!» Бөтен сөйләшү менә шул булды. Китсәм, эш урынымнан колак кага идем. Шулай әкренләп эшли-эшли өйрәндем барысына да. Чаптым, кистем, турадым, ялгыштым, әмма итне ничек тә матуррак итеп чабарга тырыштым.

ТАРИХ АША ТЕЛӘСӘ КАЙСЫ РИЗЫКНЫ АҢЛАП БУЛА

– Ит чабу да шеф-повар эшеме?

– Юк, моның белән ит чабучы шөгыльләнә. Әнә, күрәсезме, ул миңа ничек карап тора – аның өлешенә керәм бит... Әмма чын шеф-повар барысын да эшли белергә тиеш! Итне дә бүлсен ул, теләсә нинди ризыкны да пешерсен, төрле милли ашларның тарихын да белсен. Менә мин Татарстанда инде 15 ел яшим, һәм килеп төшүгә үк татар ашлары белән кызыксына башладым. Нәрсә бу? Нәрсәгә охшаган? Менә рус токмачы бар, татар токмачы бар. Алар ничек аерыла? Хәтта кисү рәвеше белән дә аерылалар! Боларның охшаш ризык булуы мөһим түгел, кемнеңдер аны баш-

PRESSA.RU



КЛАССИК ТАТАР КАЛҖАСЫ:
- ит – 2 кисәк филе;
- аджика – банканың өчтән бере;
- сарымсак – 3 бүлем;
- тәменчә тоз, борыч.

КЛАССИК ШАШЛЫК:
- сарык ите – сум ит, түш ите (корейка), бөерләр;
- тәменчә тоз, борыч;
- 4–5 баш суган.

Безгә кирәк булачак:

кача әзерләве һәм бөтенләй башка төрле ризык килеп чыгуы мөһим. Мин үзем Кисловодскидан, Төньяк Кавказдан, Кавказ кухнясы тарихын да беләм. Минә хәзер сыргa игътибар артты. Барысына да итальяннарның пармезаны ошый – сигез гасырлык тарихы, рецептурасы, традицияләре бар, имеш… Ә минә сыр кайнатуның үзәк Кавказдан башлануын бик аз кеше белә. Кавказ кайчандыр Персия составында булган, аннары Урартуга кергән… Барысы да шуннан килә. Татарлар исә катыкны һәм кортны уйлап тапкан. Бу ризыкларны әзерләү тарихы күчмә кабиләләргә барып тоташа – ул чакта суыткыч булмаган, баз гына булган, аны исә күчереп йөртеп булмый… Тарих – чын шеф-повар өчен иң мөһим нәрсә. Хәер, ашчы өчен генә түгел, дөрес һәм тәмле пешерергә өйрәнергә теләгән һәркем өчен дә кирәк бу. Тарих аша теләсә кайсы ризыкны аңлап була.

Әйе, рим легиончылары скифлар белән сугышканда, сыр аларга «барып җиткән». Һәм алар аны камилләштергән, үз сортларын чыгарган. Бездә исә һәр кабардалы сыр кайнату технологиясен дә, сырдан толымнар да үрә белә. Чөнки кабарда халкы – Төньяк Кавказ территориясендә сармат һәм скифлардан соң яшәгән унике милләтнең берсе.

БЕЗ ҮЗЕБЕЗ АШАТКАН КЕШЕЛӘР ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ

– Әле безгә беркемнең дә кулинария тарихы буенча лекция укыганы юк иде. Сез, мөгаен, кулинария училищеларында укучыларга тарих укытасыздыр?

– Профессионаллар тарихка мөрәҗәгать итәргә тиеш. Чөнки безнең проблемаларыбыз бар. Мин һөнәри училище укучыларыннан имтихан алам. Тырышлыклары җитмәүче, материалны үзләштерә алмаучы балалар күп. Без үзебез ашаткан кешеләр өчен җаваплы булудан туктадык. Бу кайдадыр еракта калды. Совет чорын искә төшерәм, мин дә, күбебез кебек, шул чор баласы бит. Ул вакытта контроль һәм хисап бар иде. Ә 1990 еллардан анархия башланды, һәм әле шуннан бирле һаман җайга килә алмыйбыз. Безнең бик яхшы белгечләребез бар иде. Җитештерүдә эшләүчеләр. Алар эшнең сыйфатлы булуын һәм бөтен кагыйдәләрне үтәүне таләп итте. Хәзер бу бөтенләй юкка чыкты диярлек.

– Вазгыятьне ничек үзгәртергә соң?

– Безнең бөтен эшкуарларга белгечләр кирәк. Әмма бер генә эшкуар да җитештерүдә эшләүчене укытуга бер генә тиен акчасын да тотмый. Минә шулай үзгәртергә кирәк – белгечләрне укытуга акча бирергә. Мин эксперт булган «Ворлдскилс» ярышлары – бик шәп уйланган нәрсә. Әмма бу чемпионатны камиллеккә җиткерү зарур. Ярышта катнашучы балалар без – экспертлардан курыкмасын иде. Аларга аңлатырга кирәк – кунаклар өчен тәмле һәм матур ризык әзерлибез, дип күз алларына китерсеннәр дә, курыкмыйча, каушамыйча эшкә керешсеннәр. Алар үзләре ашатырга тиешле кешеләр өчен җаваплылык тоярга тиеш. Алар исә барысы да нервлана, курка, ничек тә йөзгә кызыллык китермәскә иде, дип борчыла. Бу да дөрес, әмма мөһим түгел.

КУЛЛАРЫБЫЗ АЛТЫН БУЛСЫН…

Мин безнең Казан сервис колледжындагы кебек ихластан булышучы һәм борчылучыларга рәхмәтлемен, анда безнең егет-кызлар чын практика үтә, чын ярдәм ала. Бу аларга гомерләре буена кирәк булачак, чөнки шул һөнәрләре белән алар гаиләләрен асраячак. Нәрсәдер хәтердә, геннарда, тәҗрибәдә калырга тиеш бит. Минә без үзебездән соң бу тормышта нәрсә калдырачакбыз? Интернетмы? Гаджетлармы? Ватсапмы? Ихтимал, мин хәзер сукрануга күчкәнмендер, әмма без яшь чакта егетләрнең авызына чәчәк кабып өченче каттагы кызлары янына менүе гайре табигый хәлгә саналмый иде, хәзер исә телефоннан сурәт җибәрәләр дә – шуның белән вәссәлам! Янәсе, ул инде герой, кызы белән очрашуга да бара ала! Күңелсез бит бу, әфәнделәр!

Әйе, яңа технологияләр кирәк, әмма безнең кулларыбыз – алтынның үзе. Без бөтен нәрсәне кул белән ясарга тырышырга тиеш. Дәнәләп. Һәр шәхескә аерым атап. Яратып!

«Ворлдскилс»та мин җирле, төбәк дәрәҗәсендәге эксперт. Миңа Европа мөһим түгел. Миңа җирле белгечләрнең булуы мөһим. Безнең илебез зур, ашатырга кеше җитәрлек, нәрсәгә безгә ул Европа, йә?! Үз акылың белән яшәргә кирәк. Әйе, башка халыкларның милли ашларын да, кулинария тарихын да белү зыян итмәс. Әмма үзебезнекен, Россиянекен, беренче чиратта белү зарур.

– Ул тәмлерәк булгангамы, әллә сез ватанпәрвәр булгангамы?

– Ул бай һәм төрлерәк. Һәм, әлбәттә инде, тәмлерәк. Безнең Россиядә күпме милләт яши? Һәм һәркайсының үз кухнясы данлыклы. Безнең кухняга әллә кемнәр әллә нинди өстәмәләр керткән. Хәтта французлар да. Ә бит французлар, үз милли ашларын булдыру өчен, башта бик күп сәяхәт иткән. Грузия буйлап та, Әрмәнстан буйлап та, Россия буйлап та. Уналтынчы гасырга кадәр Европа нәрсә ул? Кайсыгыз әйтә миңа? – Георгий «Татарстаннан» да имтихан алырга булды, ахры. «Татарстан»лылар, маңгаен җыерa-җыерa, ул чакта Европада юынырга яратмауларын исенә төшерде…

– Менә шул шул! Хәтта юынмаганнар да! – дип мактап алды безне шеф-повар. – Ашарларына да булмаган, бака ашаганнар. Әмма алар – патриот, аптырап калмаганнар – үзләренең бака ботларын Мишлен дәрәҗәсенә күтәргәннәр. Ә безнең

табында бака ботыннан кала бөтен нәрсә дә бар. Йөгез, искә төшерегез әле: кызыл уылдык, кара уылдык, тагын нindие калды?

– Баклажанныкы! – дип үзенең кулинария-кинематография буенча белемен күрсәтергә ашыга «Татарстан».

– Нәкъ шулай. Бу бит элек-электән килә! Хәзер исә күп кенә яшь поварлар мәрсин балыгының нәрсә икәнен дә белми. Әнә, аквариумда мәрсин йөзә, дип уйлыйлар – ә бу чөгә, мәрсин балыкларының бер төре генә. Әле тагын сәврүк, калуга, кырпы бар. Иң тәмле һәм файдалы кара уылдык – кырпыныкы. Бөртекле. Ни өчен уылдык бөртекле? Белмисез. Чөнки селтә өстиләр. Мин исә моның ничек ясалганын беләм, үзем өйрәндем. Чөнки миңа кызык иде. Белем эстәп, Дагыстанга, Каспийга кадәр барып җиттем.

МӨҺЕРЛӘРЕ ДӘ, БӨЕРЛӘРЕ ДӘ – АЕРЫМ

Шеф-повар тарихка экскурсия ясаган арада куллары бер генә минут та тик тормады, һәм менә инде безнең бәрән түшкәсе төрле зурлыктагы ит кисәкләренә һәм ит өемнәренә әйләнде.

– Хәзер сезгә сарыкның кайсы өлешеннән нинди ризык әзерләргә кирәклеген күрсәтәм. Башта без бәрәнне юдык һәм кәгазь тастымал белән корыттык. Менә бу мөһерләрне кисеп алырга кирәк, күрәсезме – безнең иткә келәймә сугылган. Әлеге мөһерләрне бәрән ите тулысынча пешеп беткәнче саклау зарур. Тикшерүче органнар килә калса, бу итнең безгә каян китерелгәнен күрсәтерлек булсын. Бу ит Дагыстаннан китерелгән. Карап торышка яңа суелган, бик йомшакка охшаган. Калак сөяге янындагы иттән пылау пешерергә яхшы. Бөерләре шашлыкка китә. Элпәсен аерып алабыз. Билдәмәсе – шашлыкка. Сөяктәге ит – фаршка. Түш ите аерым. Эч майлары люля-кәбабка бик тәмле. Корсак асты кала, аны сөягеннән төшерәбез… Менә бу кисәкләрне кыеклап кисәбез – болары да шашлыкка. Матур бит! Бәрән аягын сарымсак һәм чабыр белән маринадларга, атланмай сибеп, фольгага төрергә һәм бер өч сәгать пешерергә кирәк. Бик тәмле! Аңардан шашлык та ясап була. Сөякләре исә – шулпа пешерергә, аннары, кимереп, эткә бирергә.

Мин бервакыт бер маҗар кешесе белән эшләгән идем. Ул – итче-технолог. Менә ул әйтә иде миңа: «Бу каты өлешләрен миңа калдыр! Мин алардан аш пешерәм. Сөяксез ит – кунаклар өчен, әмма сөяк салып пешерген аштан да тәмлерәк нәрсә юк». Чөнки итнең сөяк янындагы иң каты өлеше – аның иң начар өлеше дигән сүз түгел. Ул шулпага бик тәмле, ашказаны тышчасын урап ала һәм аңа файда китерә. Мин сөякле итне яратам.

ИТ ЯРАТУЧЫ ИТЧЕ

– Атаклы бәрән иярен дә күрәсе килгән иде…

– Бәрән ияре – ресторанда иң күп кулланыла торган әйбер. Аны түш итенә һәм муен арты өлешенә бүләбез. Иң матур җиргә – түш итенә күчәбез. Кыеклап кискәч, бик матур килеп чыга! Хәзер, Яңа Зеландия корейкасын алганда, нигә аны 1000 сумга сатып алырга тиешлеге уйландырыр. Аларның сөякләре Европадагыча чистартылганга гына. Менә сезгә европача чистарту! Бераз эчпошыргыч эш, тик бу итнең бәясенә дә, үзкыйммәтенә дә, тулаем җәмәгать туклануына да йогынты ясый. Әмма белгән кеше барысын да үзе эшли ала!

– Ә сез үзегез нинди ит яратасыз?

– Теләсә нindине. Мин ит яратучы итче. Итсез ике көн дә тора алмыйм.

– Ә итсез яши алучы вегетарианнарга мөнәсәбәтегез нинди?

– Бу аларның яшәү мәгънәсе, алар тормышы. Үлән ашап та үзләрен яхшы хис итәләр икән, бигайбә.

– Ә нинди кухняны бөтенләй яратмыйсыз?

– Молекуляр кухняны. Тоташ химия бит ул!

– Укучыларыбызга Яңа ел табынына нәрсә әзерләргә киңәш итәсез?

– Ит, әлбәттә. Эт елы җитә бит. Эт исә ит ярата. Мин үзем, башка поварлар кебек үк, Яңа ел төнендә эшлим. Минем өчен яңа ел 13 еннән 14 нче гыйнварга каршы төннән башлана.

– Өегездә гадирәк ризык әзерлисезме? Әллә бөтенләй пешермисезме?

– Минем өчен бөтен нәрсә бик гади. Теләгем булса – пешерәм. Бөтен гаиләбез белән бергә пилмән ясыйбыз. Улыма алты яшь – тырыша инде, ул да ясый белә.

Бәләкәй поварның уңышларына сөенеп алгач, кабат ит чабуга кайтабыз.

ЮГАРЫ ГАСТРОНОМИЯ

– Хәзер мин сезне бәрән кабыргасы ясарга өйрәтәм, – Георгий балтасы белән кулындагы сөякне кирәкле үлчәмгә кадәр кыскарта. Аннары чистарта. Бәрән кабыргасы әзер!

– Иң мөһиме үлчәм! – повар тагын берничә кабырганы «кыскарта». – Менә сөякне Европадагыча кыскарту һәм Россиядәге кебек кыскарту. Бу аның табынга ничек бирелүеннән дә тора. Бу – югары гастрономия. Сезнең өчен югары гастрономия нәрсә ул? – «Ворлдскилс» эксперты Георгий Тармазов кабат имтихан сорауларына күчә.

– Ризыкның тәмле булуы! – дип хор белән җавап бирә «Татарстан».

– Юк шул! Югары гастрономия ул – безгә кергән чималның үзебездә үк тулысынча эшкәртелеп бетүе. Аңлашыламы?

Минем һәр ашамлыгым аерым суыткычта саклана. Барысы да аерым. Бер ашамлык икенчесенә тияргә тиеш түгел! Сөт аерым. Яшелчәләр аерым. Итнең һәр төре аерым: сыер ите, бәрән ите, тавык ите…

– Мишлен йолдызы гына җитми сезгә, дип тел шартлатабыз…

ПОЛЬ БОКЮЗ ҺӘМ ЮНЫС ӘХМӘТҖАНОВ

– Алар артыннан кумыйм. Европалылардан безгә кирәкмәгән нәрсәләрне нигә алырга? Безгә үзебезнең тамырларыбызга кайту зарур. Бик тәмле пешерергә кирәк! Юныс Әхмәтҗанов, татар рецептларын бергә туплаганда, дан артыннан кумаган бит, ул онытылганнарны кире хәтердә яңарткан. Һәм үзеннән соң нинди шәп мирас калдырган! Үз халкы өчен тулы бер тарих калдырган дияр идем. Миндә Юныс Әхмәтҗанов французларда Поль Бокюз соклану уяткан кебек ихтирам хисләре уята. Алар анда Поль Бокюзны йолдызларга кадәр күтәрделәр. Ни өчен? Ул үзенең туган француз авылы кухнясын дөнья масштабына чыгарганга күрә. Хәзер татар ашлары белән дә шул хәл күзәтелә. Рецептлар җыеп, Татарстан халыклары милли рецептлары тупланган кулинария китаплары чыгарган Юныс Әхмәтҗанов татар милли кухнясын да француз кухнясы белән

PRESSA.RU

Калҗа

1. Юкартабыз!

2. Тозлый-борычлыйбыз!

3. Уабыз!

4. Ышкыйбыз!

5. Төрәбез!

6. Урнаштырабыз!

7. Пешерәбез!

8. Алабыз!

9. Кыздырабыз!

10. Кисәбез!

бер дәрәҗәгә күтәргән. Бу – безнең аш-су тарихын булдырган кеше. Без гасырдан гасырга атлаячакбыз – 21, 22, 23 һ.б., әмма без беркайчан да тамырларыбызның кайда булуын онытмаска тиеш.

ШЕФ-ПОВАР НИ ӨЧЕН САВЫТ ЮМЫЙ

– Минә сез көннәр буе ашарга әзерлисез. Кайбер ризыкларны шактый озак әзерләргә кирәк. Ә аннары кеше килә дә, биш минутта ашап та бетерә. Тагын әзерләргә кирәк. Моңа гарьләнмисезме?

– Бу соңыннан савыт-саба юучыларның гына кәефен кырырга мөмкин. Әгәр менә ашап бетермиләр икән – шул очракта гарьләндерә, димәк, тәмсез пешергәнмен. Мин үзем әзерләгән бөтен ризыкны ашап бетергәннәрен яратам. Бу – аш остасы өчен иң зур бүләк.

– Ресторанда шеф-поварны чакырып рәхмәт әйтүчеләр бармы?

– Булгалый. Әмма мин бу традицияне башкачарак дәрәҗәгә күтәрергә кирәк, дип саныйм. Поварларга рәхмәт әйтсеннәр, нәкъ менә шул ашчы әзерләгән ризыктан авыз итәр өчен, әллә кайлардан килсеннәр. Ресторан ул – бөтен кухня эше механизмы. Моңа мин үзебездә, Кисловодскида өйрәндем. Ул бит кечкенә шәһәр. Бер тапкыр тәмсез ашатсаң, икенче тапкыр килмәячәкләр. Туристларга исә ышаныч юк, алар җәен генә күп. Әгәр ел буена яхшы яшисең килә икән, теләсәң-теләмәсәң дә яхшы әзерләргә кирәк. Бу кечкенә курорт шәһәрләренең игелекле сыйфаты. Мине шул тәрбияләде дә инде.

– Башка рестораннарда ошамаган нәрсәләр булгалыймы?

– Билгеле, була инде. Дәшмим. Мин бит үзем повар, минем белән дә шундый ук хәл килеп чыгарга мөмкин. Тик инде авызга кабып булмаслык ризык әзерләгән шәкертемне күрсәм – барысын да ачыктан-ачык әйтеп бирәм. Чөнки үз укучыңнан шундый тәмсез ризык алу – зур хурлык ул.

– Остаз буларак, сез ничә шәкерт тәрбияләдегез?

– Мин аларны санамыйм. Кеше булган икән – бик яхшы! Юк икән – үзенең проблемалары. Мин барысын да бер төрле өйрәтәм бит.

– Шеф-повар буларак сезгә генә хас нинди ризык әзерлисез?

– Бераз башкачарак градация кертмәкче булам: «шеф-повар фәлән вакыттан алып фәлән вакытка кадәр әзерли». Һәм менә шушы вакыт эчендә мин нинди тәгам әзерлим, шул шеф-повардан фирма ризыгы була да инде!

Шашлык

1. Бүләбез!

2. Аралыйбыз!

3. Турыйбыз!

4. Тозлый-борычлыйбыз!

5. Сыгабыз!

6. Аралаштырабыз!

7. Тезәбез!

8. Кыздырабыз!

9. Өстәлгә чыгарабыз!

– Шеф-поварга ит тә чаба белергә, тарихны да яратырга кирәклекне без инде аңладык…

– Һәм әле бер урында казынырга да кирәк – шундый әйтем бар. Мин инде 26 ел буе аш-су өлкәсендә эшлим. Югары белемем бар. Туризм буенча академия тәмамладым. Кисловодскида башладым, анда туристларны озатып йөрдем, алар өчен шашлык кыздырдым. Мине гомерем буена кухня озата килә. Бик шәп вакыт иде ул чаклар да.

– Ничек итеп кояшлы Кисловодскины кояшы күпкә азрак елмайган Казанга алмаштырдыгыз?

– Мин үз ватанымны яратам, әмма тукталып торырга ярамый, гел алга барырга кирәк. Казанга мин бик рәхмәтле, биредә мин шунда ук бик кырыс шартларга эләктем һәм алар аркасында кеше була алдым. Казан миңа күпне бирде, мин дә Казанга күпне бирдем. Мәсәлән, 2013 елда аңа дөньяда иң озын хәләл шашлык буенча Гиннессның рекордлар китабына керергә булыштым. Мин шул итне маринадладым һәм кыздырдым. Бу Казан ит комбинатында булды. Үзем 220 килограмм итне турадым һәм маринадладым. Өч көн тырыштык. Бөтен шартларны үтәдек. Бик тәмле булып чыкты. Бу Ислам академиясе инициативасы иде. Мин мөселман түгел, православ динендәмен, әмма безгә бит дошманлашырга кирәкми. Без бергә эшли, бергә акча таба, бергә кешеләр ашата алабыз. Бу сугышка караганда күпкә яхшырак лабаса. Әлбәттә, әлеге проектта катнашу – дөнья масштабында би-и-к кечкенә бер тамчы гына. Әмма ул миңа рәхәтлек бирде.

Мин яртылаш әрмән. Әнием рус милләтеннән. Безнең өйдә ике халыкның да ризыклары әзерләнә иде. Шунлыктан мин төрле кухняларны берләштерә алам. Һәм яңа ризыклар уйлап табам. Менә, мәсәлән, чүлмәктә яшелчәләр белән томалап пешерелгән ит. Грузинча чалнахи. Башка исем кушасың да, инде өр-яңа татар ризыгы килеп чыга. Теләсә кайсы грузин ризыгын татар ашына әйләндереп була. Һәм киресенчә.

КЛАССИК ТАТАР КАЛҖАСЫ

Итне сортларга аерып, Георгий ике кисәк филе өлешен сайлап ала:

– Хәзер исә классик татар калҗасын ясыйбыз. Бу – катлама, кабымлык. Бик тиз әзерләячәкбез. Итне такта өстенә җәеп салып, суккалап юкартабыз. Аджика сылыйбыз – кул белән генә, ингредиентларның күпме кирәген мин кулым белән һәм исе буенча чамалыйм. Йомшаграк булсын өчен, әзрәк май сибәбез. Әнә, исе нинди тәмле, сизәсезме? Рулет итеп төрәбез. Башта пленкага төреп форма бирәбез, бәйлибез, аннары фольгага төреп, 180 градуслы газ мичендә 1,5 сәгать пешерәбез.

Үзебез исә классик шашлык кыздырырга барабыз. Итне 12 сәгать маринадта тотарга кирәк, мин исә 12 минутта да маринадлый алам.

– Без шикләнмибез дә!

КЛАССИК ШАШЛЫК

– Ит кисәкләрен менә шулай таратып салып, тоз, борыч сибәбез, – дип сөйли шеф-повар. – Аннан соң кулны юу мәҗбүри! Тизрәк әзерләнсен өчен, бу юлы суганны гадәттәгедән бераз күбрәк алабыз. Ярымбоҗралап түгел, саламлап турыйбыз. Нечкә итеп.

Суган турау процессы шулкадәр сихерле, без аны шунда ук Инстаграмга да куябыз.

– Хәзер суганны ит өстенә сыгабыз… Яхшылап болгатабыз. Исен сизәсезме? Маринадланган арада, күмер әзерлибез. Итне кыздыра башлаганчы, күмер өстендәге ак куныкны алырга кирәк, югыйсә ул шашлыкка куна. Күмер кызыл булырга тиеш. Бөерләр иттән йомшаграк, тарал-масын өчен, аларны шампурның уртасына куябыз. 15 минутлап кыздырабыз. Сизәсезме, тәмле ис чыга башлады! Тәмле ис чыга икән, димәк, маринад яхшы дигән сүз.

ТАРИХ СОУСЫ АСТЫНДА

Шашлык әзер. Калҗа пешеп чыгарга тора.

Георгий Тармазов табын кора: шашлык янына грильдә пешкән яшелчәләр һәм яшел тәмләткеч үләннәр куя, калҗаны черри помидорлары һәм укроп белән бизи.

«Татарстан» тарихына бу ризыклар иң профессиональ булып кереп калачак – ватанпәрвәрлек белән тәмләтелгән тарих соусы сибеп бирде аны Георгий Тармазов безгә.

2018 ел символы булган Сары Этнең күңелен күрер өчен, «Туган авылым» рестораны шеф-повары бу ризыкларны Яңа ел табынына, һичшиксез, әзерләргә киңәш итә.

КАЗАН ХАНЛЫГЫ: ТӘХЕТ ӨЧЕН КӨРӘШ

Казан ханлыгы тарихын тулырак күзаллау өчен, әлбәттә, аның ханнары алып барырга мәҗбүр булган тышкы сәясәткә дә тукталып үтәргә кирәк. Белгәнебезчә, Казан тәхетендә җучиләр нәселеннән чыккан идарәчеләр утырган. Табигый ки, Казан ханнары Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән дәүләтләр белән тыгыз мөнәсәбәттә торганнар. Әмма бу чорда күрше Мәскәү дәүләте дә, ныгып-көчәеп, күрше халыкларны басып алып, чикләрен әкренләп көнчыгыш тарафка, Урта Иделгә таба киңәйтү сәясәтен тормышка ашыра башлый. Казан ханнары дәүләтнең тышкы сәясәтен корганда шул ике якның көчле басымы астында калалар.

Автор:
Фаяз Хуҗин

1445 елның июлендә Олуг Мөхәммәднең уллары Мәхмүд белән Якуб Суздаль янындагы сугышта рус гаскәрләрен тар-мар итеп, бөек кенәз Василий II не әсирлеккә алалар. Үзен азат итү бәрабәренә Василий II зур күләмдә йолым бирергә һәм ел саен ясак түләргә мәҗбүр ителгән. Әсирлектән азат итүнең тагын бер шарты – заманында Туктамышның Василий I гә сатып җибәргән «мещера җирләрен» ханга кире кайтару булган. Нәтиҗәдә ул җирләрдә Касыйм ханлыгы төзелгән. Олуг Мөхәммәднең улы Касыйм үзенә мирас биләмәсе итеп бирелгән «городец Мещерский» өчен (тиздән ул Касыйм исеме астында танылачак) рус дәүләтенең көнчыгыш чикләрен сакларга, Мәскәү кенәзләре алып барган сугышларда катнашырга тиеш була. Суздаль янындагы сугыштан соң үткән егерме ел дәвамында, *Мәхмүд хан* идарә иткән чорда (1445–1464 еллар), Казан ханлыгы тыныч шартларда үсә һәм ныгый.

МӘСКӘҮ КАЗАНГА КУЛ СУЗА

Вазгыять Мәхмүд хан үлгәч үзгәрә. Аның тәхеткә утыртылган улы *Хәлил* озак идарә итә алмый, 1467 елда ул гүр иясе була. Казанлылар тәхеткә Мәхмүднең икенче улын – Ибраһимны тәкъдим итәләр, Мәскәү исә хан урынында үзенә бәйле кешене – Касыймны күрергә тели. Тәхеткә *Ибраһим* утыртыла, әмма Мәскәү үз ниятеннән ваз кичми. Иван III Казанга Касыйм җитәкчелегендә зур гаскәр җибәрә. Яу уңышсыз тәмамлана. Шуннан соң, 1469 елда, Казанга Иван III үзе яу белән килә. Рус әсирләрен кире кайтару һәм бер-берләренең эчке эшләренә тыкшынмау шарты белән солых төзелә. Чагыштырмача тынычлык тугыз ел дәвам итә.

1478 елның язында рус хөкүмәте Нократ (Вятка) җирләре өчен Казанга яңа һөҗүм оештыра, әмма башкалага килеп җитә алмый. Шул ук елны (кайбер чыганакларда – 1479 елда) Ибраһим хан үлә. Иван III кә Казан эшләренә актив тыкшыну өчен яңа мөмкинлекләр ачыла. Ибраһим ханның ике улы – Илһам һәм Мөхәммәд Әмин – тәхет өчен көндәшләргә әвереләләр. Казанның Мәскәү яклы төркеме тәхеткә Мөхәммәд Әминне куярга тели. Нугай һәм Кырым белән якынлашырга омтылучы икенче төркем исә *Илһам* кандидатурасын алга сөрә. Җиңүгә алар ирешә. Ун яшьлек Мөхәммәд Әминне Мәскәүнең бөек кенәзе үз янына тәрбиягә ала һәм аны киләчәктә Казан тәхетенә утыртырга теләвен яшерми.

Бу теләген Иван III 1485 елда ук тормышка ашырырга омтыла. Мәскәү гаскәрләренә таянып, Мөхәммәд Әмин Илһам ханны Казаннан куа. Ләкин Илһам нугай гаскәрләре ярдәмендә тиздән тәхетне кире кайтара. Иван III моның белән һич тә риза булмый һәм 1487 елда Казанга зур яу оештыра. 18 майда руслар шәһәрне камап ала. Дошман ягына кételмәгән һөҗүмнәр оештырып, казанлылар батырларча каршы тора. Бер ай камалышта торганнан соң, каршылык сындырыла. 9 июльдә шәһәр капкалары ачыла, һәм рус гаскәрләре башкалага керә. Тәхеттән куылган Илһамны гаиләсе белән бергә Вологдага озаталар, һәм ул шунда тоткынлыкта үлә. Тәхеткә *Мөхәммәд Әмин* утыртыла.

«МӘҢГЕЛЕК ДУСЛЫК ҺӘМ ТЫНЫЧЛЫК» КАКШАГАЧ (1487–1521 ЕЛЛАР)

1487 елдан башланган протекторат Казан ханнарының Мәскәү кенәзләренә тулы бәйлелеген аңлатмый, әлбәттә. Әйе, Иван III «Болгар кенәзе» титулын кабул итә. Казан үз күршеләре – нугайларга, Әстерхан һәм Кырымга карата Мәскәү сәясәтен үткәрергә тиеш була, кирәк чакта аларга каршы Мәскәү ягыннан торып сугышырга мәҗбүр ителә. Мәскәү ризалыгыннан башка казанлыларның

Иллюстрацияләр: Фиринат Халиков китабыннан.

«Казанны саклаучыларга багышлана. Мәрсия», 2001 ел.

үз ханнарын сайлап кую хокукы да булмый.

Аңлашыла ки, Иван III куйган хан халык тарафыннан хуплау тапмый. Мөхәммәд Әминнең Мәскәүгә ярашлы сәясәте, гади халык түләп барган салымнарның артуы, яңа йөкләмәләр өстәлүе күпләрдә, шул исәптән югары катлау вәкилләрендә дә канәгатьсезлек тудыра. Фетнә оеша, анда катнашучылар, ярдәм сорап, Себер ханы Мамукка мөрәҗәгать итәләр. Мөхәммәд Әмин башакаладан кача, ә *Мамук* 1496 елның ноябрендә үзенең гаскәрләре белән тыныч кына Казанга керә.

Яңа хан элеккесеннән дә яманрак була. Дәүләт белән юньләп идарә итә белми, борынгы кучмәннәр гадәте буенча күршедәге Арча каласына талау явы оештырырга да тарсынмый хәтта. Аның бу кыргыйлыгын гафу итмиләр – Мамук кире Себергә кайтып китәргә мәҗбүр була.

Хөкүмәтне Мәскәү тарафдарларының берсе Колмөхәммәд (Коләхмәт) үз кулына ала. Ул Мәскәү белән мөнәсәбәтләрне торгызырга тырыша, «Болгар кенәзе» Иван III кә Казанга яңа хан куюны сорап мөрәҗәгать итә. Мөхәммәд Әмин кандидатурасыннан баш тартып, 1497 елда аның энесе *Габделлатыйфны* хан итеп куялар. Колмөхәммәд хөкүмәте баштарак яңа ханны яклый, ләкин ул, артык мөстәкыйльлек күрсәтеп, Мәскәүдән бәйсез сәясәт алып бара башлагач, канәгатьсезлек белдерә. Колмөхәммәд Мәскәүгә юнәлә һәм анда ханга каршы астыртын эш башлый. 1502 елның гыйнварында Казанга киң вәкаләтләре һәм Габделлатыйфка карата төгәл күрсәтмәләре булган рус илчеләре килә. Хан тәхеттән куыла һәм Белозерога сөргенгә озатыла. Тиздән аны, Кырым ханы Миңлегәрәйнең кискен ультиматумыннан соң, Мәскәүгә кайтаралар.

Тәхеткә яңадан элек үзен Мәскәү тарафдары итеп таныткан Мөхәммәд Әмин утыртыла. Тик бу юлы инде ул, Казаннан яңадан куылудан куркып, Мәскәү рөхсәтеннән башка гына, бөтенләй икенче сәясәт үткәрә башлый. Иң әүвәл Колмөхәммәд хөкүмәт составыннан чыгарыла һәм җәзалап үтерелә. Аннары Мәскәү Русе белән ике елга сузылган сугыш башланып китә. 1505 елның 22 июнендә, Казан ярминкәсе ачылган көндә, ниндидер сәбәпләр табып, рус сәүдәгәрләрен талыйлар, кайберләрен кыйнап үтерәләр. Тиздән Мөхәммәд Әмин нугай гаскәрләре белән бергә Түбән Новгородны камап ала, Ока елгасы буендагы авыллар талана. 1506 елның язында рус гаскәрләре җавап һөҗүме башлыйлар. Каты бәрелешләр Казан тирәсендә бара. Мөхәммәд Әмин сугышчылары та-

«Сөембикәнең хушлашуы», 2001 ел.

PRESSA.RU

«Мәскәү илчеләренең XVI йөз Казанына килүе», 2000 ел.

гын бер җиңүгә ирешә. 1507 елда Казан белән Мәскәү дипломатик сөйләшүләр башлап җибәрә, нәтиҗәдә ике дәүләт арасында «элеккечә тынычлык һәм дуслык мөнәсәбәтләре» торгызыла. Мәскәүдә кул куелган «мәңгелек тынычлык» турындагы шартнамә ун ел буена үз көчендә була, һәм бу вакыт эчендә Казан ханлыгы үзенең үсешендә зур уңышларга ирешә. Әмма Казан өстеннән Мәскәү протектораты дәвам итә әле.

1518 елда Мөхәммәд Әмин үлгәч, бәкләр бәге Булат Ширин Казан тәхетенә Касыйм ханы *Шаһгалине* чакыра. Мәскәүнең яңа бөек кенәзе Василий III не бу кандидатура бик тә канәгатьләндерә, Казан аксөякләре дә аңа каршы килми. Әмма Шаһгали алып барган сәясәт (салымнарның артуы, сәүдәгәрләрнең, карачибәкләрнең хокукларын чикләү, Мәскәүгә артык ярарга тырышу) тиздән күпләрдә ризасызлык тудыра. Заговор өлгереп килә. Аны оештыручылар Кырым ханыннан яклау эзлиләр. 1521 елда шәһәргә Кырым солтаны Сәхибгәрәй җитәкчелегендәге гаскәр керә. Шаһгали куыла. Мәскәү протектораты бетерелә.

КАЗАНДА – КЫРЫМ ХАННАРЫ

Сәхибгәрәйнең идарә итүе (1521–1524) Казанда рус сәүдәгәрләрен, гаскәриләрен һәм дә Касыйм татарларын талау, кыйнау, үтерү белән башланып китә. Моңа җавап итеп, Василий III казанлыларга каршы сугыш башлый. Гаскәрләр Түбән Новгородта туктала, ләкин Шаһгали Казанга барырга җөрьәт итми. Руслар оборонага күчәләр һәм Сура елгасы тамагында Васильсурск крепостена нигез салалар. Ул аларга киләчәктә Казан тарафына хәрәкәт итү өчен плацдарм хезмәтен үтиячәк.

Сәхибгәрәй Казанда хан вазыйфасын өч ел гына башкара, аннары Кырым тәхетенә утыру нияте белән туган ягына кайтып китә. Идарә дилбегәсен исә бертуганының улы 13 яшьлек *Сафагәрәйгә* тапшыра. Әлеге кандидатураны Булат Ширин җитәкчелегендәге карачибәкләр дә яклый.

Боларның барысы да мәскәүлеләрдән рөхсәт сорап тормыйча гына эшләнә. Василий III гаскәрләре Казанга юл ала. Казанлылыр дошманның шәһәрне штурм белән алырга тырышуларын уңышлы рәвештә кире кагалар. Василий III хөкүмәте Сафагәрәйне законлы хан дип танырга мәҗбүр була. Ләкин аңа тынычлап идарә итәргә мөмкинлек бирмиләр. Мәскәү астыртын рәвештә Сафагәрәйгә каршы төркем вәкилләре белән эш йөртә, аларны яңа ханга каршы баш күтәрүгә өнди. 1531 елда Сафагәрәй бәреп төшерелә, аның яклылар җәзалап үтерелә.

Мәскәү тарафдарлары хан тәхетенә Шаһгалинең энесен, 16 яшьлек *Җангалине* чакыралар. Ләкин ул декоратив фигура гына була. Хәтта нугай морзасының кызы Сөембикә белән никахын да Җангали Василий III һәм Казан карачибәкләренең ризалыгы белән генә укыта алган. Казанның эчке эшләренә тагын Мәскәү идарәчеләренең тыкшына башлавы халык арасында көчле ризасызлык тудыра. 1535 елда Җангали үтерелә.

Казанга яңадан Сафагәрәйне чакыралар. Ул, шул заманнарда кабул ителгән йола буенча, Җангалидән тол калган Сөембикәне хатынлыкка ала. Югары катлаулар басымы астында Мәскәүдән дә, Кырымнан да бәйсез сәясәт алып барырга тырыша. Әмма Мәскәү хөкүмәте Казанга булган дәгъваларыннан баш тартмый, элеккеге протекторат чорын кире кайтарырга ниятли. Сафагәрәй, табигый ки, Мәскәүгә һәм эчке дошманнарына каршы көрәштә Кырымга таянырга чамалый. Мәскәүнең турыдан-туры катнашы белән Сафагәрәйгә каршы фетнә әзерләнә. 1546 елда ул тәхеттән бәреп төшерелә. Сафагәрәй Сөембикәнең әтисе, нугай морзасы – Йосыф янына качып китә.

Фетнәдә катнашучы казанлылар яңа хан сорап Мәскәүгә мөрәҗәгать итәләр. Иван IV күпсанлы гаскәре белән Казанга Шаһгалине җибәрә. Гаскәрне шәһәргә кертмиләр, Шаһгали үзе дә тәхеттә бер ай чамасы гына утырып кала. Шул бер ай дәвамында Сафагәрәй нугайлар ярдәме белән шактый зур гаскәр җыя һәм, вакытны сузмыйча, Казанга юнәлә. Биредә аны көтеп алалар. Иван IV исә аңа сугыш игълан итә.

Сафагәрәй үзен чолгап алган дошманнарын – Мәскәү тарафдарларын җәзалый, мөһим дәүләт вазыйфаларына Кырым һәм Нугай бәкләрен билгели. Җәмгыятьтә таркалу башлана. Бу эштә, әлбәттә, Мәскәү хөкүмәте дә актив катнаша. Сафагәрәй үз сәясәте белән ялгыз кала. Дошманнары аннан котылу юлын эзли башлыйлар. Үз теләкләрен алар 1549 елның язында тормышка ашыралар.

КУЛДАН ДӘҮЛӘТ КИТКӘН КӨННӘРДӘ

Хан итеп Сафагәрәйнең ике яшьлек улы *Үтәмешгәрәй* игълан ителә. Аның исеменнән әнисе *Сөембикә* идарә итә. Ләкин чын хакимият кырымлылар кулында була.

Казан хакимнәренең мөстәкыйльлегеннән риза булмаган Иван IV хәлиткеч сугыш юлына баса. Казанга ике зур яу оештырып, алар белән үзе җитәкчелек итә. Һәр икесендә дә уңышсызлыкка очрый. Патша хөкүмәте Казанны яулап алырга җентекләп әзерләнә башлый. 1551 елның 24 маенда Зөя елгасы тамагында рус крепосте Свияжскига (Зөягә) нигез салына. Казанга илтүче су юллары киселә. Тау ягы халкын, башлыча мариларны һәм чувашларны, үзләренең вәкилләрен Мәскәүгә җибәреп, Россиягә тугрылыкка ант иттерәләр. Казанны язмыш кочагына калдырып, Кырым гарнизоны аны ташлап китә.

Мәскәү белән сөйләшүләр башлана. Килешү буенча тәхетне Шаһгали ала. Үтәмеш белән Сөембикәне Мәскәүгә озаталар. Корылтай җыела, дәүләтнең мөстәкыйльлеген саклап калырга өметләнеп, ханлыкның Тау ягындагы биләмәләрен Мәскәүгә бирергә ризалашалар. Ачулары чыккан казанлылар Шаһгалине Казаннан качарга мәҗбүр итәләр. Бу 1552 елның 9 марты була. Чапкын Отучев җитәкчелегендә вакытлы хөкүмәт оештырыла. Тәхеткә Әстерхан ханының улы *Ядегәр* чакырыла. Ул үзен оста оештыручы һәм авыр шартларда да югалып калмый торган батыр шәхес буларак таныта.

Иван IV хәлиткеч һөҗүмгә әзерләнә. 1552 елның июль башында русларның төп гаскәрләре Коломнадан чыгып китәләр һәм 2 августта, 60 мең сугышчыдан торган лагерь булып, Казан диварлары янына килеп урнашалар. 23 августта Казанны камау башлана. 2 октябрь иртәсендә рус гаскәрләре шәһәрне штурмлауга ыргылалар. Нәтиҗәсе һәркемгә мәгълүм: Казан ханлыгы яшәүдән туктый. Дәүләтчелеге һуннар чорыннан ук башланган Идел буе татарларының югары үскән цивилизациясе юкка чыга. Борынгы башкалабыз Казан бер көн эчендә рус шәһәренә әверелә.

Җиңелүнең сәбәпләре ачык: Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән дәүләтләрнең барысы да икътисадый яктан шактый ук көчсез булалар. Өстәвенә, әле идарә итүче катлаулар тәхет өчен үзара гел сугышып-талашып торалар, һәм бу вазгыятьтән аларның дошманы – Мәскәү дәүләте бик оста файдалана.

***

Безнең һун бабаларыбыз чорыннан ук башланып киткән озын һәм гыйбрәтле тарихыбыз бар. Россиядә яшәүче халыкларның бик азы гына: «Без – борынгыдан ук дәүләтле халык!» – дип горурлана ала. Дәүләтле, димәк, цивилизацияле, югары үскән мәдәниятка ия булган халык. Бу чыннан да шулай. Бик катлаулы заманда яшибез. Көн тәртибендә – милләтебезнең киләчәк язмышы. Югалып калмабызмы? Күпгасырлы мирасыбызны киләчәк буыннарга тапшыра алырбызмы? Моның өчен нәрсәләр эшләргә кирәк? Журналыбыз битләрендә әлеге рубрика кысаларында басылып килгән мәкаләләребез, бәлки, бу сорауларга җавап табуда ярдәм итәрләр, дигән өметтә калабыз.

«Казан чолганышта», 2009 ел.

PRESSA.RU

КЕШЕ КИТӘ, ҖЫРЫ КАЛА...

2017 елның соңгы сәгатьләре сугарга санаулы мизгелләр калып бара. Дөресен әйтик, югалтулар елы булды бу. Республика тарихы, милләт өчен дә эзсез генә узмады... Татарның йөзе, милләтебезнең горурлыгы булган, аның үткәне белән киләчәге арасында күпер сузган берничә бөек шәхесебезне дә югалттык. Арада аеруча көтелмәгән, үкенечле үлемнәр бар. 2017 елга йомгак ясаганда арабыздан киткән әлеге кадерле милләттәшләребезне барларга булдык. Мәрхүмнәрнең авыр туфраклары җиңел булсын. Алар турында язылган җылы сүзләр рухларын шат итсен.

ЛЕНА ШАГЫЙРЬҖАН (16 ГЫЙНВАР)

Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Лена Шагыйрьҗан (Лена Галимҗан кызы Шакирҗанова) турында курыкмыйча әйтеп була: үз заманының иң көчле шагыйрәләренең берсе. Фикерле, горур һәм бик талантлы!

Лена апа Актаныш районының Пучы авылында укытучы гаиләсендә туа. Ә балачагы һәм мәктәп еллары Әтнә районының Күлле Киме һәм Түбән Көек авылларында уза. Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлагач, бер ел мәктәптә эшли. Ләкин аның талантына мәктәп кысалары гына җитми...

Кечкенәдән шигырь язган кызның икенче зур сәләте дә була – моңлы тавыш. Шуңа да Лена апа, укытучылык эшен ташлап, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленә җырчы-артистка булып урнаша. Соңрак Татарстан дәүләт радиокомитетында тәрҗемәче-журналист булып эшли. Кыскасы, җыр сәнгате белән иҗатны бергә алып бара. Ә 1987 елдан Лена апа бары тик әдәби иҗат белән шөгыльләнә. Нәкъ шушы чорда иң көчле шигырьләре туа, танылган, күпләрнең яраткан шагыйрәсенә әйләнә.

Лена апаны белүчеләр минем белән килешер: холкы буенча гади кеше түгел иде. Бәлки аның туры сүзле, җил уңаена каршы барган акыл-фигылен күпләр аңлап, кабул итеп тә бетерә алмагандыр. Тик, ничек кенә булмасын, ул һәрвакыт үзе, кабатланмас Лена Шагыйрьҗан булып кала алды...

Танылган шагыйрәбез бер әңгәмәсендә болай дигән иде: «Кешеләрдә иң куралмаган сыйфат – хөсетлек, көнчелек һәм ялган. Аннары байлык артыннан куучыларны җенем сөйми. Барыбер кала бит ул. Надан бәндәләрне яратмыйм. Бигрәк тә үзен акыллы дип йөрсә. Акыл бер нәрсә, хәйләкәрлек – икенче... Үземнең төп сыйфатым – эчкерсезлек. Ләкин ул миңа кыйммәткә төшә. Әшәкелек, наданлык, алдашу һәм хәйләкәрлек мине ярсыта. Нәтиҗәдә, мин «холыксыз» булып күренә башлыйм. Ләкин мин зур эшләрдә бик түземле һәм сабыр кеше, Аллага шөкер».

Лена Шагыйрьҗанны Әтнә районының Күлле Киме зиратында җирләделәр. Аңа 71 яшь иде.

Автор:
Руфия Фазылова

ГАНС СӘЙФУЛЛИН (10 МАЙ)

Татарстанның халык артисты, күренекле композитор, баянчы. 1990 елдан башлап, «Татар яшьләре җыены» проекты белән бөтен республиканы шаулаткан, гомерен татар сәнгатенә багышлаган шәхес. Ул биш йөзләп җыр авторы, дүрт йөзләп инструменталь пьеса иҗат иткән музыкант. Күп җырчыларга заманында профессиональ сәхнәгә күтәрелергә ярдәм кулы сузган кеше.

Кешенең кемлеген белер өчен кайвакыт биш минут сөйләшеп тору, күзенә карау да җитә. Ганс абый эчкерсез, сәнгать дөньясын-

да рәхәтләнеп «йөзүче» шәхес иде. Аның турында: «Гади, бик ярдәмчел кеше иде», – диләр. Аеруча хатын-кызларга хөрмәт белән карады ул. Тормышны яратты, үзен бәхетле кеше дип санады. Егерме яшендә үк Баулы егете Казан филармониясенә баянчы-аккомпаниатор булып эшкә урнаша. Татарның бөек җырчылары – Фәридә Кудашева, Зифа Басыйрова, Илһам Шакиров, Усман Әлмиев, Таһир Якупов һәм башка бик күпләргә уйный. Тиз арада популярлык казана. Шул ук вакытта композиторлык эшенә дә ныклап алына. Аның «Туган авылым урамы», «Мин бит кара карлыгач», «Син икәнсең», «Акбүз атым», «Бәхет дагасы» кебек җырларын белмәгән, ишетмәгән кеше сирәк иде.

Ганс Сәйфуллин совет чорында ук чит илләргә гастрольләргә йөргән баянчы. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле белән Монголия, Тунис, Италия, Төркия, Австралия, Бельгия, Германия һәм башка илләрдә чыгыш ясау бәхете тәтегән музыкант.

Зур сәхнәдә тамашачы Ганс абыйны соңгы тапкыр филармониядә күрде. Татарстанның халык артисты ул чакта 75 яшьлек юбилеен билгеләп узды. Бер елдан соң, 4 инсульт кичергән шәхес, комадан чыкмыйча, хастаханәдә җан бирде.

Аны туган ягында – Баулы үзәк зиратында җирләделәр.

ИЛФАК ШИҺАПОВ
(30 МАЙ):

«Илфак Шиһапов вафат» дигән хәбәргә башта ышанмадык. Мөгаен, берәрсе уйлап чыгаргандыр. Танылган кешеләр үзләренә пиар ясар өчен шау-шу куптарырга ярата бит. Тик үлем белән шаярмыйлар шул...

Күпкырлы шәхес иде Илфак Шиһапов: журналист, язучы, публицист, продюсер, җырлар авторы. Аны «Татарстан яшьләре»ндә эшләп йөргән чагыннан ук хәтерлим. Минем өчен Илфак абый, иң беренче чиратта, туры сүзле чын, оста журналист. Ә аңардагы юмор хисе... Нәкъ менә шул үткен телле язмалары белән җәмгыятьтәге гаделсезлекләрне күпмедер дәрәҗәдә фаш итә алды. Ә кеше буларак ул чиста, олы йөрәкле, ачык күңелле зат иде...

Илфак Шиһаповны күпләр продюссер буларак белә. Илсөя Бәдретдиновага җырлар язып, әле халыкка таныш булмаган яшь туташтан йолдыз ясады. Илфак абый язган стильдәге җырлар аңарчы татар эстрадасында юк иде. Һичшиксез, ул татар сәхнәсенә яңалык алып килде. Һәм шуның белән тарихка кереп калды да.

Илфак абый газеталар да нәшер итте. Танылган журналистның бу өлкәдә тагын бик күп яңа идеяләре, планнары булгандыр. Ни кызганыч, алар тормышка ашмый калды...

Талантлы кешеләр үзенчәлекле була. Илфак абыйның күңелендә дә буран өермәсе кайнагандыр...

Без, журналистлар, туры сүзле, милләт җанлы каләмдәшебезне еш искә алабыз. «Эх, Илфак абый юк, ул булса, бу теманы шәп итеп язып чыгар», «үз сүзен әйтер иде», дибез. Татар журналистикасында ир-атлар күп түгел, ә Илфак абый кебекләр бармак белән генә санарлык. Бу безнең өчен дә, татар милләте өчен дә бик зур югалту...

Илфак Шаһаповка 48 яшь иде. Ул туган ягында – Лениногорск районы Иске Иштирәк авылында җирләнде.

ӘЛФИЯ АВЗАЛОВА
(15 ИЮНЬ):

«Татар җыры» дигәч, күз алдына Әлфия Авзалова килеп баса. Бу бөек, мәшһүр җырчысыз татар сәхнәсе нинди булыр идеме икән?! Үзе исән вакытта ук легендага әйләнгән, ике тапкыр Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнгән, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисткасы исемнәре алган, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты булган Әлфия апабыз!

«Үксез бала моңлы була» диләр. Бу гыйбарәне, әйтерсең, Әлфия апа өчен уйлап тапканнар. Әниләре тифтан дөнья куйганда кызчыкка – биш, сеңлесе Флүрәгә – өч, төпчекләре Гөлсирингә бер атна гына була. Әлфия апа, истәлекләре белән бүлешеп, болай дип сөйләгән иде: «Тәрәзә төбендә шырпы каплары белән уйнап утырам. Әнинең юрганга төрелгән гәүдәсен өйгә кертеп салдылар. Мин аның битләрен тотып карыйм: сап-салкын. Аннан мине икенче ихатага алып чыгып киттеләр. Бер атналык Гөлсирин дә шунда. Олыларның сөйләшүләрен ишетеп алдым: «Тернәкләнә алмас бу бала. Авзал да моны кеше итә алмаячак». Шулай итеп әни белән сеңелне бер-бер артлы җир куенына салдылар».

Әти-әнисез үссә дә, Әлфия апа кыюлыгы, булдыклылыгы, хәтта бер төрле усаллыгы белән дә аерылып тора. Әлеге сыйфат-

PRESSA.RU

лары аңа тормышта югалып калмаска ярдәм итә дә. Һәм, әлбәттә, сәләт, кабатланмас тавышы, моңы! Аның иҗаты турында сөйләп тору артыктыр...

Әлфия апа җырчы гына түгел, хатын-кыз, ана буларак та бик бәхетле кеше. Картлыгы да кадер-хөрмәттә узды. Соңгы ике елын кызы Зөлфия гаиләсе тәрбиясендә яшәде. Инсульт булганнан соң да, 7нче хастаханәдә аерым палата биреп, хөрмәтләп карадылар үзен. Мәшһүр җырчының хәлен белергә аерым җитәкчеләр дә килде. Бер минутка да ялгызын калдырмадылар. Соңгы бер-ике елда хәле бик яхшы булмаса да, саф акылында, үз аягында йөрде. Кем генә, кайчан гына хәлен сораса да: «Бар да яхшы, Аллага шөкер», – дип, кызларына, хәл белергә килүчеләргә рәхмәт укыды.

Әлфия апа: «Мине матур итеп күмегез, бизәгез. Кызыл күлмәгемне кидерегез. Сәхнәдән озатыгыз. Халык мине күрсен, саубуллашсын...» – дигән. Барысы да Әлфия апа теләгәнчә булды: 17нче июнь көнне Татар дәүләт филармониясендә хушлашу чарасы узды. Анда бик күп мәртәбәле шәхесләр, дәүләт вәкилләре килгән иде. Җырчыны Яңа татар бистәсе зиратында җирләделәр. Әлфия апага 84 яшь иде.

ИСМӘГЫЙЛЬ ШӘРӘФИЕВ (22 ИЮНЬ)

Без аны, үз итеп, «Исмәгыйль абый» дип атап йөрдек. Журналистика факультетын тәмамлагач та, нәкъ менә «Исмәгыйль мәктәбен» (журналистлар арасында шундый сүз бар) узуым белән үземне бик бәхетле дип саныйм. Университетта чын-чынлап язарга өйрәнеп булмый ул, бары тик менә шундый мөхәррирләр генә кичәге студенттан журналист ясый ала.

2006 елның көзе иде ул. «Татарстан яшьләре» газетасына кеше кирәк, дигәч, кыяр-кыймас кына Исмәгыйль абый янына кердем. Үзем белән бер язмамны да алып кердем. Ул күз йөртеп чыкты да:

– Хәреф танымсың икән, монысы инде начар түгел, – дип киная белән елмайды. Сөйләшү дәвамында янә берничә төртмәле сүз әйтеп куйды. Мин бөтенләй коелып төштем. Шуннан йөзен җитдиләндерә төшеп:

– Сиңа беренче бирем: Татарстанда биогумус ясыйлар, шул турыда яз. Тик кеше аңлый торган телдә булсын, – диде.

Ул биогумус дигәннәре нәрсә, кайдан табарга – ләм-мим!

– Чын журналист мәгълүматны үзе эзләп таба, – диде Исмәгыйль абый.

Озын сүзнең кыскасы, ул биогумус дигәннәре туфрак булып чыкты. Ләкин гади генә туфрак түгел: суалчаннарның бер төре, үзләре аша туфракны эшкәртеп чыгара да, ул бик файдалыга әйләнә икән. Мондый туфрак гөлләр үстерү, башка үсемлекләр өчен яхшы. Әлеге суалчаннар Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институтында бар, аның белән алар шөгыльләнә икән. Бу турыда бәйнә-бәйнә яздым. Әле редакциягә бер пакет биогумус та алып кайттым. Исмәгыйль абый әллә шул файдалы туфракка сөенде (гөлләр үстерергә ярата иде), әллә язманы тиз эшләп килгәнгә, әллә язма килеп чыкканга, белмим, иртәгәсен ул миңа эшкә чыгарга кушты. Шуннан башланды... Биш ел буе, үзе әйткәнчә, «кеше аңлый торган телдә язарга» өйрәтте. Таләпчән дә, шул ук вакытта хәлгә дә керә белә иде. Көн саен иртән тугызда җыелыш ясар. Һәр язманы анализлап, селки-селки сөйләр. Кирәк икән, катырак та әйтер. Җыелыштан соң кәеф төшкәнне күрсә: «Үпкәләдеңме әллә? Мин үлгәч искә алырсың әле, башкача язарга өйрәнеп булмый...», – дип тә өстәр. Әйе, менә ничә елдан соң шуларны искә алып утырам...

Аерым сәбәпләр аркасында 2014 елда «Татмедиа» басмасына китәргә булдым. Исмәгыйль абый усал гына:

– Ник китәсең? – диде. Сәбәбен аңлаткач:

– Сез шулай, язарга өйрәнеп беткәч, ташлыйсыз да китәсез. Ярар, «Татарстан яшьләре» мәктәбен узган кешеләр югалмый ул...

Исмәгыйль Шәрәфиев «Татарстан яшьләре» газетасын 1990 елдан бирле җитәкләде. Яман чирдән 66 яшендә бакыйлыкка күчте. Үзенең теләгеннән истә тотып, әнисе белән әбисенең каберe янына – Әтнә районының Олы Әтнә зиратында җирләнде.

ШАМИЛ ӘХМӘТШИН (3 ИЮЛЬ):

Озак еллар дәвамында Кукмара итек фабрикасы директоры вазыйфасын башкарган бу кешене белүчеләр беравыздан: «Чын кеше иде. Беркайчан масаймас, башкаларга ярдәмгә килергә һәрвакыт әзер торыр», – диләр. Фабрика эшчеләре бүген дә мәшһүр җитәкчеләрен искә алганда күз яшьләрен тыя алмый. Аны күпләр «атабыз» дип йөрткән.

Шамил Әхмәтшин Кукмара киез итек комбинатына 1988 елда җитәкче итеп билгеләнә. Аңа кадәр ул әлеге оешмада инженер булып эшли. Һәм монда шуны әйтү кирәктер: Шамил Әхмәтшинны директор итеп өстән куймыйлар, ә фабрика эшчеләре ачык тавыш бирү юлы белән сайлый. 33 яшьтә генә булуына карамастан, яңа вазыйфасының беренче көннәрендә үк комбинатны газ белән эшләү системасына күчерә ул. Бу итек басу эшен берничә тапкырга җиңеләйтә. Моның өчен эшчеләр Шамил

Әхмәтшинга бер рәхмәт әйтсә, Кукмарада яшәүче гади халык мең рәхмәт әйтә. Комбинатның ташкүмер ягуы аркасында, көн саен 600 кг корым чыгарыла. Газга күчкәч, халык чын мәгънәсендә чиста һава сулый башлый.

Болгавыр 90нчы елларда Шамил Әхмәтшин Кукмара киез итек комбинатын бөлгенлеккә төшүдән саклап кала. Совет чорында фабрика нигездә солдатлар өчен итек ясый. Нефтьчеләр, газчылар, тимер юл эшчеләре өчен җылы киемнәр тегә. Үзгәртеп кору еллары башлангач, әлеге заказларның берсе дә калмый. Нишләргә?! Директор вазгыятьне тикшерә, чагыштыра, өйрәнә. Якын-тирәдәге итек фабрикалары ябылып беткәнгә күрә, көндәшләр кимегән икән... Ә халык бит итек кия, Советлар Союзы таркалса да, кыш ел саен җитә. Димәк, базар мөнәсәбәтләренә күчәргә кирәк, гади халык өчен итек басуны арттырырга! Җитештерелгән итекләрне ул Россиянең төрле шәһәрләренә озату җаен таба, Себер белән араларны җайлый. Кукмара итекләре Казахстан, Белоруссиягә кадәр китә.

Бүген Кукмара итек фабрикасы җитештергән өс киемнәрен дә, аяк киемнәрен дә Татарстанда гына түгел, Россиянең башка төбәкләрендә дә беләләр, таныйлар. Шамил Әхмәтшин башлаган эшне шундый югарылыкта дәвам итәрләр, дип ышаныйк. Ә 30 ел биредә җитәкче булып эшләгән кеше, һичшиксез, безнең игътибарга, ихтирамга лаек!

Шамил Әхмәтшинга 63 яшь иде. Ул Кукмара зиратында, якыннары янәшәсенә җирләнде.

Кеше саны тулсын өчен генә
Тумаганмындыр, шәт, дөньяга...
Эчкерсез бер ихлас сүзем белән
Төзәлгәндер, бәлки, бер яра...

Юк, тикмәгә генә килмәгән мин,
Сере моның шактый тирәндә...
Кулым минем гел Кояшка үрелер
Яшәү өчен тавыш биргәндә!

Лена Шагыйрьҗан

ХӘНИЯ ФӘРХИ
(27 ИЮЛЬ):

Мондый үлем турындагы хәбәрне «аяз көнне яшен суккандай булды» диләр. «Татарстанның һәм Башкортостанның халык артисты Хәния Фәрхи вафат» дигән хәбәргә башта ышанасы да килмәде. Ничек инде, татар, башкорт сәхнәсен тоткан, меңләгән, миллионлаган тамашачының яраткан, карап торган Хәниясе шулай көтмәгәндә-уйламаганда, әле гөрләтеп җырлап йөргән чагында китеп барсын ди?! Булмас... Тик куркыныч хәбәр хак булып чыкты. Җырчы туган ягы – Башкортостанның Тәтешле районы Югары Тәтешле авылына 87 яшьлек әнисе янына кайткан булган...

Хәния апа белән хушлашу башта Башкортостанда узды. 29 июль көнне исә Казан, Татарстан тамашачысы, җырчының якыннары, коллегалары Галиәсгар Камал театрына җыелды. «Моңа кадәр берәүне озатырга да моның кадәр халык килгәне юк иде», – диделәр. Әйе, тамашачы яраткан җырчысын озатырга ташкын булып агылды да агылды. Нәтиҗәдә, Камал театры мәйданында энә төшәрлек тә урын юк иде.

Хәния Фәрхи сәхнәдә дә, тормышта да ихласлыгы белән башка күп кенә җырчылардан аерылып торды. Эрелек, мин-минлек, йолдызлык чире юк иде аңарда... Һәм, әлбәттә, кабатланмас тавыш, моң, зәвык белән киенү сәләте... Популярлык өчен тагын ни кирәк?! Ире-хатыны, яше-карты – барысы өчен дә «яраткан Хәниябез» иде ул.

Хәния Фәрхине популяр иткән җырлар – «Сагынам сине, Питрәч», «Үпкәләсәң, әйдә, үпкәлә», «Онытылыр димә», «Кайтам әле Әлдермешкә», «Утыр әле, әни, яннарыма»... Күп алар! Җырчы үзе һәр әңгәмәсендә гомер иткән тормыш иптәше – Габделхәй Бикташиров турында: «Ул булмаса сәхнәдә 30 ел җырлый алмас идем», – ди. Чынлап та, ир белән хатын бер-берсен тулыландырып яшәүче ике газиз җан булып яшәде. Россиянең төрле шәһәрләренә гастрольгә йөрүләр, «Бәйрәм» ансамблен халыкка таныту... барысы да ир белән хатынның уртак хезмәте. Габделхәй абый исә Хәниясез калганлыгына һаман ышанып бетә алмый: «Хәниясез тормышны ничек башларга белмим әле... Казанда да, авылда да бөтен нәрсә аны хәтерләтә. Гаҗәеп кеше иде: нәрсәгә тотынса, шуны сәнгать дәрәҗәсендә башкарды. Авырлыкларны түземлек, сабырлык белән җиңеп килде. Башына операция ясаткач та, ике аягы сынгач та, ике айдан сәхнәгә чыкты. Бу юлы үлемне җиңә алмады...»

Хәния апа бер әңгәмәсендә: «Мин көтмәгәндә, атылган йолдыз кебек китәм әле», – дигән. Шулай булды да. Күктә бик якты зур бер йолдыздай балкыды да кинәт кенә атылып юк булды. Бик юксыналар, юк, юксынабыз сезне, Хәния апа...

Аңа 57 яшь иде. Җырчыны Казанның Яңа Татар бистәсе зиратында җирләделәр.

PRESSA.RU

КАҺАРМАННАРГА СУСАУ:
БЕЗ АЛАРНЫ ТАНЫЙБЫЗМЫ?

Тиздән Яңа ел һәм ул ияртеп килә торган кышкы «каникуллар». Һәркем Яңа елдан могҗиза өмет иткән шикелле, кышкы ял көннәрен дә дөньясын тамырдан үзгәртердәй булып көтеп ала. Ә яллар дигәнебез... үз ыгы-зыгысы белән узып та китә. Безнең редакциядә соңгы арада популяр булып киткән «хюгге» төшенчәсенә нигезләнеп, кышкы ялларның бер генә көнен булса да китапларга багышларга өндәр идем. Чөнки, психологлар әйтүенчә, нәкъ менә яхшы китап һәм кызыклы каһарман белән уздырган бер генә көн дә кешенең баш миен башка форматка көйләргә, караш ракурсын үзгәртергә сәләтле.

Автор:
Луиза Янсуар

Тормыш ыгы-зыгысы эчендә була шундый мизгелләр: тукталып калабыз да, дөньяга шаккатып, таң калып карап торабыз. Быел кыш шактый соң килде – декабрьнең башында гына көттереп, зарыктырып чын-чынлап кар яуды. Әнә шул кар яуган мизгелдә булды минем өчен иң беренче сигнал – азга гына, беразга... туктат конвейерны һәм, иркен сулап, тирә-юнеңә бак. Янәшәңдәгеләрне күр. Һәм аларның үзең өчен ни дәрәҗәдә кадерле булуын ваемла. Ә аннан – ҮЗЕҢНЕ! Чөнки еш кына үзебез өчен үзебез кадергә мохтаҗлар сафында гел иң соңгы рәтләрнең берсендә калабыз, тормыш куа-куа...

Бу китапларның – реальме алар, уйдырмамы, анысы әллә ни мөһим түгел! – каһарманнары өчен үзеңне тою һәм тормыштагы һәр мизгелнең кадерен белү тойгысы иң беренче урында. Зыянга булмас аларны актарып чыгу безгә дә...

БӘХЕТЕҢ – НИЧӘ БАЛЛЫ?

Хелен Расселл. Хюгге, или Уютное счастье по-датски.

Безнең бүгенге тормыш коточкыч зур тизлекләр һәм үзгәрешләргә корылган. Кеше аңы, бу тизлеккә яраклашып, аның артыннан куа-куа да, билгеле бер мизгелдә үзенең бушка (рус телендә моны бик яхшы чагылдыра торган «вхолостую» дигән сүз бар) эшләвен аңлап ала. Ә бит никадәр генә йөгерсәк тә, әллә ни алга киткәнебез юк әле. Һәм сорау туа: бу чабыш, куыш, узыш безне бәхетлерәк итәме соң? Шәхесебезне зынҗырламый, шаблонга әверелдермиме? Әллә нибары көнкүреш минимумын тотрыклырак күрсәтер, үзебезне кемдер итеп хис итәр өчен аяусыз көрәш булып кала бирәме?

Китапның үзенә күчкәнче, аның авторына тукталып узмасак, дөрес булмас иде. Хелен Расселл – Marie Claire UK журналының элеккеге редакторы, журналист. Карьерасын һәм тормышын үзгәртеп, ире белән провинциаль Ютландия ярымутравына күченеп китә, хәзерге көндә

ул – Guardian газетасы корреспонденты, Telegraph өчен Дания турында колонка алып бара. Хелен Расселл, китабы дөнья күргәннән соң, очрашуларга еш йөри, лекцияләр укый. Һәм бу лекцияләр... без барыбыз да койрыгыннан тотарга тырышкан бәхет турында. Урамда – XXI гасыр. Бәхет турында (аннан да бигрәк – бәхетсезлек турында) бүгенге заман кешесе ачыктан-ачык, уртага салып сөйләшергә күнекмәгән. Гәрчә аны безгә төрле матур тышчаларга төреп, һәр адымда тәкъдим итеп торсалар да. Тиздән ул безгә, әйтик, балкып торган Яңа ел поездында Coca Cola бренды астында килеп җитәчәк... Ә менә шушы Көнбатыш вазгыятендә Хелен Расселл бәхет турында сөйләшүне кирәк дип таба, һәм моңа батырчылык та итә. Һәм бәхет төшенчәсенең ул, иң беренче чиратта, кеше шәхесенә карата булган ихтирамга барып тоташканлыгын аңлый.

Я работала редактором в глянцевом журнале и чувствовала себя обманщицей. Целыми днями я наставляла своих читательниц, как гармонично сочетать работу с личной жизнью, добиваться успеха, сохранять душевное спокойствие и здравость ума, заниматься спортом, следовать модным тенденциям в одежде, наконец, излучать сияние и радость. При этом сама я до сих пор выплачивала студенческий кредит, а в течение дня, чтобы поддерживать тонус, поглощала лошадиные дозы кофеина и не могла заснуть без бокала «Совиньон блан».

Воскресными вечерами предстоящая рабочая неделя вызывала у меня привычное чувство тоски... Мои устремления превратились в ускользающую цель: стоило мне приблизиться к результату, как возникали новые задачи, которые накрывали меня с головой. Перечень жизненных приоритетов – того, в чем я нуждалась и что необходимо сделать, все время расширялся, а мои силы уже не соответствовали возрастающим амбициям. Синдром хронической усталости стал моим постоянным спутником, и собственная жизнь казалась хаотичной и разбитой. Я вечно бралась за множество дел и с завидным упорством не справлялась с многозадачностью.

Һәм менә бу тормышның инде анык билгеләнгән прагматик социаль һәм рухи курсларын тулаем борып, Даниягә күченеп китәләр алар. Картаймыш көнендә, пенсия ялына чыккач, Джессика Флетчер кебек детектив романнар язып утырырмын, дип хыялланган героиня өчен иренең «мине Даниягә атаклы LEGO компаниясенә эшкә чакыралар» дигән хәбәре башта аяз көндә яшен суккандай яңгыраса да. Хәер, пенсиягә әле ерак, тормышлары – тоташ йөгерү дә борчу... Җитмәсә, бәби алып кайту теләкләре дә чынга ашмый. Ә Дания... Дания нәрсәседер белән ымсындыра, дәшә...

Монда кешеләр балалар коляскаларын курыкмыйча урамда калдырып китәләр, машиналарын, велосипедларын бикләмиләр, дип инандыра Хеленны Орхус университетының икътисад профессоры Кристиан Бьернсков. «Бу прогрессив илдә кояш астында һәркем үз урынын таба ала, һәркемнең хокуклары – беренче урында, ә моңа бары тик бер-береңә булган ышаныч аша гына ирешеп була. Иерархия буенча без – һәммәбез дә тигез...» – коммунизм лозунгына тартым булып тоелса да, моны реаль фактлар белән расларга омтыла әлеге дә баягы профессор. Тора-бара тормыш үзе дә күрсәтә башлый кайда ак, кайда кара икәнен.

Престижлы эшен калдырып, Лего-мен (ирен, үз итеп, шулай атый Хелен) артыннан яңа тормышка чыгып киткәндә, аңа ахмакка карагандай карыйлар: «Син нәрсә, шундый эшне калдыралармыни?! Өйдә утырмакчы буласыңмы?! Тагын кая урнаша аласың шулай әйбәт итеп?!» Юк, ди ул ярымпышылдап, өйдә утырырга җыенмыйм... һәм инде башка үземне корбан итәргә дә, дип өсти арыган, талчыккан эчке «мине».

Матурлык, уңайлылык һәм бәхет төп төшенчәләр исәпләнгән, 10 баллы шкала буенча бәяләнгән бу илдә урнаша башлауга, алар, аңлашыла ки, мондагы эстетика, кыйммәтләр, иҗтимагый тәртипләр белән дә күзгә-күз очрашалар. Кредит системасымы ул, Баухаус төзү һәм сәнгати конструкцияләү, дизайн мәктәбеме, чүп-чарны ничек-кайда ташлау гадәтеме... Даниядәге шартларда Хелен героинясы Элеонора Портер героинясы кыйммәтләренә якынайгандай була – «шатлык өләшү уены»на. Җирле халык та аларны моңа якынайту өчен үз көчен куя. Кафелардагы гап-гади официантлардан башлап:

– Зима – тяжелое время года для иностранцев, – сказала она. – В Дании это время уютной, семейной жизни. Все сидят за закрытыми дверями. С ноября по февраль датчане кутаются. Не удивляйтесь, если на улицах будет малолюдно, особенно в сельских районах.

– Значит, вот где они все! А чем они занимаются?

– Они занимаются хюгге, – ответила Пернилле.

– Простите, что?

– Хюгге. Это такое датское слово.

– И что оно означает?

– Трудно передать словами...

– Это глагол или существительное?

– И то, и другое, – ответила Пернилле. – Хюгге означает «сидеть дома, в уютной обстановке, при свечах».

Өйдә генә түгел, ә эштә дә бәхетле булырга омтыла даниялеләр, Хелен Расселлга ышансак. «Эштән бәхет табу» дигән махсус төшенчә дә бар икән аларда. Монысы да мине, буржуаз-капиталистик мохиттән аерып алып, социализм чорына алып кайткандай була, «якты киләчәк»кә илтүче курс турында балачакта ишеткән мифларга тоташтыра. Эшне тормышның иң төп кыйммәте дәрәҗәсенә күтәреп, күзләренә ак-кара күренмичә, карьера ясауга курс тотмый даниялеләр, ди китап авторы. Ә нәрсәгә тоталар алар курсны, дигән сорау килеп туа үзеннән-үзе. Бу сорауга җавапны китап битләрендә пәйда булган чираттагы данияле танышы бирә Хеленның: «Тормышта баланс җимерелсә яисә ул озак кына пәйда булмаса, үз-үзебезгә сорау бирәбез: «Без шушы урында бәхетлеме?» Әгәр җавап канәгатьләндерә икән, димәк, әлеге урыныңда калырга кирәк. Юк икән – китәргә...»

Авыруларга тарымас, гаиләне җимермәс, балаларны тилмертмәс, әти-әниләрне хәсрәтләндермәс, мәхәббәтне харап итмәс... һәм башка тагын бик күп «өчен»нәр... өчен! «Ә кая китәргә?!» – дип гаҗәпләнә Хелен героинясы, нәкъ безнең кебек үк. «Ә без эшне, мохитне алмаштырырга курыкмыйбыз, чөнки бездә кеше, эшсез калып, тамак туйдыра алмый яшәмәячәк, безнең дәүләтебез бу яктан ышанычлы», – дип елмая танышы Ида. Шулай итеп, акрынлап без Даниянең

PRESSA.RU

иҗтимагый структурасына төшенә башлыйбыз һәм «хюгге»нең асылын да ныграк аңлыйбыз. Моңарчы инде безгә очраган профессор кебек үк, Ида да үзенең бәхет баллын 8 саны белән билгели. Китап авторының «Ә 10 булсын өчен нәрсә җитми?» – дигән соравына икесе дә бердәй җавап кайтара: «Мин әлегә үз мәхәббәтемне очратмадым, аны очраткач, бәхетем 10 баллга күтәрелəчәк…»

Бу схемага ышана да алабыз, ышанмый да. Гәрчә китап каһарманнары безне үзләренең бәхет рецептына якынаюын, аны татып каравына инандырса да. Үзең барып, яшәп карамыйча, читтән бәяләү мөмкин түгелдер. Әмма бит сүз… бәяләү турында бармый. Тәрәзәләр артында гүләп чапкан дөньяның тырнакларыннан ычкынып, кайчан эштән вакытында кайтып кергәнегез, шәмнәр ягып, ваннада изрәгәнегез, якыннарыгыз белән кичке аш өстәле артында җыйналып, озаклап гәпләшеп утырганыгыз, иртән будильник тавышына сискәнмичә, тәмләп, иркенләп кенә йокыдан торганыгыз, тәрәзә артындагы буранга хозурланганыгыз… бар соңгы арада? Яңа ел каникулларын көтәсездер, шәт. Без дә көтәбез!

«ЯРАТКАН ҖИРЕМДӘ ЯРАТЫП ЯШӘР ӨЧЕН…»

Ольга Покровская. Рад, почти счастлив…

Ә бит Яңа ел тойгысы хуш исле мандариннар һәм бизәлгән чыршылар белән генә килми. Кайчакта без аны кайнап торган җәйге челлә уртасында да тоеп алырга мөмкинбез. Тормышны яңарту, аңа моңарчы булмаган якты төсләр, бизәкләр өстәү зарурияте кебек үк… Ольга Покровская романындагы каһарман Иван, беренче карашка, рус прозасы өчен характерлы, типик герой, дияргә дә мөмкин. Әмма ул инде безгә шактыйдан очрамаган булгангамы, берара танымыйча, аптырабрак торабыз. Ә аннары, танып алабыз да, аның артыннан гадәти дә, шул гадәтилеге белән кадерле дә, җуелыбрак та барган тормышка күмеләбез. Һәм, кинәт кенә, өйгә кайткандай булабыз. Советлардан соңгы пространствога алмашка килгән капиталистик кыйммәтләр, көтмәгәндә-уйламаганда, мәтәлчек ата да, әһәмиятен югалта. Без җиңел генә, әйтерсең, кар өстеннән яланаяклап атлап, Тарковский фильмнарына, Брейгель киндерләренә, Бах прелюдияләренә барып эләгәбез… һәм кар салкынын түгел, болын чәчәкләре хуш исен, кояш җылысын тоябыз… Бу тойгы бүгенге тормыш динамикасына бөтенләе белән тәңгәл килмәгәнгә, безгә дә тәңгәл түгелдер кебек тоелып, уңайсызланып китәбез. Берәрсе безне ялкаулыкта, тормыштан артта калуда, «неудачник»лыкта гаепләмәсен, янәсе. Ә гаепләсә?!

Жизнь прошла и смерть прошла, он почти забыл их муку и принялся за дела, те же, что и «при жизни». Что именно случилось с ним, он уже и не помнил, и не хотел оборачиваться. Слава богу, главное уцелело: природа, дом, душа и рассудок – всё, что нужно человеку. Иван сознавал своё везение и ему ничего не хотелось добавить к имеющемуся.

За последний год в его городском жилище произошли перемены, которые можно было бы определить, как упадок, если бы не трогательное отношение к ним самого Ивана. Встали настенные часы, поломались электроприборы – посудомойка и чайник, беспорядочно разрослись лимоны, лианы, герани, перестали закрываться разбухшие межкомнатные двери. В этих руинах и зарослях колыхалась жизнь: растения требовали питья, врывались телефонные голоса и просили участия. Иван на «руины» смотрел с удовольствием, цветы поливал и участие проявлял исправно.

Да и вообще, без спешки, лишённый целей, он испытывал хорошее чувство – как будто, наконец, добрался до дома. Оставалось попивать чай да наблюдать за пьесой, в которой с некоторых пор у него нет роли. Нет, он действительно не играет – всё!

Окончательно излечившись за лето от старой тоски, Иван с умилением перечитал свои прошлогодние записи – дневник борьбы за радость, коллекцию волевых актов, которые должны были спасти его из пропасти. Ложиться в одиннадцать, вставать в шесть, бегать, выучить испанский, сочинить фугу, следить, чтобы в плечах не было зажима, жить для людей!

Данияле «хюгге»ның ни икәнен без азмы-күпме төшендек инде. Ә менә үзебезчә, россиячә бәхет – ул нәрсә? «В чем сила, брат?» – Данила Багровның 90нчы елларда шигарьгә әйләнгән әлеге соравына җавап булган «В деньгах» әле һаман да актуальме? Китапның беренче битләреннән ук башны шушы уйлар бораулый башлый. Юк, бу Обломовча бәхет турындагы әсәр түгел, бу бүгенге җәмгыятьтә ниндидер келәймәләр тагу куркынычыннан шомланмаган, тормыш курсын үзенчә билгеләргә омтылган яңа заман каһарманын эзләп табу омтылышы. Кулланучылык җәмгыяте тәкъдим иткән кыйммәтләргә ризалашмыйча, үзен офис костюмнары белән галстуклары рәвешендә күзалламаучы, умырткасы булган, әмма ул умырткаНы әле тормыш кануннарына яраштырып утыртып җиткереп өлгермәгән шәхес фәлсәфәсе.

Дөресен генә әйткәндә, сусаган идем мин мондый каһарманга рус прозасында. Данила Багровлар чоры узды, хәзер җәмгыять канлы пычакларын һәрбер чатта айкамый, айкаса да, күзгә күрсәтми, тышкы пәрдәләр белән, битлекләр белән каплый... Әмма күңелне тарткан, җилкендергән, яраттыра алган каһарман... әлегә күренми иде. Көнбатыш каһарманнарына, аерым алганда, Бегбедер «супер мачо»ларына клише рәвешендә эшләнеп, безнең шартларга «кертеп утыртылган» Минаев эталоннары да, Акунинның тарихи сөрмәле Фандориннары да, хәтта ки Гришковецның альтер-эголары да әлеге бушлыкны тутыра алмады... Ә монда, Ольга Покровская китабында, велосипедына утырып урман сукмагыннан җилдерүче Иван пәйда булды да кинәт сискәндерде.

Әйе, ул кешеләрдән китеп, үз аскезасына бирелеп яшәүче ялгызак. Ул күрәләтә торып бирәүгә дә бармый, берәүгә дә үз фәлсәфәсен такмый, берәүне дә артыннан өндәми. Ул заман идеологиясен тудыручы лидер түгел. Бу урында хәтергә үзебезнең татар әдәбиятындагы Зөлфәт Хәким, Марат Кәбиров образлары килеп төшә. Рафаэль Сибатның «Ялгызак» әсәре... Әмма аларның геройларында барыбер дә бимазалану, бәргәләнү ярылып ята. Ә Иван – бәргәләнми, кабаланмый, каударланмый. Иван – гамәлләренең файда китерер вакыты җиткәнен көтә, ә аңарчы тормышның һәр көнен тәмләп, яратып яши. Чөнки башкача яшәсә бу тормыш – аныкы, ул бу тормышныкы булмаслар иде. Башкача яшәсәләр, алар битлекләр кияргә мәҗбүр ителер иделәр...

Күрше хатыны Оля белән, үсмер Костя нәкъ менә заманга яраклаша белмәве, лидер булмавы өчен шелтәли, хәтта ки гаепли дә героебызны. Әмма үзләре тормышта туып торган һәр яңа, көтелмәгән, катлаулы ситуация саен Иванга киләләр. Аңардан киңәш сорыйлар, ярдәм эзлиләр, аңарга таяналар. Әнисе кайдадыр чит илләрдә бәхетен һәм мәхәббәтен эзләп йөргәндә, әтисе үз-үзе белән мәшгуль булганда, Иван көн дә кереп, хәлләрен белеп, дарулар алып кайтып, тормышларын ямьләп, авыру әбисе белән бабасын тәрбияли, әти абруе җитмәгән Костя белән Макска шул җылыны һәм ныклыкны бирергә омтыла... Ул күбрәк урман һәм җәнлекләр белән дус. Ольга Покровская романы битләреннән күпмедер дәрәҗәдә урманга китеп аерым кельяда яшәгән, кулдан аюларны, кош-кортларны ашатып йөргән Серафим Саровский рухы да агыла шикелле тоелып китә вакыт-вакыт. Гәрчә дини һәм рухи ориентирлар темасына бик сак кагылса, сизелер-сизелмәс кенә орынса да...

Әсәрдә рухи темага игътибар мул бирелә. Нигездә, Костя каһарманы һәм аның яңа танышлары – Женя, Паша һәм Маша образлары аша. Фолькер исемен йөртүче яңа заман лидеры – асылда, ять-яшь һәм, яшь булуына карамастан, бизнес-империя төзегән зат. Чит илдән баеп, тормыш тәҗрибәсе, бизнес идеяләр туплап кайтып, Россиядә аларны гамәлгә кертергә омтыла. Асылда, нияте изге дә кебек. Кыйбласы да дөрес. Ул яшьләргә һәм яшүсмерләргә инвестицияләргә тели, аларга йогынты ясый торган яңа интернет-технологияләр тудыру, мәйдан булдыру юнәлешендә эш башларга җыена. Әмма ул сайлаган, әле умырткалары ныгып өлгермәгән яшьләр, ни кызганыч, күбрәк Фолькерның тышкы тормышына исләре китә, аларның күзен аның яхталары, вертолетлары, аппартаментлары, кыскасы, байлыгы, уңыш формуласы кыздыра. Һәм шундый ук тормыш бүләк итәрдәй идеяләре, әлбәттә. Костя һәм аның кебекләр Фолькерга иман китерергә әзер...

Әмма Иван, Фолькерлар артыннан ияреп, туган иленә, ватанына Көнбатыш күзаллавын индерүләрен өнәми. Ул гомумән бәхетнең океан аръягында да, борынгылыктан заманчалыкка бездән алдарак аяк атлаган Европада булуына да ышанмый. Һәм бу хакта аермачык әйтә. Дусты Андрей аны Парижга алып киткәч тә, «Россиядән качып», Берлинда яшәүче сөйгәне Бэлланы күрү, аның белән күрешү, кавышу мөмкинлеге пәйда булгач та, ул барыбер... үзенең карлы-кышлы Россиясен сайлый. «Россиямне» дип авыз тутырып әйтми-әйтүен, әмма «өемне» дип, курсны аермачык билгели.

– Я удивляюсь, какие вы все одинаковые – как будто вас шлепали на одном диснеевском заводе. Заглатываете рекламу и мните, что нашли себя. Лодка или катер, дом на море или дом в Альпах, плюс красавица! Некоторые, правда, еще участвуют в интернет-спасении мира. Но, Андрей, ведь это все фантики!

Ахыр чиктә, тормышының асылын, үз кредосын болай тәгаенли Иван: «Шушы туфракны, янымда булган кешеләрне яратып яшәү». Совет чоры китапларын укып үскән балалар, ягъни безнең өчен җан азыгы булган Аркадий Гайдар, Владислав Крапивин романнарының геройларын хәтерләтә башлый ул вакыт-вакыт. Тимурны, Журканы... – әйтерсең, алар үсеп җиткәннәр дә, менә хәзер яңа җәмгыятьтә үз урыннарын эзлиләр. Әмма ул урынны табу читен, чөнки алардагы дөреслек хисе белән кешелеклек сыйфатлары заманыбыз чынбарлыгына тәңгәл килми. Шул рәвешле диссонанс туа да, бәхет төшенчәсе кулдан шуып ычкына... дияр идем, әмма юк, беркая да китми ул. Иван, нәкъ менә шул диссонанска карамыйча, бәхетнең һәр мизгелен тоеп яши. Ул аны кешеләргә дә өләшә – кадерләү, хәстәрләү, кайгырту аша. Без тормыш ыгы-зыгысы, куемтысы аша чапканда, берәр иске тыкрыкта очратсак, танымый да узар идек, мөгаен, аны. Әмма Ольга Покровскаяны укыгач, инде алай итмәбез, шәт.

P.S. Тәгаенләргә онытканмын: «хюгге» төшенчәсе – ул шәхси, «бары тик үзеңә генә ярашлы бәхет» дигән сүз.

PRESSA.RU

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНЫҢ ӘДӘБИ ПРЕМИЯСЕ

«Татарстан» журналының
әдәби премиясе

«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы һәм «Татарстан» журналы әдәби премиягә бәйге игълан итә

«Татарстан» журналы әдәби премиясе Татарстан матур әдәбиятына сизелерлек өлеш керткән әдәби әсәрләр иҗат итүче авторларны барлау һәм иҗатларына игътибарны арттыру максатыннан игълан ителде.

Премиягә түбәндәге жанрларда иҗат ителгән кульязмалар дәгъва итә ала: роман, повесть, хикәяләр циклы. **Әсәрләрнең Татарстан турында яки Татарстан авторы тарафыннан иҗат ителгән һәм моңарчы беркайда да басылмаган булуы – бәйгенең төп шарты!**

Кульязмалар Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә – русча һәм татарча – кабул ителә.

2017 ел дәвамында «Татарстан» журналы Экспертлар советы тарафыннан сайлап алынган текстларны журнал битләрендә һәм журнал сайтында protatarstan.ru басылып барачак.

Гран-при – китабыгызның басылып чыгуы.

2017 елның декабрендә бәйгенең жюрие ике телдә иҗат ителгән әсәрләр арасыннан җиңүчеләрне сайлап алачак – татар телендә бер әсәр һәм рус телендә бер әсәр. Икесе дә китап булып басылып чыгачаклар.

Бәйгенең шартлары:

1. Кульязманың электрон версиясе.
2. Номинант турында мәгълүмат – әсәр авторының фамилиясе, исеме, атасының исеме, контактлары – белешмә өчен телефоны, адресы).
3. Авторның кыскача иҗади биографиясе (әгәр әдәби әсәр берничә автор тарафыннан иҗат ителгән булса, һәрберсенеке).
4. Әсәрнең синопсисы.

Кульязма таләп ителгән материалларның тулы пакеты белән килмәгән очракта, жюри рәисе әсәрне кабул итмәскә хокуклы.

Кульязмалар tatarstan@tatmedia.com
электрон тартмасына «КОНКУРСКА»
тамгасы белән кабул ителә.

Конкурсны үткәрү вакыты 2017 елның 19 гыйнварыннан 2017 елның 15 декабренә кадәр.
Тулырак мәгълүмат protatarstan.ru сайтында. Конкурс йомгаклары турында «Татарстан» журналының гыйнвар санында укыгыз.

«Татарстан» журналының әдәби премиясе

«Татарстан» журналы өчен МАХСУС

Резеда ШӘРИПОВА

Яралы йөрәк

Резеда Сәрвәр кызы Шәрипова Азнакай районы Мәндәй авылында туып-үсә. Урта мәктәпне тәмамлагач, КДУның филология факультетында укый. Азнакайдагы «Маяк» газетасында бүлек мөхәррире булып эшли. Резеда Шәрипова поэзия һәм проза жанрында иҗат итә. Әсәрләре вакытлы матбугатта даими басылып килә. Берничә китап авторы. Азнакай районының М. Хәсәнов исемендәге премиясе һәм С.Сөләйманова исемендәге кызыксындыру премиясе лауреаты. Резеда Шәрипова «Гөлстан» район әдәби түгәрәгенә җитәкчелек итә. ТР Журналистлар берлеге һәм Язучылар берлеге әгъзасы.

Кирилл Суханов картинасы.

Бер дә чиргә бирешкәне юк иде Алиянең, әллә нәрсә генә булды. Юкса, тормышыннан зарланырлык түгел: үзе өчен җан атып торган ире, алма кебек балалары бар. Соңгы араларда йөрәге шаяра башлады. «Урының җылыда, авыр күтәреп эшләмисең,» – дисәләр дә, укытучы һөнәренең үз кыенлыклары җитәрлек анысы. Еллар буена барысы да җыелгандыр. Менә һич көтмәгәндә-уйламаганда операция өстәленә ятарга туры килде. Район үзәгендә булса бер хәл, республика хастаханәсендә ясадылар. Ара ерак, өйдәгеләргә мәшәкать булдым инде, дип борчылды Алия. Казанда хәл белешердәй якын туганы юк иде, шуңа күңеле дә бераз боекты. Авылдан Рәшите, балалары төянеп килеп кергәч, күзләреннән яшьләр тәгәрәде.

Бар да бер оя булып җыйналгач, Алиянең җанына тынычлык иңде. «Юк, мин аларны ташлап китәргә тиеш түгел, ничек тә аякка басарга, тормышны дәвам итәргә кирәк,» – дигән ныклы карарга килде. Юкса, табиблар операциягә дигәч, яшәүдән ваз кичеп, өмет канаты сынган иде.

Аякка басканчы янында улы Азамат булды. Акыллы, төпле бала. Беренчесе булгангадыр инде, һәр эшкә җаваплы карый. Ике сеңлесен дә тәрбияләште, өйдәге эшләрдә дә гел ярдәм итте Алиягә, бусы кызлар эше, дип тормады. «Бәхете генә була күрсен, тормышында үзе кебек ипле яр туры килсә ярар иде», – дип тели ана инде утызга якынлашса да, һаман өйләнергә базмый йөргән улына сокланып.

Азаматның әнисеннән бер генә яшерен сере юк дисәң дә була. Алар кайчагында сәгатьләр буе сөйләшеп сүзләре бетми. Хәтта кызлар турындагы иң яшерен серләре белән дә уртаклаша. Гөлнар турында да бик сөйлисе килгән иде, әнисе авырып киткәч, сүз кузгатырга базмый йөрде.

– Таныштыр инде әниең белән, әйдә, янына бергә барабыз, – дип, Гөлнар айга-вайга куймый кыстагач, бүген тәвәкәлләде.

Алар килгәндә Алия һава суларга бакчага чыккан иде. Улын ерактан ук күреп алды. Тукта, ниндидер кыз җитәкләгән түгелме? Ананың йөрәге сизгәндәй сызып куйды: «Йөзеннән нур балкый иде, юкка булмаган икән!»

Яшьләр хәзер кыю, кыз берниндн кыенсыну-тартынусыз кул биреп исәнләште.

– Әни, бу – Гөлнар, бергә эшлибез, – дип таныштырды Азамат.

Алиягә артыгын аңлатып тору кирәкми дә иде. Ул хатын-кыз көнчелеге һәм кызыксынуы белән Гөлнарның кимчелекле якларын табарга тырышты, янәсе, улына чынлап та лаекмы? Юк, артыгын бизәнмәгән-ясанмаган, табигый матурлыгын саклаган, кигән киеме дә килешле генә, артык кычкырып та тормый, шул ук вакытта заманча да. Буй-сыны да зифа, күз генә тимәсен. Әрсез дә, алай җебек тә түгел сыман. Гаеп таба алмады әлегә Алия кыздан. Күңеленнән генә улына хәер-фатиха бирде.

Җай гына сөйләшеп утырганда, Гөлнар кемнедер күргән кебек, талпынып куйды, йөзенә дулкынлануы бәреп чыкты.

– Берәр танышың бармы әллә? – диде Азамат ул караган якка борылып.

Гөлнар бернәрсә дә аңлатып тормады, Азамат белән Алияне билгесезлек эчендә калдырып, каршы якта утырган иргә таба юнәлде.

Үзе янына кемдер киләсен көтмәгән иде булса кирәк, ир кызның якынлашуын абайламады, уйларына чумып, карашын җиргә төбәгән иде.

– Әти?

Ир тавышка күтәрелеп карады. Гөлнарның шиге калмады.

– Әти!

– Гөлнар, әллә син инде? – Ир, таныш чалымнар эзләп, кызның йөзенә тутырып карады. Бер гамьсез шаян кызчыктан сылукайга әверелгән иде Гөлнар. – Дәшмәсәң танымас та идем, кара ничек зур үскәнсең! – диде ир соклануын яшерә алмый.

– Ә мин сине таныдым. Чәчләреңә чал кунса да, син әллә ни үзгәрмәгәнсең. – Озак вакыт күрми торган кадерле кешесен очраткан куанычыннан кызның йөзенә кояш кунды. Сабый чактагы кебек әтисенең кочагына сыенып, чәчләреннән сыйпыйсы килде, әмма еллар салкыны арага киртә булып яткан, алар бер-берсенә якынаерга базмый, утыргычның ике башында сүз алыштылар.

– Үзең кем янына килдең соң әле? – дип кызыксынды ир, хәл-әхвәл сорашкач.

– Дустымның әнисе янына. Әнә алар, теге эскәмиядә утыралар, – дип, Гөлнар Азаматлар ягына ымлады.

Ир елмаеп аларга баш кагып исәнләште һәм сискәнеп куйды: сораулы карашын төбәп каршы якта Алия утыра иде.

– Алия?! – дип пышылдады иреннәре сизмәстән.

– Әйе, Алия апа ул, – диде Гөлнар. – Ә син аны каян беләсең?

Ирнең маңгаена бөрчек-бөрчек салкын тир бәреп чыкты. Ул бер мәлгә югалып калды, Гөлнарга ни дип җавап кайтарырга да белмәде.

– Ә-ә, – дип сузды исенә килеп, – без бергә укыган идек, студент чакта…

– Ой, ничек шәп! – Гөлнарның сөенече эченә сыймады. – Әйдә тизрәк алар янына, әйдә, Алия апа сине танымагандыр да әле, сюрприз булсын!

Кыз әтисенең кулларыннан тартып торгызды һәм сөйрәп диярлек алып китте.

– Алия апа, кем бу, таныйсызмы?

– Мансур?!

Алия агарып китте. Аннан бите уттай яна башлады. Кирәк бит, язмыш вакытын да, урынын да сайлый белгән!

Алар сүзсез бер-берсенә карашып тордылар. Шушы бер мизгел эченә дистә еллар сыйган иде. Яшен тизлегендә ялтырап күңелдән истәлекләр узды.

***

Университет тулай торагы. Дискотека. Мансур ялгышып кына күзе төшкән бер кызны биергә чакырды. Танышып киттеләр.

– Алия, – диде кыз исемен.

– Мансур булам.

– Син кайсы факультеттан?

– Геофактан. Дүртенче курс.

– Мин дә дүртенче курстан, филфактан. Сине бер дә үзебезнең дискотекада күргән юк иде.

– Күрше тулай торактан мин, классташ егетнең туган көненә кердек. Ә сездә болай ярыйсы гына үзе, кызык икән.

– Күрше тавыгы күркә булып күренә, диләрме әле?

Шаяртып кына башланган сүз мөнәсәбәтләрне тирәнгә үк алып кереп китәр дип уйламаган иде Мансур. Шимбә саен ул күрше тулай торакка ашкына башлады. Шушы гади генә авыл кызында магнит кебек тарту көче бар иде. Әллә, чыннан да, беркатлылыгы, күңел сафлыгы җәлеп итте егетне, үзе дә аңламый. Ничектер җанга тыныч иде Алия белән. Тора-бара алар иртән лекцияләргә бергә барырга ияшләтеләр, киногa, театрларга йөрделәр. Аралар көннән-көн якынайды. Җәйге каникул егет белән

PRESSA.RU

кыз өчен зур сынау булды. Көзне алар болай беркайчан да түземсезлек белән көтеп алмаганнардыр.

Бишенче курс башланып, китапханәдә дәүләт имтиханына, диплом эшләренә әзерләнеп йөрүләре иде. Горький паркына төшеп, башларын беразсаф һавада җилләндереп, кышкы манзара белән хозурланып кайтасы иттеләр. Чалт аяз кышкы төн. Күктә чекерәеп янган миллионлаган кечкенә йолдызлар белән олпат ай идарә итә. Төз биек наратларның башы биеккә ашкан, әйтерсең, алар җир белән күкне тоташтырырга омтылалар. Шәһәр уртасындагы бу табигать утравында бөек сер, тирән мәгънә яшеренгән кебек. Башында нинди уйлар булгандыр, Алия кисәк:

– Син Аллага ышанасыңмы? – дип сорап куйды.

– Әллә инде. Минә минем әби көн-төн намазлык өстендә, ә тормышта бәхетләме соң ул? Сугышта ирен, тыныч тормышта үстереп, кеше иткәч улын югалткан. Гомере буе колхозга бил бөккән, фермада саз ерып, аяксыз-кулсыз калган.

– Яратканнарыма гына дөнья газабы җибәрермен дигән, ди безнең әби.

– Әби дә әби… Юк сүз куертмыйк әле. Бүген мин бәхетле – шунысына рәхмәтлемен.

Мансур кызны кулларына күтәреп алды да әйләндерергә тотынды.

– Чү, егасың! – дип тә әйтеп өлгермәде кыз, алар ястык кебек йомшак җиргә аудылар, кар сибешә-сибешә, өсләре ап-ак булганчы тәгәрәшеп уйнадылар.

Аннан үз җуләрлекләреннән көлә-көлә, агачлар арасыннан куышып, көрт ера-ера тулай торакка таба йөгерделәр.

Кайтуларына күңелсез хәбәр көтә иде: Алиянең әнисе каты авырып киткән, авылдан чакырып телеграмма сукканнар. Икенче көнне үк ул юлга чыкты.

***

Алиясез китапханәгә дә барасы килмәде Мансурның. Бүлмәдә пружиналы тимер кроватьта түшәмгә карап, ялгызы эчпошыргысыз уйларга бирелеп ятканда ишек шакыдылар.

– Керегез! – дип яткан җирдән генә кычкырды егет. «Кайсы әдәпле булып кыланган була инде анда?» – дип уйлады. Тулай торакта ишек шаку гадәте юк, студентлар аяк тибеп керәләр.

Әмма ишекне ачучы булмады. Тагын шакыдылар.

– Ишек төртерлек тә хәлсез кем йөри? – дип сукранып, торып, ишекне ачып җибәрсә, каршысында күз камаштырырлык сылу кыз басып тора иде. Егет каушаудан сүзсез калды.

– Гафу итегез, Риф шушы бүлмәдә яшиме? – диде кыз йомшак нәфис тавыш белән.

– Әһә, – дип ым какты Мансур һаман телгә килә алмый.

– Үзе юкмы әллә?

– Бар, бар, хәзер керер, күрше бүлмәгә генә чыккан иде, – диде егет хисләреннән айнып. – Уз, утырып тор, – диде ул кыюланып.

Кыз эчкә узды. Бүлмәдә эссе иде, ул тунының төймәләрен ычкындырды, башындагы бүреген салды. Кара чәчләре бүрек астыннан иреккә чыккач, дулкынланып иңнәренә таралып төште. Түгәрәк бит очларына алсулык йөгерде. Озын кара керфекләрен күтәреп, ул бүлмәгә күз салды. Бер генә мизгелгә аларның карашлары очрашты. «Ярабббый, бу карлыгандай кара күзләрдә адашырга мөмкин!» – дип уйлады егет.

Сөйләшми утыру мәзәк иде.

– Кайткач колагын борырмын әле Рифнең, шундый матур кызны кунакка чакырып, үзе әллә кая югалган! – Мансур сүзгә кеше кесәсенә керә торган түгел иде, анысы.

Кыз мактау сүзләренә тыйнак кына елмаеп куйды. Чит егет белән икәүдән икәү генә бер бүлмәдә утырудан кыенсындымы:

– Мин конспект артыннан килгән идем. Башка вакытта сугылырмын инде, – дип китәргә урыныннан кузгалды.

– Кем килде диярга соң?

– Венера диярсез.

– Матурлык алиһәсе димәк?

Егет асыл сүзләре белән кызны тагын елмаерга мәҗбүр итте.

Венера чыгып китәргә өлгермәде, ишектән Риф атылып килеп керде.

– Кызларны көттерү килешми егет кешегә! – дип шелтәләде аны Мансур.

Риф борын астыннан нидер мыгырданды, акланды, тумбочкасында шайтан үзе абынып, аягын сындырырлык мәшхәр арасыннан ашыгып-кабаланып конспектын эзләргә кереште.

– Кунак кызын чәй дә эчерми җибәрмибез, кая самавыр куйыйм әле, – дип Мансур җәһәт кенә электр самоварын тергезеп җибәрде.

– Юк, юк, сез нәрсә, болай да озакладым, башка вакытта, – дип карышты кыз.

– Бездәге кебек тәмле чәйне әле беркайда эчкәнең юктыр. Авыл мәтрүшкәсе белән! – Мансурның сихри гүзәл кызга озаграк сокланасы килә иде. Әйтерсең, ишек ябылыр да, ул бу гүзәллекне мәңге күрмәс.

– Мәтрүшкәле чәй дә эчкән бар, – дип ялындырды кыз.

– Ә башкорт балы? Рифләрнең шәхси умартасыннан!

Кыз балга да алданмады.

– Шә-ә-әп! – диде ишек ябылу белән Мансур.

– Шәбен шәп тә, безнең ботакка кунып сайрый торган кош түгел, – дип каршы төште Риф.

– Нигә тагын? Синең кай җирең ким? Буй-сын дисеңме, төс-кыяфәтме – нәкъ Салават-батыр!

– Казан кызы. Әтисе зур түрә.

– Бу яклап син хаклы, – дип килешми булдыра алмады Мансур. – Байлар байларны сайлый. Әкияттә генә ул ярлы егет бай кызына гашыйк була да, өйләнешеп, атасының ярты мөлкәтен алып, бәхетле итеп яшиләр.

– Бетмәс әле безгә дә Алия кебек берәр авыл кызы! – дип көлде Риф.

– Көлмә, буең озын дип тормам, ипи шүрлегеңә берне менеп төшәрмен! – диде Мансур, ачуы кузгалып.

– Мин бит көлмим, чынлап әйтәм.

– Алия дигәннән, озаклады әле ул да, ни эшләп һаман килми икән?

– Чын мәхәббәт шундый була торгандыр инде ул, әйеме? Бер генә көн дә бер-береңнән башка тора алмыйсыңдыр.

– Яшьрәк шул син, гашыйк булгач аңларсың әле менә. Венера кебек бер гүзәле башыңны әйләндереп җибәрсә!

– Кара, Мансур, Яңа елга чакырсам, килерме икән?

– Чакырып кара, башыңа сукмас. Кыюрак булырга кирәк, егет!

– Синең кебек бишенче курска җиткәч, мин дә шомарып бетәрмен әле.

– Без синең кебек чакта ук чос идек, энем! Кызлар җебекләрне яратмый, аң бул. Менә мин Алияне үземә ансат кына каратты дип уйлыйсыңмы әллә? Шактый тырышырга туры килде Мансур абзаңа! Артыннан бер тотам калмый йөргән авылдаш егете бар иде. Керә дә кысыла арага, керә дә кысыла. Күрәм бит, Алия мине күбрәк ошата, юк, теге һаман аяк астында буталып йөри. Саллы гына аңлатырга туры килде.

– Ә Алия?

– Җуләр, кем инде мөнәсәбәтләрне кызлар алдында ачыклый! Алия белми дә калды.

– Мут та егет инде үзең!

Дәвамын http://protatarstan.ru/tat/ сайтыннан укыгыз.

Язгыл һәм телевизор от!

1 Язгыл

31.12.2017 кадәр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең кимендә 3 басмасына язгыл *(акциядә катнаша торган басмалар белән tatmedia.ru сайтында таныша аласың)*

2 Җибәр

язылу квитанцияләренең күчермәсен «Акция» билгесе белән түбәндәге адреска җибәр *(телефон номерыңны күрсәтергә онытма)*: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 От

Телевизор, фотоаппарат һ.б. бүләкләр!

Акцияне үткәрү вакыты: 25.10.2017 - 20.03.2018

Акция турында тулырак – tatmedia.ru сайтында
Оештыручысы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте
Белешмәләр өчен тел.: (843) 222-09-84, өстәмә номер - 1261

16+
Реклама

МАХСУС ПРОЕКТ

28нче чыгарылыш

Татарстан юбилярлары

Әхмәт Мәзһәров,
техник фәннәр докторы, профессор, ТР ФА академигы, «ВНИИУС» ААҖ генераль директоры, гыйнварда 75 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Альберт Гыйльметдинов,
А.Н.Туполев исемендәге Казан милли-тикшеренү техник университеты – КАИ (КМТТУ-КАИ) ректоры, ТР ФА академигы

Юрий Гортышев,
КМТТУ-КАИ президенты, ТР ФАнең Математика, механика һәм машина белеме бүлеге академик-секретаре

Фото КМТТУ-КАИ матбугат хезмәтеннән алынды.

Фән һәм сәнәгать мөмкинлекләрен берләштереп

Хөрмәтле Әхмәт Мәзһәрович!

Юбилеегыз белән ихлас котлауларыбызны кабул итегез!

Сезнең хезмәт биографиягез Татарстан һәм Россия Федерациясе иминлеге өчен фәнни эзләнүләр белән аерылгысыз бәйләнгән. Сез олы тормыш һәм фән мәктәбе уздыгыз һәм ТР Фәннәр академиясе үсешенә бәяләп бетергесез зур өлеш керттегез.

Республика һәм бөтенроссия дәрәҗәсендәге фәнни-техник һәм социаль-мәдәни проблемалар белән бәйле, академия һәм вуз фәненең үзара бердәмлегенә ярдәм итүче фәнни юнәлешләр һәм өстенлекләрне үстерә барып, фән һәм сәнәгать мөмкинлекләрен берләштерә алдыгыз.

Сез бетмәс-төкәнмәс иҗади мөмкинлекләргә ия булган талантлы шәхесләрнең берсе. Туган Татарстаныбызның һәрьяклап үсеше өчен керткән өлешегез гаять зур. Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы һәм Президиум Киңәшчесе буларак, тәҗрибәгез һәм зирәклегегезне киләчәк буыннарга тапшыра барасыз.

Сезгә чын күңелдән ныклы сәламәтлек, бәхет һәм озын гомер телибез! Ниятләгән эшләрегезне тормышка ашырыр өчен омтылыш һәм бетмәс-төкәнмәс энергия һәрчак юлдаш булсын, фикердәшләрегез, дусларыгыз, якыннарыгыз һәм туганнарыгыздан беркайчан да аерылмагыз!

PRESSA.RU

БАКЧА-САРАЙ: КЫРЫМ – ҮЗЕБЕЗДӘ

Ел дәвамында республикабызның матур исемле, бай тарихлы авылларына сәяхәт кылдык. Сокланып та, кайчакта йөрәк әрнүе белән дә яздык алар турында. Ә иң үзенчәлеклесе ел азагына калган икән: Югары Осланның Бакча-Сарай авылын күздә тотам. Бер җирдә дә бу кадәр тәэсирләнгән юк иде әле. Авылның тарихы, урнашу үзенчәлеге, кешеләре – башка якларда күргән халыктан аерылып тора...

Автор:
Руфия Фазылова

УРМАН КИСҮДӘН БАШЛАНГАН ЭШ

Бакча-Сарай күркәм үткәне, танылган кешеләре белән башка авылларны уздыра алмый. Аның каравы, географиясе, табигате – искиткеч! Ул Идел елгасының нәкъ уң як ярында утыра. Әйе, бәхетле кешеләр яши биредә: кул сузымында гына Идел җәйрәп ята. Офыкта урман-таулар сызылып китә... Шушы гүзәллеккә таң калып, тын да алмыйча карап тордык.

– Ә сез бирегә җәен килегез, оҗмах почмагы бу, – ди авыл кешеләре.

Бакча-Сарай тау өстендә урнашкан, республиканың иң биек икенче ноктасы санала. Моннан ярты Татарстан күренә диярлек.

Гадәттә, авыллар тарихы халык сөйләгән, телдән-телгә күчкән истәлек-чыганакларга нигезләнеп төзелә. Бакча-Сарайда исә барысын да төгәл фактлар белән ныгыталар, чөнки аңа нибары 90 яшь кенә әле!

Авылның беренче кешесе – Ярулла Кәримов. Ул гаиләсе белән бирегә 1927 елда килеп төпләнә. Авылда туган беренче бала да нәкъ менә Кәримовлар гаиләсеннән була. Гайшә апа бүген дә исән икән, 87 яшьне тутырган. Казанда балалары тәрбиясендә яши.

– Бакча-Сарай исемен әнием Миңнехәят тәкъдим иткән, – дип сөйләде Ярулла абыйның оныгы Алсу апа Хәлиуллина. – Булат Солтанбәковның «История в лицах» китабында татарларга 1920нче елларда рәсми рәвештә яр буенда яшәргә рөхсәт ителә дип языла. (Тарихтан беләбез: Иван Грозный Казан ханлыгын басып алганнан соң су буенда урнашкан авыллардан татарлар куыла. Татарларга су буйларында яшәргә рөхсәт ителми. – Авт.) Ул вакытта безнең әби белән бабай Кама Тамагында Бәби авылында яши. 1925 елда бабайның өлкән улы, Казанда дәрәҗәле җирдә эшли. Авылга кайтып, әти-әнисен Идел елгасы буена күченеп утырырга өнди. Ярулла бабай, улының сүзен тыңлап, Матюшино авылы янәшәсендәге җирне барып карый. Ул вакытта анда куе урман үсә шаулап утыра. Бабай яр буен нык бик ошата, җитмәсә Казанга да якын. Икенче юлы ул Бәби авылының тагын сигез ир-атын да ияртеп алып килә. Агачларны кисәләр, землянка казыйлар. 1927 елда Бакча-Сарайга яшәргә гаиләләре белән күченеп киләләр.

Алсу апа Хәлиуллинаның әнисе хатын-кызлардан әлеге җирләргә беренче булып аяк баса. Ярулла абый унбиш яшьлек кызын урман кискән ир-атларга ашарга пешерергә алып килә. Буй җиткән кыз, биредәге матурлыкны күреп: «Бу бит Бакча-Сарай!», – дия. Шуннан төзелеп килүче авылга шул исем ияреп тә кала.

– Татарларның елга буена килеп урнашуын күршедә генә яшәүче Матюшино руслары яратмый, – дип сүзен дәвам итте Алсу апа. – Кайдан килдегез, шунда китегез, дия торган булалар. Әле ут төртәбез дип тә куркыталар. Ләкин Ярулла бабай бик үҗәт, кыю кеше була. «У нас тоже есть спички», – дип кенә җибәрә. Санаулы еллар эчендә Бакча-Сарайдагы йортлар саны унсигезгә җитә. Халык, урынга кызыгып, тирә-як авыллардан да килеп урнаша. Татарларның дус-тату, тырыш булуларын күреп, Матюшинада яшәүче рус кешеләре дә Бакча-Сарай халкына хөрмәт белән карый башлый. Ике арада дуслык күпере салына. Бер-берсенең телләрен өйрәнәләр, йомышка йөрешәләр.

Кәримовлар гаиләсендә 13 бала үсә, соңгылары Бакча-Сарайга күчеп килгәч туа. Ярулла абый зама-

Фото: Лилиана Вәлитова

нына күрә зыялы кеше була. Балаларына белем бирә. Үзе дә төшеп калмый – Бакча-Сарайда колхоз оешкач, аның рәисе итеп билгеләнә. Тик, кызганыч, авылда Кәримовларның йорты сакланып калмаган, янгын чыгып харап иткән.

– Мөслим районында яшәсәк тә, барлык җәйге каникулларыбыз Бакча-Сарайда узды, – дип хатирәләре белән бүлеште Алсу апа. – Май азагында кайтып, Мөслимгә яңадан сентябрь башында гына килә идек. Шуңа күрә Бакча-Сарай миңа туган авылым кебек якын. Бабайның йорты ике тапкыр янды. Өченче тапкыр яңа йорт салып тормады, иске бер өйне нигезенә кучереп кенә куйдыртты. Бик зур хыял-өметем бар – Ярулла бабайның нигезенә мемориал такта эшләсеннәр иде. Авылга нигез салучыларның берсе бит ул.

Бакча-Сарай заманында совет зыялыларының ял итү урыны саналган. Мәскәүдән һәм башка шәһәрләрдән килеп, җәй буе бирéдә яшәгәннәр. «Киләсе җәйгә дә киләбез, йортыгызны кешегә бирмәгез», – дип, авыл кешеләренә күздән үк акча биреп калдырганнар. Шуның өчен күпләр, җәен килгән кешеләр өчен, йортларына икенче кат та өстәп ясарга тырышкан. Бакча-Сарайда кемнәр генә ял итмәгән: академик Петр Анохин, профессор Әбүбәкер Терегулов, шул чорның дәүләт җитәкчеләре һ.б.

– Ярулла бабайның йортында берничә җәй СССРның халык артисты, композитор Рөстәм Яхин яшәде, – дип сөйләде Алсу апа Хәлиуллина. – Аның белән бәйле якты истәлекләр күп миндә. Кызганыч, шуларны язып бармаганмын...



Бер төркем авыл кешеләре белән Бакча-Сарайның яңа гына федераль программа буенча салынган клубында очраштык.

ОҖМАХТАН – ШӘҺӘРГӘ...

Бакча-Сарай әллә ни зур түгел. Бүген бирéдә 208 кеше яши, 60лап хуҗалык бар. Ләкин җәен авылда халык саны бермә-бер арта икән, чөнки бакчачылар килә. Урта мәктәп, клуб, мәчет, кибет, кыскасы, тормыш өчен кирәк булган барлык социаль объектлар да бар. Дөрес, иске, диеп, балалар бакчасын ябып куйганнар. Әмма тиздән бу проблема чишелергә тиеш икән.

Бер төркем авыл кешеләре белән Бакча-Сарайның яңа гына федераль программа буенча салынган клубында очраштык.

– Бу авыл кешеләре өчен бик зур бүләк булды, – дип шатлыклары белән бүлеште җирле халык.

Бакча-Сарайның тарихын икегә бүлеп карап була: беренчесе – аның оешу, икенчесе чәчәк ату, киңәю чоры. Соңгысы 1960–1970нче елларга карый. Бирéдә известь чыгара башлыйлар. Нәкъ шуның нәтиҗәсендә Бакча-Сарайга юл салына, эш бар дип, күрше авыллардан гаиләләре белән кешеләр күченеп килә.

– Авылда Рәшит Кадыйров исемле бик тәҗрибәле агроном бар иде, – дип сөйләде Шәүкәт абый Җәләлетдинов. – Авыл башындагы үзәнлектә җәелеп яткан ак известьне Казанга тикшертергә алып бара ул. Агроном шулчакта ук аның туфрак өчен бик файдалы икәнен сынап караган була. Чынлап та, махсус тикшерү күрсәтә: 96 процентлы чиста известь бу! Шулай итеп 1967 елда карьер оештырдык. Мине аның җитәкчесе итеп билгеләделәр. Тирә-як авыллардан да известька килделәр. Җирне аның белән эшкәрткәч, уңыш бермә-бер арта иде.

1980 елда Матюшино карьерын (Бакча-Сарай белән ике арада ул) рәсми рәвештә ачалар. Татарстанның төрле районнарына

PRESSA.RU



Гөлнара Насибуллова хуҗалыгы.

су юлы аша тонна-тонна известь төяп җибәрәләр. Ул чорда карьерда 300ләп кеше эшли. Эшчеләргә дип махсус йортлар салалар.

– Бакча-Сарайда бушка торак бирәләр дигәч, 1983 елда ирем белән монда күченеп килдек, – дип сөйләде китапханәче Гүзәлия апа Нигъмәтуллина. – Йортлар ике гаилә өчен дип салынган иде. Соңрак без аларны хосусыйлаштырдык.

Бакча-Сарайның клуб мөдире Асия апа Фәйзуллова авылга 1989 елда килгән.

– Бездән соң әзер йортлар бик бирелмәде инде, – дип сөйләде ул. – Теләгән кеше басу ягыннан җир алып йортлар салды. Ул чорда авыл гөрләп торды. Хәзер генә бетеп бара ул. Яшьләр калмый...

– Ни өчен? – дим. – Бакча-Сарай Казанга 50–60 чакрымда гына, эш бар. Мондый җирдән дә матуррак урын таба алмыйлардыр бит?

– Әйе, табигать искиткеч бездә. Тик, дөресен әйткәндә, җәй көне бер тапкыр елга буена төшеп су коенган да юк безнең. Кешеләр Казаннан, әллә кайлардан килә. Елга буенда энә төшәрлек урын да булмый. Ә без... Әллә күз күреп ияләнгән, әллә вакыт таба алмыйбыз шунда... Табигать белән генә булмый, яшьләргә акчалы эш кирәк. Рәхәт тормыш эзлиләр. Авылда әллә ни эше дә юк. Карьерда элеккеге кебек күп кеше эшләми, известька сорау һәм ихтыяҗ кимеде. Менә шулай картая авыл.

Әлбәттә, Бакча-Сарай йөзләгән башка авыллар кебек юкка чыкмас. Мондый гүзәл авыл урамнарын чүп үләне басмас, дип уйлыйм. Тик ул дача урынына гына калмасын иде. Хәер, өмет бар әле.

ҖЫРЧЫ ФЕРМЕР?!

Өмет дигәнем Гөлнара Насибуллова кебек яшьләр. Бу сөйкемле кыз ялгызы 20 баш мөгезле эре терлек асрый. Тугыз савым сыеры гына бар! Шуның өстенә, атна саен шимбә көнне Казанга ярминкәгә килеп, сөт ризыклары сата. Гөлнарага 26 яшь. Гади, шул ук вакытта үткен әлеге кыз яхшы мәгънәсендә гашыйк итте үзенә.

– Яшьләр авылда калмый, дип зарланабыз. Син бу стереотипны җимереп ташлагансың, – дим Гөлнарага.

– Казан дәүләт авыл хуҗалыгы институтын тәмамлагач, Казанда эшкә урнашкан идем. 2015 елда кинәт кенә әтием вафат булды. 62 яшь кенә иде. Әнигә ялгызына бик авыр дип авылга кайттым. Сыер, бозауларны да карарга кеше кирәк бит.

– Әтисе исән вакытта фермерлык эшенә бергә алынганнар иде, – дип сүзгә кушылды Гөлнараның әнисе Зөлфия апа. – Фәһим белән өч кыз үстердек. Гөлнара – иң кечесе. Кечкенәдән үткен, эшкә батыр булуы белән аерылып торды. Хайваннарны бик яратты. Бернәрсәдән курыкмады.

Баксаң, Гөлнара 23 яшендә үк фермер булырга хыялланган. Казанда эшкә урнашып, алты ай хезмәт хакы ала алмагач, әти-әнисенә кайтып: «Әйдә, күп итеп маллар асрыйк, үзем карыйм», – дигән. Фәһим абый кызының фикерен хуплаган. Сыер, үгезләр алганнар. Тик, ни кызганыч, ата кешенең якты хыялы тормышка ашып килүен күрергә гомере җитми калган шул.

– Әтинең рухы шат булсын дип тә тырышам, эшне дәвам итәм, – дип җөпләде сүзен Гөлнара. – Авыл хуҗалыгы өлкәсендә югары белемем булу ярдәм итә. Югары Осланның район җитәкчелеге дә миңа карата бик хәерхаһлы. Башта бу эшне башкарып чыга-алуыма бик ышанмадылар, ахры. Эшләп күрсәткәч, бөтен яклап ярдәм итә башладылар. Авыл хуҗалыгы тармагына караган нинди дәүләт программалары бар – аңлаталар. Документлар тутырырга ярдәм итәләр.

Гөлнара Насибуллова мини-фермалар төзү өчен бирелә торган программа нигезендә дәүләттән кайтарылмый торган 200 мең сум акча алган. Шуңа быел 8 сыерга исәпләнгән абзар салдырган. Савым сыерлары өчен елга бер тапкыр бирелә торган 3 мең сум акчага иген кайтарткан.

– Сыер асрауның файдасы бар, – ди Гөлнара. – Әлбәттә, азык та күп кирәк. Үзебезнең җир, техника булмагач, бөтен әйберне сатып алырга туры килә. Тик барыбер чыгымнарга караганда керем күбрәк. Район авыл хуҗалыгы бушка печән, салам да кайтартты. Кыш чыгарга азык бар.

Гаилә быел йортларын да зурайткан. Ә киләсе елга Гөлнараның планнары тагын да зурдан икән – крестьян-фермер хуҗалыгы булып теркәлеп, илле баш сыерга исәпләнгән ферма төзетү. Урындагы җитәкчеләр моның өчен махсус җир бүлеп биргән инде.

– Бу кулларны сыер сава дип әйтеп булмый, – дим, Гөлнараның маникюрына карап.

– Үзем савам, кулга перчатка киям, – дип елмайды яшь фермер. – Ни өчендер сыер савучы пычрак,

иске халаттан йөрергә тиеш, дип уйлыйлар. Мин бит бу куллар белән сөт, каймак, эремчек, корт та сатам.

– Аларны да үзең ясыйсыңмы?

– Сөт ризыклары ясау күбрәк әни өстендә. Пәнҗешәмбе, җомга көннәрендә сепарат аертып корт, эремчек ясый. Ярминкәгә апа белән бергә барабыз. Базарга җомга төнлә үк барып куябыз, югыйсә урын калмый. Ике ел шулай сату итәбез, үз сатып алучыларыбыз бар. Көтеп торалар.

Ана белән кыз тагын 300 баш каз, 300 баш үрдәк, 250 баш тавык үстергән! Тавык-казларны суеп урнаштырып бетергәннәр, үрдәкләрнең йөздән артыгы бар икән әле.

Гөлнара аш-суга да бик уңган. Ат ите белән сыйлады ул безне. Хыялында ат асрау да бар икән.

– Синең кебек уңган кызга егет табуы да авырдыр, – дим.

– Булачак ирем миннән дә ким эшләргә тиеш түгел, – дип елмайды Гөлнара. – Әлегә кияүгә чыгарга планым юк. Әлбәттә, гаиләдә ир-ат булу кирәк. Әтине еш искә алам, бик җитми ул безгә. Рәхмәт, әле әнинең абыйлары бар, ярдәм итәләр. Ни дисәң дә, хатын-кыз бит хатын-кыз ул, никадәр генә булдырса да, ир-ат кулы кирәк.

Гөлнара янә укырга кергән – КФУның музыка факультетында белем ала. Кечкенәдән сәхнәдән төшмәгән кызның икенче бер хыялын да тормышка ашырасы килә – югары белемле җырчы булу.

– Бездә җырчыларның исәбе-хисабы юк, синең җырчы фермер буласың киләме? – дим, уенын-чынын бергә кушып.

– Күз күрер инде, белемнең артыгы булмас...

90 ЯШЬЛЕК АВЫЛНЫҢ 130 ЕЛЛЫК МӘКТӘБЕ

Бакча-Сарайда тагын бер үзенчәлекле нәрсә – урта мәктәп. Нәкъ авылның уртасында балкып утыра ул. 37 бала белем ала биредә. Бакча-Сарай авылындагы белем бирү йорты Матюшино урта мәктәбе исемен йөртә. Бактың исә, Бакча-Сарай авылы төзекләнә, үсә башлагач (1980нче еллар), бирегә яңа мәктәп бинасы салганнар. Һәм күрше Матюшино авылы укучылары, яңа мәктәптә укысыннар, дип, Бакча-Сарайга китергәннәр. Ә исеме «Матюшино урта мәктәбе» дип калган.

Белем бирү йортына да сугылдык. Районда гына түгел, республика буенча да алдынгылар рәтендә икән ул. Быел «Республика авыллары арасында иң яхшы 100 мәктәп» исемлегенә кертелгән. Ике тапкыр миллион сум грант отканнар. Җитәкчесе Илдус Әнвәр улы Шәрәфиев «2017 елның иң яхшы мәктәп директоры» исеменә лаек булган.

Матюшино урта мәктәбенең төп үзенчәлеге – биредә трактор сыйныфлары бар. Тугызынчы сыйныфны тәмамлаган егетләр, Югары Осланның төрле авылларыннан килеп укыйлар. Трактор йөртү таныклыгы алып чыгалар.

– 2017 ел башында, трактор курсларын видеога төшереп, укыту планнарын күрсәтеп, Мәскәүгә – конкурска җибәргән идек, – дип сөйләде Илдус Шәрәфиев. – Күрәсең, Россия буенча мондый тәҗрибә бик юк, безнең мәктәп белән Мәскәүдә дә кызыксындылар. Нәтиҗәдә, миллион сум грант оттык. Ул акчага махсус тренажер кайтарттык.

Тренажер дигәннәре, нәкъ трактор кабинасы кебек: руль артына утырасың да, сцеплениене кушасың. Зур экран аша кая барганыңны күзәтәсең.

– Укучылар бу тренажерга утырырга атлыгып тора, – диде Илдус Шәрәфиев. – Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнү өчен бер стимул булды, шунсыз рульне бирмибез.

Мәктәптә Бакча-Сарай авылы музее эшли. Анда авылның беренче кешеләре турында мәгълүмат, тарихи истәлекләр, тагын әллә ниләр бар.

Мәктәптән соң Роза апа Арсланова йортына киттек. Монда үзеңне галереяда йөргән кебек хис итәсең. Чигелгән, кулдан эшләнгән картиналар белән стеналар тулган. Тагын салкын фарфор, балчыктан эшләнгән савыт-саба, чәчәкләр, лента белән чигүле мендәр тышлары, дисеңме... Боларның барысына да Роза апа пенсиягә чыккач өйрәнгән. Җиде ел эчендә өен әнә шундый «авыл галереясына» әйләндергән!

– Кул эшләренә җәй көне алынмыйм, – диде Роза апа. – Вакыт юк, бакчада эш күп. Көздән язга кадәр картиналар чигәм, чәчәкләр ясыйм. Җанга рәхәтлек бирә. Бүләккә дә әйбәт. Хәзер кул эшләре модада бит!

...Менә шундый авыл ул Бакча-Сарай. Кешеләре дә, нәкъ табигате шикелле, күркәм. Эссе җәйдә, һичшиксез, барып күрәсе килә бу әкияти почмакны. Юкка гына җирле халык аны «Татарстанның Кырымы», дип атамый, ышаныгыз. ■

Күпләр, җәен килгән кешеләр өчен, йортларына икенче кат та өстәп ясарга тырышкан.

Мәктәптә Бакча-Сарай авылы музее эшли.

«Кул эшләре бүләккә дә әйбәт, алар хәзер модада бит!» – ди Роза апа Арсланова.

Без үз якларыбызда күпләп «яшәгән» Татарстан риваятьләрен җыюыбызны дәвам итәбез. Бүгенге тарих – Лаеш районыннан.

ТАТАРСТАН РИВАЯТЬЛӘРЕ: БИЧУРА ҮЧЕ

Өлкәннәр аны шук-шамакай яисә хулиган дип атыйлар. Һәм кыланышлары турында сөйләгәндә һәрвакыт аңа сокланалар да кебек. Бу шаяртучының исеме – Бичура, сөйләүләре буенча, идән астында, чарлакта яисә мунчада яшәп ятучы бәләкәйрәк буйлы бер хатын. Ләкин һәркемдә дә яшәми ул, үзе сайлап алган хуҗаларда гына. Еш кына – ялгызакларда. Кемдер аның тәртипсезлекләренә куркып карый, кемдер ихтирам күрсәтә – төнгә ризык салынган савыт калдыра, ә ул иртәнгә бушап куйган була. Әгәр хуҗаның ризыгы тәмсез булса, Бичураның тәлинкәне ватып ташлавы, яисә, кечкенә давыл кебек, тирә-яктагы бар нәрсәне туздырып атуы да мөмкин. Менә шундый йорт иясе, әмма үзе көйсез хатын-кыз холкына ия, башында борынгы татар баш киеме – ирнак булыр. Белгән кешеләр аның көйсезлекләрен кичерә, чөнки аңлыйлар: кемдә Бичура яши – алар байый, һәм киресенчә, кем аны куып җибәрә – ул фәкыйрьлеккә дучар була.

Әнә шундый үзсүзле Бичура Лаеш өязенең Кискә Асты авылы мулласында яшәгән дип сөйлиләр. Мулла көннән-көн байый барган. Аның акчасы күп, терлекләре таза һәм тук булган, ди. Бичура акчаны аңа төннәрен күршеләрдән урлап китерә, ә атларын шулай ук күршеләрнең келәтләреннән урланган солы белән сыйлый икән, дигән сүзләр йөргән.

Әмма дөньяда һәр нәрсә өчен дә түләргә туры килә, һәм мулла аңа кирәгенчә түли дә – көйсез Бичура хуҗага, өенә соңарып кайткан чагында, йә киез итек томыра, йә мич башыннан утын пүләне, мич артыннан кирпеч ыргыта... Хет бөтенләй өйгә кайтып кермә. Шуңа да авылдашлары еш кына бай мулланың, ирнаклы көйсез зат хуҗа булган өенә керергә куркып, тыйнак кына өй нигезендә утырганын күргәләгәннәр.

Һәм менә Бичура үзенең кыланышлары белән хуҗаны шулкадәр туйдырган ки, ул аннан котылырга уйлаган. Моның өчен мулла күрше авылдан бер сихерче кызны алып кайткан. Үзе бик матур, яшь, ди. Әмма сихерче кызның капкадан керүе булган, мулланың бөтен амбарларына, сарайларына ут капкан, һәм ут тиз арада өенә дә күчкән. Күршеләре ничек кенә тырышмасын, янгынны сүндерә алмаганнар. Бер сәгать эчендә мулла фәкыйрьлеккә төшкән: өйсез дә, мөлкәтсез дә, мал-туарсыз да калган. Мулла яшь сихерче кыз белән бәхетлерәк булгандырмы-юктырмы – монысы турында хәбәрләр килеп ирешмәгән. Әмма без беләбез инде, законлы Бичураңның ачуын китерү – үзеңә үк зыян салу дигән сүз. Гафу итмәячәк. Үч алачак. Ай, үкенерсең!

Редакция сезнең туган якларыгыз, авылларыгыз риваятьләрен дә «бүләккә» рәхәтләнеп кабул итә. Җибәрегез аларны безгә – һәм бөтен ил сезнең туган яклар турында белер.

Фото: Карина Гизатуллина. Реклама

FURIA*

НЕ СКРЫВАЙ
СВОЙ
ХАРАКТЕР

Казань, ул. Н. Ершова, 1а
Торговый дом Корстон, 1 этаж
тел.: (966) 250 03 83

furia_kazan
www.furiamex.ru

СОБОЛЬ • КУНИЦА • РЫСЬ • ШИНШИЛЛА • НОРКА • ПУШНИНА

* Фурия.

ТАССР 100 лет

«Татарстан»лы Яңа ел беләнǃ